www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 39 (1455) 6 октябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



8-9

Галимҗан Ибраһимовның «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» әсәре 1911 елда аерым китап булып басылып чыга, ул бу елларда инде Казанда яши, күп фатирлар алыштыра.

12-13

Түбән Кама районының Олы Аты авылында туып-үскән Владислав Уткин 2014 елдан башлап Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә эшли, бик күп бию образлары белән танылып та өлгерде.

19

Актаныш районының Татар Ямалысы авылында туып-үскән Дибәҗә Каюмова 30 ел буе Алабуга мәдәни-агарту училищесында укыта, күренекле педагог кына түгел, шагыйрә буларак та таныла.



Күз иркендә ямансулап тора Казаныбыз күрке казан да...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Рөстәм Миңнеханов житәкчелегендәге Татарстан Республикасы делегациясе Астанада узган «Иннопром. Казахстан» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә катнашты.

- Дөнья татарларын берләштерүче Бөтендөнья «Татарча диктант» акциясенә теркәлү тәмамланды.

- Чечен Республикасында Татарстанның сәнгать осталары, халык сәнгать һөнәрләре остазлары, иҗат интеллигенциясе, кинематографистлары катнашында Татарстан Республикасы Мәдәният көннәре узды.

- Беларусь Республикасының Янка Купала исемендәге Милли академия театры сәхнәсендә Татарстанның В.И. Качалов исемендәге рус драма театры артистларын ике атна дәвамында тамашачылар көндәлек алкышлар белән каршы алды.

- Башкортстанның Дүртөйле районы Иске Кәңгеш авылында Агыйдел буе татарлары тарихына багышланган төбәк тарихын өйрәнүчеләренең түгәрәк өстәле узды.

- Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы уңаеннан уздырылган «Зур бәлеш-гөбәдия» гастрофестивалендә метр ярымлык гөбәдия пешерелде.

- «Балтач» тыюлыгы хезмәткәрләре Норма авылының «Тургай» балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре өчен «Чиста чишмә» экологик акциясен үткәрде.

- Казандагы халыкара юридик форумда Халыкара юристлар һәм консультантлар ассоциациясе тәкъдим итедде, дустанә юристлар концепциясе турында фикер алышу узды.

- Васильево поселогында ике катлы «Берег-Яр» дип исемләнгән беренче яшьләр үзәге төзелә башлаячак.

- Агымдагы елның 8 аенда Татарстанда хайваннарның йогышлы авыруларына каршы 410 миллион вакцинация, 4 миллион диагностик тикшеренүләр һәм паразитларга каршы 2,5 миллион хайван эшкәртү үткәрелгән.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

7 октябрь – язучы, драматург, Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе Данил Хәбибрахман улы Салиховка 65 яшь (1958).

9 октябрь – Бөтендөнья почта көне.

12 октябрь – 1552 елда Явыз Иванның Казанны басып алган көне – Хәтер көне;

– Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгат Сафа улы Таҗетдинга 75 яшь (1948).

СЫНАМЫШЛАР

● 6 октябрьгә яфраклар саргайса, әмма коелмаса, көн тиз генә суытмый әле.

● 7 октябрьдә – чөгендер, 8 ендә кәбестә уңышын җыярга кирәк.

● 8 октябрьдә беренче кар яуса, 21 ноябрьдән чын кыш башлана.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 56 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 09 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 13 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **13 октябрьдә 10 сәгать 41 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 9, 10 октябрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(6-14 октябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигул әүвәл аеның 21 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Рүзәл ЮСУПОВ, академик

ТУГАН ТЕЛ АБРУЕ

Күренекле татар шагыйре Һади Такташның «Ана – бөек исем» дигән матур сүзләре бар. Бу гыйбарәне ул ананың исеме генә түгел, җисеме дә күркәм шәхес булуын күздә тотып әйткән. Чыннан да, ана кешенең җәмгыятьтә, гаиләдә мөһим урында торган, бик кирәкле һәм кадерле зат икәне бәхәссез. Яшәешнең нигезендә ата-ана булу һәркемгә мәгълүм. Шушы хакыйкатькә эстәп, «Ана – тормышның алтын тоткасы», дип әйтергә дә мөмкин.

Ата кеше гаиләнең матди нигезен төзүдә хәлиткеч көч булса да, тормышның иминлеген, ямен саклап тотуда иң игелекле вазыйфаны – балалар тәрбияләп үстерүдәге мөһим бурычны барыннан да бигрәк ана башкара. Безгә, татарларга, үзебезнең аналарыбызга күңелләребездә аеруча зур хөрмәт хисләре саклау фарыз. Чөнки татар халкының тормышында аналар күп гасырлар дәвамында, үзләрен аямыйча, фидакарьлек белән, балаларын игелекле, тырыш, итагатьле һәм башка асыл сыйфатларга ия кешеләр итеп тәрбияләп үстерүгә ирешкән. Татарлар эшлекле, инсафлы, югары әхлаклы халык икән, бу беренче чиратта аналарның казанышы: бала тәрбияләп үстерүдә иң зур хезмәт, иң зур җаваплылык ана өстендә.

Хәзер татар ата-аналарына яшь буынны лаеклы тәрбияләүдә аеруча катлаулы бурыч йөкләнә. Бу бурыч бүгенге яшьләрне, башка күркәм сыйфатлары белән бергә, милли җанлы итеп тәрбияләү ихтыяҗы белән бәйләнгән. Хикмәт шунда: хәзерге глобализация шартларында кешеләрнең миллилек сыйфатларын саклау кыенлаша – безнең илдә аз санлы халыкларның милли мәдәнияте күп санлы халык мәдәниятенә ассимиляцияли, гади итеп әйткәндә, йота бара. Чын цивилизацияле, югары культуралы җәмгыятьтә глобализация күренеше аз санлы халыкларның мәдәниятләрен, телләрен һәм үзләрен юкка чыгару исәбенә түгел, төрле милләтләрне үстереп, аларның бер-берсен баетуы аша җәелә. Әмма безнең илдә глобализация аз санлы халыкларның милли телләрен һәм мәдәниятләрен кысрыклау юлы белән бара.

Соңгы елларда татар мәктәпләренең күбесе ябылды, калганнарында русча укытуга күчә баралар. Янәсе, чыгарылыш имтиханнарын (ЕГЭ) рус телендә бирәсе булгач, хакимият вәкилләре, кайбер укытучылар һәм ата-аналар фикеренчә, татарча укыган егет-кызларга югары уку йортына керү кыен булачак. Дөрес, милли мәктәпләрдә укыган балаларга чыгарылыш имтиханнарын русча бирдертү тәртибе кертү начар булды. Моны милли мәгарифнең тамырына балта чабу дип кенә бәяләргә мөмкин. Республикалар хакимиятләренә милли мәктәпләрдә дәүләт имтиханнарын элеккечә, укучыларның туган телләрендә тапшыру тәртибен кире кайтаруны таләп итмичә ярамый. Хәзерге кырыс заманда бу омтылыш барып чыкмаса да, милли мәгарифне, һәртөрле чаралар күреп, бөтен көчне биреп сакларга кирәк. Хакыйкать шул: балалар үз телләрендә укымаса, алар дөрес әдәби телләреннән мәхрүм булып калачак һәм, димәк, халыкның сөйләм теле югалуга дучар булачак. Бу – бүген телебезнең саклануы, якын киләчәктә татар халкының алдынгы милләт буларак яшәеше өчен иң зур куркыныч.

Әмма хәл бөтенләй үк котылгысыз түгел. Әгәр дә республика хакимияте, мәгариф органнары һәм мәктәпләр татар телен саклау максатында акыл белән эш итсә, шулай ук укучыларның ата-аналары, туган телләреннән мәхрүм булып, үз милләтен югалтырга теләмәсә, хәзерге кыен шартларда да балаларны, яшьләрне, туган телләрен камил белеп, шул телдә иркен аралаша алырлык итеп тәрбияләргә мөмкин.

Татар телен яшәтүнең төп чарасы буларак, балаларга һәм яшьләргә туган телләрен укыту-өйрәтү эшенең тиешле нәтиҗәсе барыннан да бигрәк ата-аналарның бу мәсьәләгә уңай мөнәсәбәттә торуына, ягъни аларның балаларына туган телләрен яхшы итеп өйрәтүнең зарурлыгына инанган булуына бәйле. Бүгенге көндә балаларның туган телләрен белүе һәм бу телдә аралашуы мәсьәләсендәге иң зур бәла – ата-аналар арасыннан күбесенең бу мәсьәләгә битараф һәм хәтта тискәре караштa торулары. Аларны, бу хәтәр мөнәсәбәтләреннән арындырып, туган телне белүнең һәм ул телдә аралашуның бик кирәкле икәнлегенә төшендерүгә ирешмәсәк, бу турыдан-туры татар халкының гуманитар һәлакәтенә юл тоту булачак.

Ни өчен бу изге эшнең уңай яки тискәре нәтиҗәсе беренче чиратта ата-аналарга бәйле? Чөнки хәзер Россия законы буенча укучыларның кайсы телне өйрәнүләре ата-ананың ихтыяры белән хәл ителә. Ул бездә баласының нинди тел дәресләренә йөрүен язма рәвештә белдерергә тиеш. Бик аяныч, хәзерге татар ата-аналарының шактые балаларын туган тел дәресләре урынына рус теле дәресләренә йөртә. Төп сәбәбе һаман да шул – югары уку йортына кереп уку өчен рус телен яхшырак белсеннәр дигән теләктә булу.

Хәзерге уку планнары һәм программалары буенча, белем алучы яшьләргә югары уку йортында уку өчен борчылырга кирәкми: мәктәпләрдә, шул исәптән татар мәктәпләрендә дә, рус теленә күп сәгатьләр бирелә һәм бу предмет яхшы итеп өйрәтелә һәм тырышып укыган татар егет-кызлары, теләсә кайсы вузга кереп, уңышлы укый ала.

Татар телен өйрәнү һәрьяктан файдалы. Иң әүвәл, туган телне белү – һәркемнең изге бурычы. Туган тел ул – халкың тарафыннан меңнәрчә еллар буена барлыкка китерелеп, камилләштерелеп, ата-аналарың, әби-бабаларың аша ирештерелгән мөкатдәс байлык. Шунлыктан аңа, ата-анаңа, якыннарыңа булган кебек, зур ихтирамлы караш хөкем сөрергә һәм ул кадерләп сакланырга тиеш. Хакыйкать шул: тел югалса, милләт тә бетә. Татар телен белгән кешеләргә, уңышлы яшәү һәм эшләү өчен, мәйдан киң була: бу телне белгән кеше дистәләрчә халыклар белән турыдан-туры аралаша һәм хезмәттәшлек итә ала. Өстәвенә, берничә тел өйрәнү баш миенең тулы куәткә эшләвенә ярдәм итә (бу күренеш физиолог галимнәр тарафыннан расланган). Берничә тел иясен икенче милләт кешеләре дә хөрмәт итә, башка халыклар телен белү аңа алар белән тиз аңлашырга, уртак фикергә килергә ярдәм итә. Алдынгы илләрнең күбесендә яшьләрнең берничә тел белүе – гадәти күренеш.

> ***Берничә тел иясен икенче милләт кешеләре дә хөрмәт итә, башка халыклар телен белү аңа алар белән тиз аңлашырга, уртак фикергә килергә ярдәм итә.***

Шунысы да бар: туган телне яклау һәм саклау, шул максаттан милли мәгарифне алга җибәрү дәүләт җитәкчелегендә һәм аның ярдәме белән башкарылырга тиеш. Бу мәсьәләдә эшне активлаштырып, зуррак нәтиҗәләргә ирешү ихтыяҗы бәхәссез. Милли мәктәпләр эшенә, бигрәк тә татар телен һәм әдәбиятын укытуның күләмен һәм сыйфатын күтәрү бурычы тора. Татар мәктәпләре иң яхшылардан, татар телен һәм әдәбиятын укыту иң нәтиҗәлеләрдән булырга тиеш.

Мәгариф министрлыгыннан, татар телен һәм әдәбиятын укытуны оештыру белән нәтиҗәлерәк шөгыльләнеп, укучыларның бу фәннәрдән белемнәренең төплерәк булуына ирешү таләп ителә. Рус мәктәпләрендә балаларга һәм яшьләргә татар телен укыту белән, нигездә, формаль рәвештә шөгыльләнүләрен истә тотып, бу бик әһәмиятле эшне дә җайга салу зарур. Әлеге предметны бигрәк тә татар балаларына яхшы итеп укыту мөһим, чөнки ул аларның туган теле, ана телен исә һәркем белергә тиеш. Мәктәп директорлары һәм укытучылары ата-аналарга һәм укучыларга туган телләрен белүнең әһәмиятен аңлатуга юнәлдерелгән идеология эше белән нәтиҗәле шөгыльләнсен иде.

Россиядә янә битлек режимы кертә башладылар

Россиянең кайбер төбәкләрендә ковид, грипп һәм ОРВИга каршы көрәшү максатыннан битлек режимы кертелә башлады.

Тула өлкәсендә медицина оешмасына килүчеләргә һәм шунда эшләүчеләргә битлек режимын үтәргә киңәш ителә, Төмәндәге кайбер поликлиникаларда һәм хастаханәләрдә дә шулай ук шәхси саклык чараларын кулланырга, дигән киңәш игълан ителде, дип яза «Лента.Ру» сайты.

Моннан тыш, Псков өлкәсенең Сәламәтлек саклау комитеты рәисе Марина Гаращенко төбәктәге хастаханәләрдә битлек режимы кертелү турында хәбәр итте. Саратов өлкәсендә хастаханәләрнең медперсоналына битлек киеп йөрү мәҗбүри, ә Пермь краенда поликлиника һәм хастаханәләрнең баш табибларына битлек киеп йөрергә киңәш ителгән.

Шулай итеп, Төмән, Пермь крае, Югра, Мәскәү, Тула, Псков, Саратов өлкәләре хастаханәләрендә кабат битлек киеп йөри башладылар. Татарстан әлегә бу исемлектә юк. Хәзерге вакытта Татарстанда коронавируска бәйле вазгыять тотрыклы, дип хәбәр итә республика буенча Роспотребнадзор идарәсе.

Коми республикасында, Югра, Мурманск һәм Томск өлкәләрендә мәктәп укучылары дистанцион укуга күчерелгән, дип хәбәр итә массакүләм мәгълүмат чаралары.

Ханты-Манси автоном округында ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны арту сәбәпле, барлык медицина оешмаларында да битлек режимын кире кайтарганнар. Шулай ук пациентлар һәм хастаханәгә килүчеләр өчен аерым фильтр ясалган, анда аларның температураларын үлчәп һәм кулларын антисептик белән чистартып кертәләр. Иркутск өлкәсендә Иркутск шәһәре аэропортында контроль алып барыла, анда хезмәткәрләр халыкара рейсларның пассажирларын һәм экипажларын тикшерә.

Мәскәүдә сәламәтлек саклау оешмаларының бер өлешендә битлек режимы гамәлдә, Санкт-Петербургта эпидемиологик вазгыять аркасында, митинглар, демонстрацияләр һәм пикетлар уздыруга тыю вакытын август аенда ук озайтканнар иде.

Соңгы атнада Россиядә коронавирус белән авыручылар саны 48 процентка арткан. Шул сәбәпле, Роспотребнадзор коронавирусның «пирола» дип аталган яңа төре барлыкка килү турында хәбәр итте. Бу төрнең өстәмә мутацияләре бар, һәм ул омикронның баштарак табылган вариантларына караганда күпкә йогышлырак. Коронавирусның «пирола» дип аталган яңа штаммы Татарстанда әлегә табылмаган.

Яңа «пирола» штаммына бәйле рәвештә ковидны дәвалауның нинди дә булса үзенчәлекләре юк, дип аңлатты санитар табибләр. Аның дәвалау өчен ковидны дәвалауда кулланылган шул ук препаратлар файдаланыла.

Татарстандагы Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Анна Попова әйткәнчә, хәзер ковид белән авыру очраклары артса да, хастаханәгә салу очраклары аз теркәлә. Ул прививкалар ясарга һәм инфекцияләрне профилактикалау кагыйдәләрен үтәргә өнди.

Республикада һәр атна саен ковидның 76 очрагы теркәлә, бу узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 8,3 тапкырга азрак.

«Соңгы атнада ковид белән авыруның артуы 24 очракны тәшкил итте. Бу – яңа коллективлар формалаштыру белән бәйле, бу – елның шушы чорына хас күренеш», – дип аңлаттылар Роспотребнадзор идарәсендә.

Республикада коронавирус инфекциясе белән бәйле нинди дә булса чикләүләр кертү турында сүз бармый, диделәр ведомствода.

intertat.tatar.

Блогер кызга өч ел төрмә



Казан блогеры һәм эшмәкәре Парвина Әбүзәровага хөкем карары игълан ителде. Ул махсус операциягә каршы постлары өчен 3 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Мөселман киемнәре дизайнеры Әбүзәрова шушы гомерен гомуми режимлы колониядә уздырырга тиеш була. Казанның Яңа Савин район суды шундый карар чыгарды.

Судта блогер үзенең гаепсез булуын раслый.

«Коммерсантъ» газетасы апрель аенда «ФСБ мәгълүматлары буенча, кыз блогында экстремистик материаллар урнаштырган һәм «Россия хәрбиләрен дезертирлыкка өндәгән», дип язган иде.

Блогер Парвина Әбүзәрова Россия Федерациясе Җинаять Кодексының 280.4 маддәсенең 2 нче өлеше буенча (дәүләт иминлегенә каршы юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыруга ачык (гаммәви) чакырулар) гаепле дип табылды. Бу хакта «Ъ-Казан» сайтына суднның матбугат хезмәтендә хәбәр иткәннәр. Бу маддә буенча 1 миллион күләмендә (яки соңгы 5 елдагы хезмәт хакы күләмендәге) штраф билгеләү, яисә 3 елдан 6 елга кадәр иректән мәхрүм ителү каралган. Суд хатынкызны ирегеннән мәхрүм иткән.

Казан блогеры П.Әбүзәрованың социаль челтәрдәге аккаунтына 82 мең кеше язылган. Ул, нигездә, ислам, мода, психология темасына язган, шигырьләр урнаштырган. Әбүзәрова мөселман кызлары өчен спорт киемнәре брендын булдырган, кулинария студиясе проектын башлап җибәргән. Иреннән аерылган, балигъ булмаган 2 баласын ялгыз тәрбияли.

«Коммерсантъ» язуынча, Парвина Абузарованы 2023 елның март ахырында тоткарлаганнар. Татарстан буенча ФСБ идарәсе хәбәр иткәнчә, кыз социаль челтәрләрдә «Украинада махсус хәрби операциядә катнашучы Россия хәрбиләрен дезертирлыкка чакырулар» язган. Көч структуралары мәгълүматлары буенча, Парвина Әбүзәрова башта гаепле булуын таныган, ләкин соңыннан качып китәргә тырышкан, аны федераль эзләүгә игълан иткәннәр. Март ахырында аңа өй аресты билгеләнгән була. 11 сентябрьдә суд залында кулга алынган.

14 февраль көнне аның фатирында тентү узган. Ул чакта блогер үзен терроризмда гаепләүләрен хәбәр иткән.

«Минем аңлавымча, мине террорчылыкта гаеплиләр. Шундый мөнәсәбәт күрсәтсеннәр өчен, кайсы төшем белән мин террористка охшаган?» – дип язган булган ул вакытта Әбүзәрова.

Интертат.

Транспортта йөрү бәяләре арта

2024 елдан Татарстанда өлкәннәр һәм балаларга транспортта йөрү өчен айлык бердәм социаль билет бәясе артачак. Республиканың Транспорт министрлыгы тарафыннан эшләнгән Татарстан Хөкүмәте карары проекты коррупциягә каршы экспертиза уза.

Мәсәлән, транспортта йөрү өчен айлык бердәм социаль билетны тулыландыру бәясе – 605 сум, ә балалар өчен 369 сум тәшкил итә. 2023 ел белән чагыштырганда, ул 24 һәм 15 сумга артачак.

Исегезгә төшерәбез, узган ел транспортта йөрү өчен айлык бердәм социаль билет бәясе 34 сумга һәм 21 сумга арткан иде.



13 ел төрмә өчен 31 млн сум түләячәкләр

13 сентябрьдә Уфаның Ленин районы суды 86 яшьлек Фәтхулла Исхаков дәгъвасы буенча хөкем карары чыгарды. Чит кеше кылган җинаять өчен ул 13 ел төрмәдә утырган. Бу турыда «Башинформ» хәбәр итте.

1959 елда 22 яшендә Фәтхулла Исхаковны танышы кылган җинаять өчен төрмәгә утырталар. Әлек ул 450 млн сум компенсация таләп иткән иде. Суд карары буенча, компенсация 31 млн сум булачак.

«13 ел эчендә Ф.Исхаков хатынын, ата-анасын югалта, баласы ятим кала. Ул ата-анасыз 10 ел чамасы яши. Ирекка чыккач, 50 ел чамасы ул гаделлек эзләп йөри. Шуңа күрә бу сумма – бик аз», – ди Исхаковның адвокаты.

Пенсионер бу акчаны кая куясын да билгеләгән инде – 450 млн сумга ул Сочида өй алырга тели, акчаның бер өлеше бинаны саклауга, хезмәткәрләргә булачак, диелә хәбәрдә.

2021 елның 21 декабрендә Россия Конституция суды, аерым очракларда, судларга, яңа дәлилләр барлыкка килгәндә, прокурор позициясенә карамыйча, хөкем карарларын кире карарга рөхсәт итте. 1959 елда хөкем ителгән Уфа кешесе Ф.Исхаковның дәгъвасына җавап сайтның судында чыккан.

Ф.Исхаков үтерергә маташуда гаепләнеп хөкем ителә, 13 ел колониядә утыра. Ул үзенең гаепсез булуын әйтә, ирекка чыккач та хөкем карарын бетерү артыннан йөри. 2012 елда шаһитларның берсе Исхаков хөкем ителгән җинаятьне үзе кылуын әйтә.

Яңа дәлилләр чыккач, прокурор судка тиешле карарны җибәрә. Берникадәр вакыттан ул аны кире чакыртып ала һәм судка башка җибәрми. Шулай итеп, озак еллар буена бу эштә билгесезлек кала. Прокуратура производствоны бернечә тапкыр туктата, реабилитация таләп итүче Исхаковның дәгъвалары буенча судлар моның белән килешми, ләкин хөкем карарын да кире какмыйлар. 1959 елның 25 маенда чыгарылган карарны кире кагу турында карарны Россия Югары суды быел майда гына чыгара.

1959 елда Исхаковны 3 кызны үтерергә маташуда гаеплиләр. Имеш, 22 яшьлек егет танышларының өенә кергән һәм пычак белән һөҗүм иткән. Судта моны 4 кеше раслый. Исхаковны 15 елга төрмәгә утырталар, ул үзенең гаепсез булуын исбатлый алмый. Фәтхулла төрмәдә утырганда, хатыны да, әти-әнисе дә үлә. 13 елдан ирекка чыккач, ул кабат гаепсез булуын исбатларга тырыша.

1 нче биттә – Көзге Казан күренеше.

Сабада Кабак бәйрәме

22 сентябрьдә Байлар Сабасының үзәк мәйданында «Кабак бәйрәме- 2023» иҗади фестивале гөрләде. Быел «Кабак» бәйрәме юбилеен билгеләп үтә. Ул 2003 елда «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясе коллективы инициативасы белән уткәрелә башлый һәм 20 тапкыр уздырыла.

Саба үзәгендә буеннан-буена кабактан күргәзмәләр тезелеп киткән. «Бәйрәм исе» әллә каян сизелеп тора иде. Кабак бәлеше, кабак согы, кабак бөккәне һәм кабактан ясалган төрле әйберләр. Әлеге бәйрәм – Саба районына гына хас күренеш. Ул башка районнарда көзге ярминкә форматында гына узып китә. Ә Кабак бәйрәмендә, ярминкәдән аермалы буларак, иң зур кабакны билгелиләр. Шушында җиңү өчен, Саба халкы яздан ук күз карасыдай карап, су сибеп, кабакны шушы бәйрәм өчен үстерә.

Саба – нарат агачларына бай як. Район үзәге чисталыгы, табигате, матурлыгы белән соклану уята. Татар җанлы, татар мохите белән яшәүче халык монда. Саба районының авыллары да бик матур. Йорт-җирләре төзек, урамнары чиста, соклану уята торган табигате белән чын авылча яшәп ятучы халык монда. Әмма Саба халкының бер тискәре ягы бар икән – бәйрәмне вакытында башламау, халыкны бик көттерергә яраталар.

Инде барлык күргәзмәләрне карап бетердем дигәндә генә, сәхнәгә алып баручылар күтәрелде. «Кабак» бәйрәмен башлап җибәрү өчен сүз Саба районы башкарма комитеты җитәкчесе Ишниязов Марат Рәшат улына, шушы бәйрәмне оештыручы «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясенең җитәкчесе Мөбәрәкова Әлфия Галимҗан кызына бирелде.

«20 нче ел рәттән районыбыз журналистлары, радио-телевидение тапшыруларыннан арынып торган арада, көзнең бер матур көнендә Кабак бәйрәме үткәрә. Быел Кабак бәйрәменә, бүтән еллардан аермалы буларак, комиссия әгъзалары итеп, оешма, учреждение җитәкчеләре чакырылды».

Барлык комиссия әгъзаларын бер сәхнәгә чакырдылар. Алар һәр күргәзмә мәйданчыгын әйләнеп уза, үзләренең бәяләрен бирә һәм җиңүчеләрне билгели. Әле күргәзмәләргә бәя бирә башлаганчы, Әлфия Мөбәрәкова сорауларга җавап бирде.

– Байлар Сабасында Кабак бәйрәме үткәрүне «Саба дулкыннары» телерадиокомпаниясе журналистлары уйлап тапты. Бәйрәмебез Республика күләменә дә күтәрелде. Монда Мамадыштан, Арчадан, Балтачтан, Әтнәдән һәм Кукмарадан иң зур, иң эре кабакларны алып киләләр.

Бәйрәмдә Саба мәктәпләре, балалар бакчалары һәм мәдәният йортлары катнашты. Аларның һәммәсе дә кабактан күргәзмә оештырган. Һәр авылның мәдәният хезмәткәрләре, үзләрендәге фольклор коллективлары белән бергә, кабак турында такмаклар әйтеп, комиссияне каршы алдылар.

«Иң матур композиция», «Кабактан әзерләнгән ризыкны үзенчәлекле итеп тәкъдим итү» һәм «Иң зур кабак» номинацияләре дә бар иде. Бәйрәмнең иң төп вакыйгасы – иң зур кабак кемнеке? Башка еллардан аермалы буларак, быел иң зур кабакны халык соравы буенча ярып карадылар. Шикләнүләр булмасын өчен! Ләкин ни кызганыч: «Иң зур кабак» номинациясендә җиңү яулаган кабакны ярмадылар, башка көнне ярабыз, дип калдырдылар. Чөнки Казанда узучы бәйрәмгә дә шушы 90 килограммлы кабак барачак икән.

«Кабак бәйрәме- 2023» иҗади фестивалендә «Иң зур кабак» номинациясендә 3нче урынга 38,85 килограммлы кабак иясе – Кукмара районының Совхоз-Нырты авылыннан Рәшит Гыйльманов лаек булды. Икенче урынга 41,17 килограммлы кабагы белән Байлар Сабасыннан Адлен Ашимов чыкты. Ә беренче урын – Байлар Сабасындагы 92,4 килограммлы кабакка бирелде. Аны үстерүче – Алисә Хаҗиева. Узган елны да алар җиңү яулаган.

Бәйрәм бик матур концерт номерлары белән үрелеп барды.

Илзирә **ХӘЙРУЛЛИНА.**

Коншак районы башлыгы вафат

Чиләбе өлкәсендәге Коншак районы башлыгы Сибәгатулла Әминов вафат булган.

Сибәгатулла Әминов 1954 елда Коншак районы Татар Караболагы авылында туа. Көньяк-Урал дәүләт университетын тәмамлый, төрле металлургия предприятиеләрендә эшли. 2015 елда туган районы башлыгы итеп сайлана. Ике ел элек Сибәгатулла Әминовны яңадан башлык итеп сайлыйлар.

«Сибәгатулла Нурулла улын көчле, нәтиҗәле җитәкче, сүзендә тора белүче кеше буларак хөрмәт итә идек. Ул Коншак районының социаль өлкәсен һәм инфраструктурасын үстерү өчен күп эш эшләде. Аның көтелмәгәндә вафат булуы – район халкы, башлыклар корпусы, бу лаеклы кешене белгән һәм хөрмәт иткән һәркем өчен зур югалту», – дип хәбәр итә губернатор Алексей Текслер.

Бөтендөнья татар конгрессы Сибәгатулла Әминовның туганнары һәм якыннарының чын күңелдән кайгысын уртаклаша, диелгән хәбәрдә.

tatar-inform.tatar.
Фото: © Бөтендөнья татар конгрессы сайтыннан.

● Социаль фонд мәгълүматларыннан күренгәнчә, Россиядә ярты елда пенсионерлар саны 404 200 кешегә кимегән: 2023 елның 1 гыйнварына илдә 41,78 миллион пенсионер исәпләнсә, 1 июльгә инде 41,38 миллионга калган. Беренче яртыеллык азагына эшләүче пенсионерлар саны 7,8 миллионга тәңгәл булган, бу ел башындагыдан 82 500 гә кимрәк. Ярты елда 717 сумга артып, июльдә эшләүче пенсионерларга уртача 16 114 әр мең сум түләнгән. Эшләмәүче пенсионерлар саны исә 33,5 миллионга тәңгәл – гыйнварда андыйлар 321 700 кешегә артыграк булган. Әлеге категориядә пенсия күләме уртача 20 260 сум тәшкил итә.

● Бәйсез профсоюзлар федерациясе аңлатуынча, Россиядә пенсионерлар санының шулай кимүе быел беркемнең дә картлык буенча пенсиягә чыкмавы белән бәйле. 2023, 2025 һәм 2027 елларда пенсия тиешле еллар эшләүчеләргә һәм Ерак Төньяк шартларында яшәүчеләргә генә биреләчәк. 2024 елда исә картлык буенча пенсия 1966 елгы хатын-кызларга һәм 1961 елгы ир-атларга билгеләнәчәк.

Татарстанда ягулык кыйммәтләнде



Татарстанда барлык маркадагы бензин һәм дизель ягулыгына бәяләр чираттагы мәртәбә артты. 11-17 сентябрь көннәрендә төбәкләр буенча статистиканы «Росстат» Федераль дәүләт статистикасы хезмәте бирә.

Мәсәлән, атна эчендә дизель ягулыгының бәясе 58,77 сумнан 59,77 сумга кадәр күтәрелгән. АИ-92 бензины 42 тиенгә артып, 51,92 сум; АИ-95 – 40 тиенгә артып, 18 сентябрьдә 54,03 сум тәшкил иткән.

Иң аз үзгәргәне – АИ-98 бәясе, ул 36 тиенгә яки 65,49 сумга күтәрелгән.

Шулай да Татарстанда бензин һәм дизель ягулыгына уртача бәяләр Идел буе федераль округында иң арзаннардан санала. Татарстаннан бары тик Башкортстан гына алда бара.

«Ядәч»не карадык

Батулла улы Байбулатның кино төшерүе хакында ишеткәч тә, карарга кирәк, дип күңел җилкенеп куйды. Фильмның үзен күргәнче үк аның «Короче» дип аталган Бөтенроссия кыска метражлы кино фестивалендә дебют программасында җиңүен ишеттек. Ниһаять, фильм кинотеатрларда да күрсәтелә башлады.

Фильмны карарга килүчеләр арасында – артистлар, журналистлар, сәнгать кешеләре. Яшь режиссерның иҗаты белән кызыксыналар, димәк.

Фильм Батулла белән Алмаз Хәмзиннең кара-каршы эчеп утыру күренеше белән башланды, эчтә шундук ризасызлык кымырҗып куйды. Татар тормышыннан киноны хәмер кертмичә генә төшереп булмадымы икән?.. Татар тормышына хәмер кергәч, киносында да булыр инде ул…

Эчтәлекне кыскача гына әйтик: алты яшьлек Илһамны җәйге ялга авылга, әби-бабасы янына кайтарып куялар. Аның китәсе килә, телефонын кулдан төшермичә эти-әнисен көтә. Тик алар кайта алмый: очкычлары һәлакәткә очрый. Йөрәкләре хәсрәт утында көйсә дә, әби белән бабай сиздерми, оныкның күңелен күрү өчен әллә ниләр эшли. Бабай баланы ядәч уйнарга өйрәтә. Уенда оттырган картлар кибеттән бер чиләк туңдырма, бер ванналык газировка ташыйлар, көне буе робот булып сөйләшәләр һ.б. Ядәч уенына башка авылдашлар да кушылып китә. 83 минут дәвам иткән фильм барышында күз алдыбызда авылдагы гап-гади, хәтта беraз борынгырак көнкүреш белән яшәүче татар йорты тормышы бөтен бизәкләре белән ачыла. Артистлар уены шул җирлектә бик табигый агып кына бара кебек. Бабайны уйнаган Батулла да, танылган актриса Роза Хәйруллина да тел тидергесез, аларның уйнавы сизелми, алар шул мохиттә яши. Әби классик татар карчыгы түгел, экстравагантрак, тик аның шундый булуы күңел каршылыгы уятмый. Ә бабайга килсәк, кәгеп йөргәне өчен әбинең «мин синнән шундый түйдым, бүтәнчә түзә алмыйм» диюенә туры килми ул. Болай әйтер өчен бабай гомере буе баш ташлап эчкән, әбинең йөрәгенә төшкән булырга тиеш. Тик фильмда без андый таушалган сәрхүш картны күрмибез, анда таза, шома йөзле, зирәк, үз бәясен белгән картны күрәбез. Һәм әбинең аңа карата «мин бүтән түзә алмыйм…» дигән сүзләре ышандырмый. Бу рольне гомерлек сау, тәүфыйклы яшәү рәвеше белән әкиятче аксакал образына ирешкән Батулла түгел, башка актер уйнарга тиеш булгандыр.

Батулланың ике улын җитәкләп иҗат кичәләренә, спектакльләргә йөрүенә шаһит булып, соңрак бу талантлы җегетләрнең сәхнәдә чатнатып шигырь сөйләүләрен, ут чыгарып биюләрен алкышлап, «карап үстердек». Хәзер исә бу ике җегет – Байбулат белән Нурбәк милли сәнгатебез дөньясында үз юлларын эзли. Алар һичшиксез талантлы, гәрчә иҗат җимешләре күпләрдә каршылыклы фикерләр уятса да...

Фильмның ахырында күпчелек тамашачының күзендә яшь иде. Димәк, каткан күңелләр йомшарган, фильм кешеләрнең күңеленә үтеп, анда ниндидер хәрәкәт барлыкка китергән. Сәнгать әсәренең, аны иҗат итүченең максаты да шул түгелме соң?

Эльмира СИРАҖИ.

«Бистә шәле» фестивале

Татар халкы гомер-бакый тырыш, һөнәрле булган. Тире эшкәртеп читеген дә каеп кигән, йонны киезләп итеген баскан, шәлен бәйләп тә иңбашына салган, алъяпкычын да җете төсләр белән чиккән, өен дә энә-җепләр белән бизәкләп ямьләндергән. Һәр төбәктә үз эшенең осталары яшәгән.

Әйтик, Кукмара районы киез итекләре, табалары белән данланса, Балык Бистәсе уңганнары мамык шәлләре белән танылган. Күптән түгел Балык бистәсе районының Сабан туе мәйданында «Бистә шәле» I нче республика фестивале үтү дә шушы булдыклы халкыбызның һөнәрен дөньга күрсәтү ниятеннән иде. Татарстан Мәдәният министрлыгы, «Таткультресурсцентр», Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән үткәрелгән фестивальдә районның барлык авылларыннан кул эше осталары катнашты.

Шәл бәйләү Балык Бистәсе районында гына киң таралган һөнәрләрнең берсе. 1970 елларда Күгәрчен авылына Чистай районында туып-үскән Зәйтүнә исемле укытучы килеп төшә. Аның кул һөнәре дә була, ул шәл бәйли белә. Зәйтүнә авылда үскән тырыш, уңган кызларны, килен-җиңгәчиләрне күреп, аларга шәл бәйләү серләренә өйрәнергә тәкъдим итә. Яшьләр һөнәрне бик тиз үзләштерә. Шәл бәйләүнең тормышны алга җибәрү өчен бик отышлы һөнәр булуын да бик тиз аңлап алалар. Шуннан шәл бәйләү таралып китә. Тора-бара Күгәрчендә шәл бәйләп үскән кызлар башка авылларга килен булып төшә. Алар һөнәрне үзләре яшәгән җирләргә дә алып килә. Әйләнә-тирә авылларда бер-берсеннән күреп тә шәл бәйли башлыйлар. Шулай итеп Күгәрчен авылында башланган эш аеруча Ямаш, Балтач, Күки, Тегермәнлек авылларына тарала. «Бүген районның барлык авылларында да шәл бәйләүчеләр яши. Ир-атлар да хатыннарына булыша, ярдәм итә», – ди Балык Бистәсе районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Айгөл Вафина. Хәзерге көндә дә Күгәрчендә шау-гөр килеп гомер итәләр, авыллары белән шәл бәйләүне алып баралар.

Бәйрәмне район башлыгы Радик Исламов җитәкчелегендә дулкынланып каршы алганнар. Фестивальне үткәрү турында өч ел элек Бөтендөнья татар конгрессының Балык Бистәсе районындагы җитәкчесе Эльвира Касыймова әйткән булган. Аны башта төрле бәйрәм-кичәләрдә кечкенә генә өзек итеп күрсәткәннәр. Быел исә зурлап үткәрергә булганнар.

Мәйданда Татарстан Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Балык Бистәсе башкарма комитеты җитәкчесе Данис Сатдинов составындагы кунакларны Балык Бистәсе мәдәният үзәге каршында Мансур Җәләлов җитәкчелегендә эшли торган «Чулман моңнары» халык гармунчылар ансамбле милли көй-моңнарыбыз белән каршы алды. Аннары кунакларны осталарның йөзләрчә метрга сузылган шәл һәм кул эшләре күргәзмәсе белән таныштырдылар. Анда челтәр, мамык шәлләрнең нинди генә юк. Төрле зурлыктагы шәлләрнең һәркайсының бизәкләре дә үзенчәлекле. Иң зур шәл ике метр 20 сантиметрлы. Аларны гадәттә, ябынып йоклау өчен алалар икән. Моннан тыш бияләй-оекбашлар, шарф, өчпочмаклы кыекча шәлләр... Оренбургның данлыклы шәлчеләре дә, үз осталыкларын дәлилләп, гаҗәеп нәфис челтәр шәлләрен алып килгән. Алар арасында чын энҗеләр кушып бәйләнгән 120 мең сумлык зур шәлләр дә бар.

Бер мәйданчыкта «Шәл бәйлисем килә» дигән осталык дәресе бара. Анда мамыкны юу, тетү, шапылдату, башкача әйтсәк, аялау, эрләү, аннары аны катып йомгак ясау, бәйләү серләре белән танышырга мөмкин иде. Шунысы үзенчәлекле: кайбер районнарда мамыкны савып җеп итсәләр, Балык Бистәсе авылларында аны шәл өчен дә кабада эрләп әзерлиләр. Бәйләүчеләр арасында көз иярмәслек тизлек белән шәл бәйләүче ир-ат та бар. Ул – Тәбәрде Чаллысы авылында мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе Илшат Заһидуллин. Шәлне җиде яшендә бәйли башлаган. Әлбәттә, аның әбисе янында кадерле малай булып үсүе дә кулына бәйләү инәләре ала башлавына сәбәпче булгандыр. Оекбаш үкчәсен бәйләргә өйрәнүдән башланган осталык шәл бәйләүгә барып җиткән. Бүген инде ул иң оста шәлчеләрнең берсе. «Мин кечкенә вакытта кәҗә мамыгы юк иде. Куян асрый, аның мамыгыннан шәл бәйли идек. Эштән кайткан арада бәйләп, бер елга 30лап шәл өлгерткән еллар бар», – диде ул.

Күгәрчен авылыннан Сәрия Кәримуллина җиде яшеннән кулына бәйләү энәләре алган. Ул күршеләренә кереп башта сарык йоны җебеннән бәйләргә өйрәнгән. «Авылда барысы да диярлек шәл бәйли. Атнага бер шәл әзер була. Эштән кайткач, буш вакыт булганда, кулга бәйләү инәләрен алабыз. Күршеләр белән җыелышып кич утырганда да, капка төбендә ял иткәндә дә, кулларыбыз тик тормый», – дип сөйләде ул.

Зөһрә Зәйнуллина исә – Иске Арыштан. Бу авылда шәл бәйләү белән бик мавыкмаганнар. Әмма дүртенче сыйныфта укучы Зөһрәнең әнисе ел буе хастаханәдә авырып ята. Гаиләнең акчасы юк. Бу әле авылларга электр чыбыклары да сузылмаган еллар. Шуннан Зөһрә үзлегеннән өйрәнеп, керәчин лампасы яктысында шәл бәйли, аны 21 сумга сата. Бу ул елларда шактый акча була. Зөһрә Зәйнуллинага хәзер инде 72 нче яшь, ул һаман да кулыннан инәләрне төшерми. Гомере буе төзелештә, социаль яклау бүлегендә эшләсә дә, барлыгы 1500 дән артык шәл бәйләгән. Аларны төрле җирләрдә сатканнар. Отпуск вакытында исә төнге икенче яртыларга кадәр бәйли, уртаның яртысын бетерүне гадәт иткән. «Кеше бәйләгәнне яратмадым, пөхтә, матур булсын, дип тырыштым. Ул вакытта тормыш авыр иде. Аннары сеңелләребез өйрәнде, дүртебез дә шәл бәйли башладык. Кулга акча кергәч, тормыш та көйләнеп китте. Без эшләп яшәдек. Бәйләп тә, эшләп тә туймадым», – ди Зөһрә Зәйнуллина. Ул Волгоград ягына кәҗә мамыгына да отпуск вакытында үзе бара торган була. 100 әр кило мамыкны капчыкларга тутырып алып кайталар. Бервакыт аллап-артлап капчык белән мамык аскан хәлдә Мәскәү метросына керәләр. Зөһрә ханымның бер сумкасында күчтәнәчкә алынган – чәй, икенчесендә апельсин. Шунда З.Зәйнуллина абынып егыла. Апельсиннар чәчелә. «Андый хәлләр күп булды. Нужасын да күрдек. Кызыгы да, рәхәте дә булды», – ди ул. «Гомумән, бөтен тормышыбызны шәл белән көйләп алып бардык», – диләр Балык бистәсе шәлчеләре. «Укырга кергәнче үк бәйли идек. Әгәр шәлне тотарга вакыт тапмасак, бер эш тә эшләмәгән кебек кәеф кырыла», – дип сүзгә кушыла шәл бәйләү остасы Рузилә Әхмәтҗанова.

Аш-суга оста хатын-кызлар исә «Бистә кабартмасы» күргәзмәсен тәкъдим итә. Биредә тәлинкәләргә 26 төрле милли ризыгыбыз – кабартма тезеп куелган. Районда 26 авыл җирлеге бар, аларның һәркайсы кабартманы үзенчә пешерә. Гадәти кабартма, җимешлесе, кортлысы, майда йөздереп пешергәне... Иске Арыш авылы кабартмаларын тәкъдим итүче Зәмзәмия һәм Минзәлия Зәйнуллиналар аралашып алабыз. Алар апа сеңел кебек бик якын күренсә дә, кайнана белән килен булып чыкты. Әмма аларның үзара матур мөнәсәбәтләре өлге итеп куярлык. Икесе дә мәдәният өлкәсендә хезмәт куя икән. Алар пешергән кабартма аеруча тәмле тоелды.

Игътибарны нәфислеге белән хәйран калырлык итеп үреп эшләнгән якалар, кием бизәкләре, калфаклар җәлеп итә. Бу кул эшләре остасы Рәмзия Фәттахованың хезмәте. Ул җептән челтәрләп бизәкләр үрүне яңартып җибәргән, иҗат үзәгендә балаларга да өйрәтә.

Күргәзмәдә Хәтимә Солтанова Балык Бистәсе туган якны өйрәнү музееннан шәл тарихына кагылышлы күргәзмә алып килгән. Алар арасында балаларны киендереп, шәлгә төреп чанага утыртып бакчага алып бару күренеше элекке елларны искә төшерсә, кәҗә мамыгыннан бәйләнгән кием-салымнар да төрлелеге белән җәлеп итә. Арада 1950 нче елда бәйләнгән шәл дә бар.

Мәйданда бәйрәмне шәл бәйләү тарихын искә төшерү Республика районнарыннан килгән фольклор ансамбльләр, Балык Бистәсенең сәнгать коллективлары парады башлап җибәрде һәм фестиваль театраль күренешләр, сәнгати чыгышлар белән үрелеп барды. Мәйданга 75 шәлне кушып бәйләгән иң зур шәл чыгарылу бәйрәмнең иң иң матур мәле булды.

Төп сәхнәдә исә халкыбызның моңлы сандугачлары Зәринә Хәсәншина белән Сиринә Зәйнетдинова шәлчеләр фестивалендә катнашучылар өчен халкыбыз көйләрен башкарды, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Арча, Теләче, Әтнә һ.б. районнарның фольклор коллективлары милли йолаларыбызны искә төшерде.

Жюри әгъзалары өчен иң авыры «Иң креатив шәл» бәйгесендә җиңүчеләрне билгеләү булды кебек. Шәлләрнең һәркайсы үзенчә матур. Әмма Ямаш авылыннан Исламия Сафина фестиваль өчен махсус бәйләнгән ак мамыклы «Бистә шәле» дип язылганына «Иң креатив шәл» дип билгеләнде. «Иң тиз бәйләүче» бәйгесендә исә 20 оста катнашты. Аларга 25 метрлы җепне сыйфатлы итеп бик тиз бәйләп бетерергә кирәк иде. Бәйге бик кызды, осталарның кулларының җитезлеге – гаҗәеп. Бу конкурста Кече Укмас авылыннан Гөлүсә Хисмәтова җиңүче дип игълан ителде.

Барлык җиңүчеләрне дәрәҗәле кунак_лар котлады, аларга истәлекле бүләкләр тапшырды.

Бәйрәм беренче тапкыр узса да, ул бик уңышлы чыкты. Районның мәдәният бүлеге җитәкчесе Лилия Кәримуллина искәрткәнчә, Балык бистәсенә генә хас булган «Шәл фестивале»н үткәрү гомер буе шәл бәйләүче, сатучы халкыбызны данлау, хөрмәтләү фестивале дип тә атарга мөмкин булыр иде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Казанга җыелган 700 гармунчының берсе

Республика көне уңаеннан Камал театры каршында «Уйнагыз, гармуннар!» XXXVIII Республика халык иҗаты фестивальле узды. Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев әйтүенчә, бәйрәмгә 30 өлкәдән 700 милләттәшебез килгән. Шундыйларның берсе – Гаяз Габдуллин.

Гаяз абый Габдуллин Төмән өлкәсе Шыкча авылыннан килгән. Борынгы татар авылы Шыкчага (русча Чикча) 1483 елда нигез салына. Авылга хәзерге вакытта 540 ел! XX гасырга кадәр авылда бары тик Себер татарлары гына яши, 1921 елдан башлап бирегә Казан татарлары да күченә башлаган.

Гаяз абый үзе Башкортстанда туып-үскән. Милләте, әлбәттә, татар. «Әти-әнием Ярмәкәй районындагы Исламбакты авылында яшәгән. Тарих буенча безне Кыр-Еланы волостена кертәләр, ә аңа татарлар 280 ел элек Минзәлә белән Актаныш районнары чигендә урнашкан Бүләр волостеның Мөшегә түбәсеннән күчеп килгән. Шулай итеп Уралның иң соңгы итәгендә яшәгәнбез, бездән соң Оренбург далалары башлана», – диде ул.

«4 нче сыйныфта чөгендер утаган акчага миңа «Шуй» исемле ике рәтле хромка алып бирделәр. Үсә төшкәч, Оренбург базарыннан «Белорусь» исемле гармун алдык. Германиядә хезмәт итеп кайткач, Октябрьский шәһәреннән үземә «Тула» гармунны алдым. Бүген дә шуның белән килдем әле», – дип сөйләде Гаяз абый.

Белеме буенча «сварщик» булгач, армиядән соң, ул Себер якларына эшкә китә. Шунда татар-башкорт театры белән таныша, түгәрәкләргә йөри, һәм үз ансамбльләрен булдыралар. «Беренче мәртәбә Казанга 1990 елда килдем. Ренат абый Ибраһимов татар дөньясында беренче тапкыр «Рамазан» бәйрәме оештырган иде, Төмәннән безнең коллективны чакырдылар», – ди ул. Озакламый ул кабат Казанга килә, ләкин бу юлы инде – музыкаль белем алу өчен. «Мин зур уку йорты бетердем. Тукай урамындагы мәчеттә узган 9 айлык курсларда гармунны кайсы яктан тотырга кирәклегенә өйрәнеп кайттым», – дип, Гаяз абый көлеп алды.

Җыр-моңга сәләт аңарга гаиләсеннән бирелә, дияргә була. «Әтием тальян гармунда да уйный, җырлый да иде, авылның бөтен мәҗлесләренә чакырганнар. Шулай ук ике абыем да гармунда уйныйлар», – диде ул.

1995 елда ул Шыкча авылы мәктәбендә 1-11 сыйныфларга музыка дәресләре укыта башлый, бер үк вакытта клубта да эшли. Тормыш иптәше дә Гаяз абый белән бергә мәдәният йортында хезмәт куя. Әтиләре балаларына да җыр-моңга мәхәббәт сеңдерә. «Улымның югары музыкаль белеме бар. Аның улы туды, исемен Аяз куштык, ягъни бабай булдым. Кызым Төмәндә тәрбияче, шулай ук кайткан саен концертларда катнаша, җырлый».

Хәзерге вакытта Гаяз абый балалар фольклор-этнографик коллективын җитәкли. Аны 2007 елда Шыкча авылы мәдәният һәм ял итү үзәгендә оештырганнар. Алар фольклор-этнографик композицияләрендә Себер татарларының гореф-гадәтләрен һәм фольклорын куллана. Коллектив төрле жанрларда чыгыш ясый, бик зур уңышларга ирешә. Алар Россиянең Самара, Пермь, Чаллы, Казан, Нальчик шәһәрләрендә, шулай ук Казахстанда һ.б. җирләрдә чыгыш ясаганнар. 2014 елда Италиядә узган «Русское лето в Италии» Халыкара балалар фестивалендә беренче урын яулаганнар. «Балалар халык көйләрен җырлап, уен коралларында – кыл кубыз, курай, шыбызгы, ятаганда уйнап, барча итальяннны шаккатырды», – дип искә ала ул.

«Балалар үсә баралар, студент булып китәләр. Хәзерге вакытта яңа гына кергән 4-5 балам бар, 4 буынны укытып чыгардым. Алла боерса, пенсиягә чыккач та эшләргә ниятлим. Миңа яңа гына 58 тулып килә, әле мин япь-яшь, күңелем яшь», – дип көлә Гаяз абый.

«Күпчелек борынгы көйләр онытылып бара, хәзерге яшьләргә гел эстрада, шоу-бизнес кирәк. Ә мине балачактан халык көенә тартты, моңга. Ә хәзер моң югала! Минем максат – шул иске җырларны эзләп табып, яңадан уятып, яшь буынга тапшыру».

Балалар укытудан тыш Гаяз абыйның тагын бер бик яратып эшли торган һөнәре бар, ул – уен кораллары ясау. Алар арасында – курай, көпшә курай, сыбызгы курай, кыл кубыз, ике кыллы домбыра, зур шыбыжгы, кыска шыбыжгы, ятаган... Әлеге уен коралларын хәзер инде эзләп табу да авырдыр.

«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» диелә татар халык мәкалендә. Күрәсең, Гаяз абый бер дә әлеге мәкальне исеннән чыгармаган!

Камилә БИЛАЛОВА
Интертат.
Абдул Фархан фотосы.

«Тик син, тормыш, җырлап кал, яме!»

(Дәвамы. Башы 37, 38 нче саннарда).

«Татарларым!» дип лаф ормады ул, милләтебезгә тугрылыкны саф саклау тойгылары аның күңелендә илаһи бер урын, оҗмахтай төбәк саналган, 7 ел балачагы үткән Иске Кучәрбай авылы, сөекле нәнәсенең «бәп-бәләкәй, ап-ак» өен гомере буена сагыну хисләренә үрелде:

«Бер син, нәнәй, иркәләдең мине,
Бер син көйләп, «бозып бетердең».
Мин кадерле кеше булу бәхетен
Туган йортта гына кичердем...

Минем илем – үткән гомеремме әллә?
Исләремә төшсә, төш күрәм.
И нәнәем! Мин шул төшләремдә
Газиз булу бәхетен кичерәм.»;

«Ничек кычкырыйм: «Сөям!» дип, –
Киттем туган ягымнан...
Мин илемне сагынам тик,
Мин илемне сагынам».

«Кучәрбайда ашаган ипи тәмен Америкада да эзләп карадым», – дип юкка гына белдермәгәндер ул, хикмәт икмәк тәмендә генә дә булмагандыр. Тансыклаткан ул тәм төпкел аңда аяулы балачагы, яклаучы мәлләре, туган авылы, нәнәсе турында хатирәләр уятып, шулай мазасызлагандыр.Үтә туган җанлы иде Нурия. Уфада, Мәскәүдә чакта да өч сеңлесен – Светлана, Венера, Тамараны һаман кайгыртты, иркәләде, тормышларын көйләште, соңрак ике сеңлесенә Америкага күченергә ярдәм итте. Алар инде Кушма Штатларда балалар, оныклар үстерә. Гәрчә андагы көнкүрешнең күп кенә уңайлылыкларын да беркайчан да кире какмый иде Нурия. Американы аның шигырьләре аша гына түгел, үзем барып күрү форсаты да бар иде, югыйсә. Илчелек аша рәсми чакыру юллады ул Лилия Сәгыйдуллина белән икебезгә. Лилия барды, йөреп кайтты. Фәнүзә апам авыргач, мин кузгалмадым. Кызыбыз Нурия студентлар программасы буенча бер җәй Америкада Массачусетс штатының Бостон шәһәрендә булды. Шунда мәшһүр адашында, аның американча албакчалы, ике катлы аерым йортында кунакта да булды.

Шәбрәк чагында Нурия, бакча гөлләремне үзем тәрбиялим, түтәлләрдә, туган яклардагы кебек, яшелчә үстереп тә маташам, дия иде. Америкада юк, дип, хуш исле кара карлыган үсентесен дә алган иде берчак, үстерергә ниятләп. Таможнядан үткәрмәгәннәрдер инде...

Нурия Измайлова Ватанга кайтканда күрештек алай. Аны кунак итү мәшәкатьсез – ризыкны талымламый диярлек. Иң яратканы – икмәк, каз итен, бәлешне хуплый, кара яндырып пешерелгән мәтрүшкәле чәйне кинәнеп эчә. Ашказаны йончыктанга, кефир белән катыкка әвәс.

Кибеткә кереп, икмәкне үзе сайлый иде ул. Ипикәйне бер-бер артлы тотып, иснәп үк карый, хәтта сатучылар аңа шикчел күз сала. Үзе әйтмешли, «мануфактурада» табигый чималдан эшләнгән мамык, йон әйберләрне хушсына.

Бер кайтканында «Кызыл таң»нан Фәния Габидуллина, Лилия Сәгыйдуллина, мин аны Халисә Мөдәрисовага – Нуриман районына, Кызылъяргә алып бардык, ул сәфәр турында Фәния язып та чыкты гәзиттә. Нурия белән Халисә бигрәкләр шатланышты очрашуга. Нурия үзенчәлекле ядкарь – үзеннән салып, муенса белән алкаларын бүләк итте Халисәгә. 2013 елда Нурия Измайлованы, «Сәхибҗамал» татар хатын-кызлары оешмасының кунагы буларак чакырып, «Ихлас» мәчетенең конференцияләр залында җәмәгатьчелек һәм матбугат вәкилләре белән очрашу үтте. Җанлы сөйләшү озак кына барды: җыелганнар якташыбыздан яңа шигырьләрен укуны үтенде, четерекле сораулар да бирде.

Дүрт ел элек, 2019 елның июль башында, Нурия илгә соңгы тапкыр кайтты. Лилия Сәгыйдуллинада тукталды, «Китап» нәшриятында бернечә бик якын ахирәтебез белән генә очрашырга ризалашты. Яшьлектәге истәлекле урыннарны, яңа урамнарны, Габдулла Тукай һәйкәлен иркенләп күрсәтеп йөртте кызыбыз.

– Уфа чибәрләнгән! – дип сокланды Нурия. Бергәлектән, күрешү куанычыннан күңелләр күтәрелде.

Электрон почта аша хәл-әхвәл белешкәләдек ара-тирә. Былтыр ел азагында ул аралашуны ешайтты. Көтмәгәндә гаиләбезгә кагылышлы бер тәкъдим кузгатты. Чынга ашарына өмет тотмаганга, күтәреп алмагач, «Җәһәтлә!», «Бу бик мөһим!», «Яхшылыкка тырышам!» – дип үртәлде. Үкенечле: сүзен эш итеп, уйлаган гамәлен кылыр өчен фани дөньялыкта үҗәтләнеп соңгы ашкынуы, талпынуы булгандыр ул, бәлки...

Шигырендә: «Җырлый-җырлый кереп адаштым», – дип язса да, Нурия Халит кызы язмыш карурманында адашкан көчсез бер зат булмады:

«Мин үзсүзле – агымнарны бордым,
Агым уңаена акмадым.
«Язмыш» дигән сүзне инкяр итеп,
Тормышымны үзем ясадым».

«Мин шәп кунак булсам иде җирдә,
Яки – шәп җыр», –
дип юраганы юш килде шагыйрәнең, аһәңле җыр кебек матур әдәби мирас калдырды ул. Күрәзәчелек итеп, әле яшь чакта ук:

«Мин китәрмен тыныч.
Ә син,тормыш,
Уйнап-көлеп, җырлап кал, яме!..
Мин бит синә гашыйк булып килдем,
Гашыйк килеш китим, җан атып!
Сөеп китсәм,
сагынып тиз кайтырмын,
Гөлләр булып, хуш ис таратып...» –
дигәне дә рас килә. Бәрәмле генә шәхесләребезнең берәүсе, милләтебезнең газизәсе, хатирәләрдә кайтыр ул үзен юксынганнар, аны хәтерләгәннәр, аның иҗатына гашыйклар янына, әсәрләре белән күңелләрдә яшәр, ашкынулы җырларын яшь буыннар яңгыратыр...

Динә МОРЗАКАЕВА.

ЯҢА КӨНГӘ КЕРГӘНДӘ...

Ялкынланып утта яна
чорга язган хатларым.
Җил тарата төтен итеп
хыялларның акларын.
Офык читенә илтә җил
йөрәктә туган моңны,
Тилергән күк, сөрем сөзеп,
уфылдап ала тынын.
Яна-яна тарала моң,
иркен, киң җиһан буйлап,
Әллә җырлап, әллә көлеп,
әллә сулкылдап елап.
Яңа көнгә аяк басам
мең төрле уйлар уйлап...

КӨН БЕЛӘН ТӨН АРАСЫ

Көн белән төн җитәкләшеп
Йөриләр гомер бакый.
Көнен кояш үпкән җаннар
Төнлә йолдыздай балкый.
Кояш кереп калган күңел
Төнгә нур өсти шулай.
...Каршылап яңа таңнарны
Мәңге сайрасын тургай!
Көн белән төн арасы...
Безгә әле барасы...

ЮГАЛТУ

Ярты көнем юкка чыкты,
Күмде вакыт агышы.
«Кайтару мөмкин түгел!» – дип
Дәшә йөрәк тавышы.
Ком кебек чәчелгән минут,
Секундлар китте агып.
Офыкта кояш кызарды,
Җуелды алтын вакыт.
Комны җилдә җилгәрсәң дә,
Кабаттан булмый табып...

ҮПКӘЧЕ

Каш җимереп йөри берәү,
Үпкәләгән кемгәдер.
Баш бирми ул беркемгә дә,
Елмаймый хет көнгә бер.

Әйтерсең лә җуйган кинәт
Яулап алган тәхетен.
Япа-ялгыз кетә җирсеп,
Сыңар күзле бәхетен.

КУАНЫЧ

Кемдер килә... кемдер китә...
Тормыш шундый икән ул.
Берәү яши оя корып,
Гомер тавы – кыя ул.

Кемдер югала, әйтерсең
Чума төпсез чоңгылга.
«Күңел – төпсез кое» диләр,
Ышанамын, чындыр ла.

Кереп кенә чыккан да бар
Бер күз ачып дөньяма.
...Битарафлар читләп үтә,
Шуңа күңел куана.

ҮКЕНҮ

Бар дөньяга хуҗа сыман йөри,
Кесәсендә акча булганга.
Бер елмаю бүләк итә алмый
Очраганда җаны туңганга.

Акча белән үлчи һәр адымын,
Уйлый: «Җирдә бар да сатыла».
Дөнья гамен бар дип белмәгәннәр
Үкенә, баскач әҗәл катына.

Әлфия СИТДЫЙКОВА

Күпме кеше җан җылысы таба Бер шырпы ут салган учакта...

ЙОМЫШЧЫЛАР

Без дөньяда йомышчылар,
Йөгерәбез гомер буе.
Чынбарлыктай күрәбез без
Бу тормышта һәрбер уйны.

Хыял канатларын кагып,
Менәбез без зәңгәр күккә.
Онытабыз килгәнлекне
Әллә азга, әллә күпкә.

Тырышабыз, тырмашабыз
Биек тауга менәр өчен.
Ашыгуны төшенәбез
Җуйгач бары яшәү көчен.

Тәмен белеп һәр мизгелнең
Яшәүчеләр бар микән ул?
Әллә инде туганчы ук
Барчабызга сызылган юл.

Юл тузанын йота-йота
Йөгерәбез гомер буе.
Якынайтып мизгел саен
Гомерләрнең соңгы туен.

* * *

Кыйбламны җуймас өчен җирдә
Сыенганым булды ташка да.
Шуышмадым елан булып һич тә,
Сынаулардан сынган чакта да.

Таш астыннан исән чыккан затлар
Сокландырып яши һәрчакта.
...Күпме кеше җан җылысы таба
Бер шырпы ут салган учакта.

КЫРЫМ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕ

1

Кошлар кышлый торган якка
Талпынды җан гомер буе.
Язмыш насыйп иткәч, илтте
Анда мине һава юлы.

Ак очкычта күккә мендем,
Болытлар да, калмый арттан,
Озата барды җылы якка,
Кулын изәп һәр тарафтан.

Кояш күзли һава юлын,
Нуры керә хәтта җанга.
Башта уйлар... Билгесезлек...
Нәрсә көтә икән алда?

Симферополь. Аэропорт.
Халык белән тулы заллар.
«Хәерле көн барчагызга,
Ямьле үтсен, диләр, яллар!»

2

Томырылып карап каршы алды,
Йөзем үскән Кырым җирләре.
Кипарислар илен күрдем мин дә,
Таш кыяда үскән гөлләрне.

Пальмаларга килеп сарылдым да,
Күзләренә бактым диңгезнең.
Татыдым мин, Кырым, бары синдә
Тансык тәмен илләр гизүнең.

Аюдагның серле сукмагыннан
Эзләдем мин Пушкин эзләрен.
Бакчасарай фонтаныннан тамган
Яшь тамчысын җаным күзләде.

Шаулый диңгез... Әллә серен сөйли,
Әллә җырлый ирек җырларын?!
Шаула, диңгез, тыңлыйм моңнарыңны,
Читкә куып барлык уйларым.

Ял итсен дә җаным, кодрәт туплап,
Кайтсын әле синең яныңнан.
Хыял иде серләреңне ачу,
Яшьлегемнең алсу таңыннан.

Көмеш тәңкә салдым суларыңа,
Күрешербез диеп яңадан.
Арган җанга сихәт өсти торган
Ирек кошын синсез табалмам.

Ярларыңа сыймый чайпаласың,
Чайкаласың минем алдымда.
Кара диңгез, үлеп гашыйк хәлдә
Басып торам синең ярыңда.

Сулар юып тишкән ташларыңны
Җыям учка комлы ярыңнан.
Сагынсам да өзелеп туган якны,
Авыр булыр китү яныңнан.

Күктүбәгә килеп, башым идем,
Волошинның[1] рухы алдында.
Вакыт кыяташка уйган һәйкәл
Шигъриятнең тора сагында.

Кайный икән һаман иҗат йорты,
Җанга бага шигырь күзләре.
Кай тарафка колагыңны салма –
Ишетелә Шагыйрь сүзләре.

Ярылып ята Маринаның[2] эзе,
Блокны да ярлар хәтерли.
Һәр кунактан ядкәр-хатирә бар,
Кырым хәтер саклый, кадерли.

Беркемне дә онытмыйлар монда –
Күпме исем ташка уелган!
Кем килсә дә башын иеп зурлый
Һәм гамь ала дулкын сыеннан.

Чал дулкыннар тарих төпкелләрен
Ничә тапкыр төшеп айкаган?!
Таптым мин дә үзем өчен күпме
Әйтеп-сөйләп бетермәслек байлык
Күктүбәдән, Бакчасараеннан,
Диңгез ярындагы Ялтадан!

Кырым татарлары белән күрешкәндә:
– Ни хәл, кардәш! – дидем, яратып.
Күзләрендә – мәңге бетмәс газап,
Моңнар тулы, ничек таратыйм?!

Курку катыш кызыксыну белән
Ятсынгандай карый күзләре.
Йөрәк түрләрендә йөртә бар да,
Югалтудан калган эзләрне.

Кырым...Кырым...
Җырланмаган җыр син!
Серләр тулы утрау бүген дә.
Синең язмыш – илнең язмышы ул,
Тибрәнә гел халык телендә.

3

Аккошларның канатлары сыйпый
Тынып калган диңгез өсләрен.
Кызганмаган табигатьнең кулы,
Мул кулланган буяу төсләрен.

Яшел, зәңгәр, алсу, көмеш, кара
Төскә кереп, диңгез үзгәрә.
Җил искәндә дулкын арты дулкын
Килеп ята баскан эзләргә.

4

Өрәңгеләр сары. Кипарислар,
Артышлар да мәңге яшелләр.
Яңгыр да юк монда, күк күкрәми,
Күкне телми утлы яшеннәр.

Тулган ай да бездәгедәй түгел,
Таный кебек татар баласын.
Табак кебек айны сагынып йөрим,
Туган якка килеп кайтасым.

5

Кала Кырым: Кизләү һәм Ялита,
Солтансарай, Феодосия.
Саубуллашып Кара дингез шаулый,
«Китмә!» – диеп, елап җил исә.

...Акчарлаклар хушлашкандай, күрче,
Сагышланып канат кагалар.
Шаянланып алга йөгереп килгән
Дулкыннарың елап калалар.

Соңгы кичем монда, иртән – юлга...
Төнге күкне күзли күзләрем.
Сагындырды газиз туган җирем,
Якыннарның тансык йөзләре.

Соң мәртәбә табигатең күзләп,
Матурлыгың җанга салыйм да,
Күңел сандыгында алып китим
Кырым төсен туган ягыма.

Юеш комга төшкән эзләремне
Дулкын юып алыр мизгелдә.
Яңа гамьнәр тәэп китеп барам,
Кабат килер өчен диңгезгә.

[1] *Рус шагыйре, тәрҗемәче, тәнкыйтьче, рәссам.*
[2] *Марина Цветаева.*

КИТӘ КОШЛАР

Каеннар төс үзгәрткән мәл,
Яшел, сары чуклары.
Пәрәвезләр оча җилдә,
Бу – әбиләр чуагы.
Яфракларны түши җилләр
Сары җирнең өстенә.
Дөнья гаме, сагыш-моңы
Сеңгән яфрак төсенә.
Саубуллашып китә кошлар,
Җанда торна тавышы.
Фасыллардай алышына
Гомерләрнең агышы.

Чаллы.

Мәдәни җомга
6 октябрь
№39, 2023

Шәриф БАЙЧУРА:

Галимҗан Ибраһимов

(Истә калганнардан)



Үзбәк Байчура

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 1997 елдан алып Үзбәк Байчура фонды эшләп килә. Фондның төп өлешен 527 китап һәм архив документлары тәшкил итә. Әлеге материаллар 1979–1996 еллар аралыгын колачлый. Фондта Үзбәк Байчураның шәхси китаплары һәм документлары белән беррәттән, галимнең әтисе журналист Шәриф Байчура һәм табибә Әминә Алимбәккә караган материаллар да саклана. Әмма безнең өчен нәкъ менә Шәриф Байчураның үзе белән бәйле истәлекләр кызыклы. Шәриф Байчура – XX гасыр татар журналистикасына зур өлеш керткән, Совет власте елларында актив җәмәгать эшчәнлеге алып барган шәхес. Хезмәтенең башлангыч чорында ук Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Һ.Такташ, К.Тинчурин, Г.Ибраһимов кебек танылган татар зыялылары, талант ияләре белән якыннан таныш булган. Еллар үтеп, үзе дә шактый тәҗрибә туплаган журналист булып җитлеккәч, Шәриф әлеге шагыйрьләр, язучылар белән булган истәлекләрен мәкалә итеп язып бастыра. Бу материаллар барысы да Үзбәк Байчура фондында саклана. Укучылар игътибарына шундый мәкаләләрнең берсен – язучы, галим, публицист, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов белән бәйле хатирәләрне тәкъдим итәбез. Язма 1967 елда «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан. Әлеге истәлек хәзерге заман укучысы өчен дә шактый мавыктыргыч һәм файдалы чыганак булыр дип уйлыйбыз.



● Галимҗан Ибраһимов.

Бу моннан 56 ел элек – 1911 елның җәй башында булды. Мин ул вакытта бер хосусый типографиядә корректор булып эшли һәм шул ук вакытта рус теленнән укытучы булырга хәзерләнә идем. Рус телен мөмкин кадәр яхшырак үзләштерү һем практик яктан да ныгыту теләге белән, ул замандагы татар яшьләренең рус семьяларыннан бүлмә алып, рус укымышлылары белән аралашып торырга омтылулары бик табигый хәл иде. Классик язучыбыз Фатих Әмирханның «Яшьләр» һәм «Урталыкта» дигән әсәрләрендә бу заман яшьләре тормышыннан шундый күренешләр бик ачык тәсвир ителә.

Мин дә бу елны хәзерге Спартак (элекке Әрмәнски) урамының 16 йортында Казан хәрби интендантлыгы чиновнигы Спасский квартирында бер гимназист һәм бер художество мәктәбе укучысы белән берлектә аерым бүлмә алып тора идем. Беркөнне кич белән минем эштән кайткан төшемә хуҗаның өй хезмәткәре: «Сезгә ниндидер бер төргәк калдырып киттеләр», – дип каршылады. Мин, моңа гаҗәпләнеп, кайдан, нинди төргәк китергәннәр дип, бер кәгазь төргәген ачып карасам, ул кайсыдыр типографиядән җибәрелгән корректура булып чыкты. Яхшылап тикшерә торгач, аның шул елларда әдәбият мәйданына чыккан һәм тиз арада күренекле язучы булып үсеп барган Галимҗан Ибраһимовның беренче әсәре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясенең корректурасы икәне беленде. Аның бу әсәре 1907–1908 елларда шәкертләр органы – «Әлислах» газетасында Фатих Әмирханның турыдан-туры булышлыгы һәм редакциясе белән газетаның күп саннарына сузылып басылып килгән иде. Хәзер исә аның аерым китап итеп басылуы икән. Сораштыра торгач, ул корректураның миңа килеп эләгүенең сәбәбе дә аңлашылды.

Г.Ибраһимов бу вакытта шул ук Әрмәнски (хәзерге Спартак) урамында бишенче йортта тора икән. Типографиядән җибәрелгән кыз аны таба алмыйча урамда аптырап йөргәндә, кемдер берәү «Менә бу йортта типографиядә эшләүче бер татар егете тора» дигәч, төргәкне миңа калдырып киткәнлеге беленде. Мәсьәлә ачыклангач, мин икенче көнне кич белән Г. Ибраһимов иптәшне эзләп таптым.

Өй ишеген шакып, сорап кергәч, мине уртача буйлы, озын кара чәчен артка таба шомартып тараган, кара мыеклы, коңгырт кара күзле, өстенә кара сатин күлмәк киеп, биленә киң каеш бәйләгән, чалбар балакларын итек кунычына кертеп кигән мөлаем кыяфәтле егерме биш яшьләр тирәсендәге егет каршылады. Бу – Галимҗан Ибраһимов иде. Аның бу елларда үзенең тышкы кыяфәтен М.Горькийга ошатырга тырышканлыгы күпләргә мәгълүм нәрсә. Минем башыма кылт итеп шул фикер килеп китте.

Г.Ибраһимовның ул вакытларда ук инде демократ табигатьле кунакчыл кеше икәнлеген аны белгән күп кешеләр хәтерли булса кирәк. Ул тиз генә чәй хәзерләтеп алды һәм без – беренче очрашкан кешеләр шактый вакыт төрле темаларга карата сөйләшеп утырдык. Күбрәк ул сөйләде, мин сораулар гына биргәләп утырдым. Бу вакытларда инде аның башлыча «Йолдыз» газетасында байтак кына мәкаләләре чыгып өлгергән, татар әдәбиятының барышы турында еллык отчетлары басылып килә. Шуңа күрә аның фикер ягыннан шактый үскән, мәгълүматы да байтак киң икәнлеге һәр сүзеннән күренеп тора иде. Минем Тукай һәм Фатих Әмирхан иҗатларына карашы турында биргән сорауларыма да ул кыскачарак кына, ләкин уңай җавап бирде, чөнки бу чакта әле ул бу язучыларга карата уңай позициядә тора иде.

Менә шушы күрешүдән соң миңа Г.Ибраһимов белән тагын да очрашкаларга туры килде. Кайчакларда урамда очрашып-сөйләшеп йөрүләр дә булгалады. Бу елны ул һәрвакытта башына котелок (каты кара эшләпә), өстенә соры калын чикмән киеп йөрде. Моннан соңгы елларда инде материаль ягы яхшыра бару белән кием дә үзгәрә барды: җәен күбесенчә панама (эшләпә) өстендә накидка (җиңсез пальто), кышын гади пальто һәм бүрек кия, аякта һәрвакытта күн итек була, йөргәндә ул вак-вак атлап тиз йөри, гәүдәсен төз тота иде.

Революциядән элекке чорда аның белән тагын бер озаклап сөйләшеп утыруым исемдә калган. Бу – 1914 елда, аның «Аң» журналында секретарьлык иткән вакытында булды. Бу чакта ул хәзерге Куйбышев мәйданы ягыннан килеп Щапов урамына кергәннән соң, тау уртасына кадәр менгәч, уң кул якта урамнан ук агач баскыч белән менеп керелә торган 3 катлы дүртенче номерлы йортның икенче катында, хәзер өченче номерлы квартирада дүрт тәрәзәле якты бүлмәдә тора иде. Бу юлы без аңа мәрхүм язучы М.Гали белән барып чыктык. Татар әдәбиятының үсеше, яшь көчләрнең туып күтәрелеп килүе, «Аң» журналының бу өлкәдә зур эшчәнлек күрсәтүе турында шактый озакка сузылган сөйләшү алып барылды. Без китәргә җыенгач кына, Г.Ибраһимовның якын дусларыннан берсе булган Шәһит Әхмәдиев килеп калды. Бу күрешүдән соң Г.Ибраһимов озак та тормыйча Казаннан китте һәм беренче империалистик сугыш елларында ул Уфада «Мәдрәсәи Галия»дә укытучылык итте.

Февраль революциясен ул Уфада каршылап, анда элек «Ирек», аннары «Безнең юл» газеталарында эшли, 1918 елның январендә Петроградка Учредительный собраниегә барып, большевиклар белән берлектә аны ташлап чыга. Казаннан барган Мулланур Вахитов белән бергә Милләтләр халык комиссариаты янындагы Мөселман комиссариатын төзү эшенә катнаша, аның органы булган «Чулпан» газетасының фактик редакторы була һәм 1919 елның җәендә яшерен рәвештә дүрт ай чамасы Колчак тылында йөреп кайтканнан соң, шул елның көзендә яңадан Казанга әйләнеп килә.

Бу вакытта мин «Кызыл Армия» газетасында секретарь булып эшлим. Без тагын очрашабыз. Г.Ибраһимов редакциягә еш кына килеп чыккалый. Бу чорда ул әдәби әсәрләр тудырудан бигрәк публицистика белән шөгыльләнә, революциянең барышына, совет шартларында милли культураның үсешенә карата «Кызыл Армия», «Эшче» һәм «Эш» газеталарында әһәмиятле мәкаләләр бастырып килә. Шуның белән бергә, әдәби әсәрләр язуны да бөтенләй читтә калдырмый. «Яңа кешеләр» (1920) пьесасы, «Кызыл чәчәкләр» (1921) хикәясе шул вакытларда дөньяга чыкты. «Безнең көннәр» романының беренче вариантлары шул 20 нче елда чыкса да, ул асылда революциядән элек язылган иде. Язучы революция тарихына караган хезмәтләр чыгаруда да активлык күрсәтте. «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1922), «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1925) h.б.

1919 ел ахыры һәм 1920 ел башларында мин хәзерге Бауман урамындагы «Бристоль» гостиницасында Галимҗан Ибраһимов белән янәшә бүлмәдә яшәдем. Без еш аралаша идек. Бераздан мин аннан күчеп киттем. Шуннан беркадәр вакыт үткәч, Г.Ибраһимов белән бер очрашкан вакытыбызда ул гостиница тормышыннан туйганлыгын сөйләп, кая булса да квартирага чыгарга теләвен

белән очрашулар



белдерде һәм миннән шул турыда сорашкалап каравымны үтенде. Мин бу вакытта хәзерге Зәйни Солтанов урамы, 12 йортта профессор Газиз Гобәйдуллин әтисе квартирында тора идем, шул ук өйдә хосусый йортлардан учетка алынган торак мәйданнарына ордер бирүче район оешмасы да урнашкан иде. Мин шуннан сорап карарга булдым. Бер-ике көннән Г.Ибраһимов исеменә ордер алдым һәм ул элекке Шиһап Мәрҗани йортындагы (Насыйри урамы, 10) бер квартирага кереп күчеп утырды. Хәзер без тагын күршеләр булдык. Бер атна-ун көн үткәч, мин авылдан хат алдым. Хәзерге Буа районы Аксу авылында укытучы сеңлем авырый икән, кайтып килергә кирәк. Галимҗан минем авылга кайтасымны белгәч: – Көннәр салкын тора, юл ерак, өстең юка, әнә минем даханы киеп кайт, диде. Аның Уфадан алып килгән бу дахасы эче-тышы мехтан, киң, иркен һәм гаять җылы иде. Мин аны кигәч, салкынның нәрсә икәнен дә белмичә, авылдан бик әйбәт йөреп кайттым.

Г.Ибраһимов күпкырлы талант иде: ул әдип тә, тәнкыйтьче дә, тарихчы да, педагог та, тел галиме дә. Шулай ук орфография мәсьәләсе белән дә җитди шөгыльләнде. Шундай бер вакыйга хәтеремдә калган: 1920 елның көзендә (сентябрьдә булса кирәк) Татарстан Республикасы Совнаркомының беренче председателе иптәш Сәетгалиев җитәкчелегендә хәзерге Щапов урамы, 41 йортта (Машкин йорты) татар теле орфографиясе буенча киңәшмә үткәрелде. Бу чорда татар әдәби телендә сузык авазларны алты яки ун итеп санап, бу ике агым вәкилләре арасында көрәш бара иде. Республика күләмендә шул агымнарның кайсын рәсмиләштереп тормышка ашыру мәсьәләсен хәл итү өчен барган бу киңәшмәдә, алты сузык ягындагылар белән ун сузык ягындагыларның докладлары тыңланды. Алты сузыкны яклап, доклад белән Г.Ибраһимов чыкты һәм киңәшмәдән соң алты сузыклы орфографияне кабул итү турында Татарстан хөкүмәтенең декреты чыгарылды. 1925-1927 елларда Г.Ибраһимов иптәш Татарстан мәгариф комиссариаты янындагы Гыйльми Үзәк председателе булып эшләве белән бергә В.Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшенә дә җитәкчелек итте. Мин исә «Кызыл Татарстан» газетасында секретарьлык эшен алып барудан тыш, әнә шул тәрҗемә эшләренә дә катнаша идем. Шул уңай белән тагын еш күрешә башладык. Бу вакытта (1922–1923 еллар) ул хәзерге Ленин урамы 21 номерлы йортта тора иде.

Шул чорда Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү комиссиясенең бер утырышында булган эпизод исемдә калган. Сүз, мәкаль һәм әйтемнәрне тәрҗемә итү турында бара иде. Утырышны алып баручы Г.Ибраһимов: – «Мин үзем, егетләр, мәкальләрне тәрҗемә итү ягында тормыйм. Мәкальләр ул, күбесенчә, һәр телнең үзенчәлегенә бәйләнешле була. Шуңа күрә тәрҗемә уңышлы чыкмый. Кайбер сирәк очракта әйбәт кенә килеп чыгуы да мөмкин. Ә менә бу «львиная доля» сүзләрен «арыслан өлеше» дип тәрҗемә итүгә килгәндә инде (сүз шул турыда бара иде) минемчә, бу начар булмас иде кебек. Чөнки татарчада бу мәгънәне бирә торган мәкаль юк», – диде.

● Татарстан Мәгариф министрлыгы каршында төзелгән Гыйльми үзәк әгъзалары.

Менә шул рәвештә, Г.Ибраһимов, тәрҗемә өлкәсендә һәрбер үзенчәлекле мәсьәләгә карата зур игътибар белән эш итә иде. 1926 ел башында мин нәшрият һәм матбугат комбинатының редакция коллегиясе секретаре булып эшли башлагач, Г.Ибраһимов белән тагын да ешрак аралашу башланды, чөнки бу редколлегиянең председателе Сафа Борһан булса да, мәгариф комиссариаты вәкиле буларак бу коллегиядә член булып торган Г.Ибраһимов үзенең бу өлкәдәге зур тәҗрибәсе һәм авторитеты белән нәшрият планнарын төзүдә һәм башка төп мәсьәләләрне хәл итүдә үзәк рольне уйнап килде. Бу вакытларда аның миңа телефоннан шалтыратмаган көне аз булгандыр.

Шулай ук ара-тирә аның өенә дә барып чыккан вакытлар булгалады. Мәгълүм булганча, бу елларда (1923–1927 еллар) ул хәзерге Комлев урамы, 33 йортта тулы семья тормышы белән яшәде, һәм исәнлеге начарлана башлагач, Кырымга да шул квартирасыннан күчеп китте. Аны озак вакытка Казаннан аерган бу ерак сәфәргә озатучылар арасында бу юлларны язучы да бар иде.

Текстны басмага Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты Гөлнирә ХӨСӘЕНОВА әзерләде.

«Фәнни Татарстан» журналы. 2022. №1.

ДӨЯ КҮЗЕ

Чыңгыз АЙТМАТОВ

(Дәвамы. Башы 35, 36, 37, 38 нче саннарда).

Без трактор ышыгында, җирдә сөйләшми генә утырып торабыз. Әбәкер, ачулы бер кыяфәт белән папиросын чәйни-чәйни, тәмәке тартты, аннары комбинезоны белән күлмәген салды да киемнәре өстенә кояшта кызынырга ятты. Аның аркасы куна тактасы шикелле киң, таза, елкылдап тора иде. Минем дә кояшта кызынасым килеп китте. Күлмәгемне салып, җиргә җәя генә башлаган идем – Әбәкер эсседә мәлҗерәгән ачулы бер чырай белән миңа күтәрелеп карады да:

– Арканы кашы! – дип боерды. Аның кушканын хәзер үк үти башлармын дип уйлап, ул авыр башын беләкләре өстенә салды.

Мин эндәшмәдем.

Әбәкер, башын күтәрмичә, усал гына итеп җилкәләрен селкеткәләде дә:

– Ишетәсеңме? – диде.

– Кашымыйм! – дидем мин.

– Ә мин әйтәм, кашыйсың! – Әбәкер, капыл гына беләкләренә күтәрелеп, миңа таба тартылды. – Йә, күпме көттерерсең?

Шулчак аңардан читкәрәк шуыштым да:

– Син һәрвакыт, «мин эшче дә мин эшче!» дип, күкрәгеңне төясең. «Мин бөтен кешене, бөтен дөньяны ашатам» дисең... Син эшләгәнгә күрә генә эшче бит, ә җаның синең эшче җаны түгел. Синдә бай булырга кирәк булган, – дидем.

– Булыр идем шул! Ә син минем җанымны тикшермә! – диде дә Әбәкер искәрмәстән генә борыныма чиертте.

Мин сикереп тордым да, кулларымны йодрыклап, аның өстенә ташландым. Әйтерсең Әбәкер шуны гына көтеп торган иде. Соңгы көннәрдә миңа карата җыеп килгән ачу-нәфрәтен ул берьюлы чыгарды – бөтен көче белән каты итеп сугып җибәрде, мин җиргә тәгәрәп киттем. Шуннан соң көчкә-көчкә торып тезләндем дә, ачу-ярсуымнан берни белештермичә, тагын Әбәкергә ташландым. Ул суккан саен мине аяктан ега торды.

– Йодрыгымның тәмен татытыйм әле мин сиңа! Җанымның нинди икәнен күрсәтим әле! – дип сөйләнде ул, мине дөмбәсли-дөмбәсли.

Ләкин аның саен сикереп тордым да, тешемне кысып, зәһәрләнеп, Әбәкер өстенә ташландым. Аның битенә, ерткыч танавына сугарга тырыштым, ә ул, катырак эләксен дип, минем эчемә, кабыргаларыма, күкрәгемә сукты.

Менә тагын аягыма торып бастым да әкрен генә аның өстенә килә башладым. Әбәкер кулын күтәрде дә, ит чабучы балта белән кизәнгән шикелле, «һы!» дип көчәнеп, йодрыгы белән муен тамырыма китереп салды. Мин, ыңгырашкан авазым чыкмасын дип, иренемне тешләп, җирдә ята башладым.

– Ятасыңмы, Академик! Йә, җирдән нинди ис килә, иснәп кара инде! Бу сиңа таш сыннар турында лекция уку түгел, – дип сөйләнде Әбәкер, мышный-мышный авызыннан кан төкереп.

Ул безнең аяк астында тапталып беткән киемнәре янына китте дә, алып каккалагач, зур бер эш башкарган шикелле бик канәгать төстә ашыкмыйча гына киенергә кереште. Шулай да бу сугышта да мин җиңеп чыкканлыкны аңламады ул. Әйе, җирдә егылып ятсам да, җиңелмәдем. Мин дөреслек өчен йодрык белән дә сугышырга мөмкин икәнлеген аңладым. Үзеңне кыйнаган кешене кыйнарга мөмкин һәм кыйнарга кирәк икәнлеген аңладым. Минем өчен җиңү, өстен чыгу иде бу...

Әбәкер комбинезоны эченә кереп ашыкмый гына киенгән арада тордым да, тиз генә киенеп, сабан өстендәге урыныма барып утырдым.

Трактор үкереп эшли башлады һәм бераздан буйлап кузгалып китте. Кабина тәрәзәсеннән һаман шул үз киресенә каткан таза муен күренә, мин дә кулларым белән сабан штурвалына ябышкан шул ук прицепщик идем.

4

Безнең тормышта кайбер үзгәрешләр булып алды. Безгә, сукалаган җиргә чәчүлек орлык ташу өчен, тракторда пар ат җигә торган арба һәм ике ат китерделәр. Ат тотучы бер кеше дә килде. Шулай итеп, хәзер су ташучының эше җиңеләя төште. Садабәк белән Әсәркәп тракторларын чәчүгә күчерделәр, без Әбәкер белән сөрүдә калдык.

Тагын бик мөһим бер яңалык бар икән әле.

Моннан берничә көн элек, төштән соң атка утырып кырга барганда, чишмә янында теге сакманчы кызны күрдем. Арбадан сикереп төштем. Ат тотучы егет атларны туктатып тормакчы булган иде дә, Әбәкер туктаттырмады.

– Әйдә, тоткарлама, – дип кенә боерды ризасыз бер кыяфәт белән.

Мин кызга таба йөгердем, кыз да, сарыкларын калдырып, миңа каршы килә башлады. Шулай да мин аның янына ук барып җитә алмадым, эш башлануга барып өлгерер өчен, арбадан калмаска кирәк иде. Шуңа күрә туктадым да кызга:

– Исәнмесез! – дип кычкырдым.

Кыз да, туктап:

– Исәнмесез! – дип җавап кайтарды.

Аны күрүемә бик сөенсәм дә, нәрсә дип сөйләшергә дә белмәдем.

– Нигә сезнең сугә килгәнегез күренми, сез кайда хәзер? – сорады кыз.

– Мин хәзер тракторда йөрим! – дип горурланып җавап кайтардым. – Без әнә теге кырда! Гафу итегез, мин бик ашыгам!

– Йөгерегез, йөгерегез! – дип, кыз кул селкеп калды.

Мин арба артыннан йөгердем. Бер генә тапкыр артыма әйләнеп карадым. Кыз шул ук урынында баскан да миңа карап тора иде. Арба туктап-туктап ала. Инде хәзер йөгерүе җиңел, рәхәт иде. Кызның кул селкеп калуы, үземнең ягзы иркен дала буйлап әнә шулай йөгереп баруым һушларыма киткән иде минем...

Иртәгесе көнне дә ул безнең кыр янында күренде. Бәрәнле сарыкларын көтеп, бездән әллә ни ерак булмаган калкулык битендә басып тора иде. Аның янына бер генә минутка бик барасым килсә дә бара алмадым – Әбәкер мине анда җибәрәме соң, андый яхшылык эшли торган кешеме соң ул?

Кыз икенче тапкыр әлеге калкулык битендә күренгәндә, без Әбәкер белән трактор янында басып тора идек, ул моторның нәрсәсендер тикшерә-карый иде.

– Нишләп бик еш килә башлады әле ул? – дип сорады Әбәкер.

– Белмим, – дидем мин.

– Ни исемле ул?

– Анысын да белмим.

– Их син, Академик! – дип, Әбәкер мыскыллы бер кыяфәт белән төкереп куйды да кызга таба карады. – Татлы нәрсәкәй күренә...

Мин ачу белән Әбәкергә күтәрелеп карадым.

– Бар, урыныңа утыр! – дип акырды Әбәкер, һәм шуннан соң без кузгалып киттек.

Ул арада кыз сарыкларын калкулык битеннән яланлыкка, безнең кырдан йөз адым чамасындагы ачык җиргә куып китерде. Их, янына барып бераз сөйләшсәң, маңгаендагы матур чәч чугына карап утырсаң икән...

Трактор кинәт туктады.

Әбәкер, кабинадан башын чыгарып:

– Рычагны беркет! Үзең монда кил! – дип кычкырды.

Мин сабан өстеннән төштем дә, аптыраган-гаҗәпләнгән хәлдә, Әбәкер янына киттем. Эшләгән чакта ул мине кабинасына кертми иде моңарчы.

– Утыр. Йөртергә өйрән, – дип, ул миңа үзенең урынын бирде.

Мин шаккаттым. Мондый хәлне һич көтмәгән идем аңардан. Әбәкергә ни булган, әллә миңа мөнәсәбәте үзгәргәнме? Шулай да, әллә ни озак уйланып тормастан, ул кушканнарның барысын да эшләргә әзерләндем.

– Педальгә бас. Сцеплениене тоташтыр. Менә шулай. Хәзер әкрен генә педальне җибәр. Фрикцион рычагларын тот...

Трактор үкерә-үкерә кузгалып, җир сөреп китте. Мин шатлыгымнан тын ала алмас булдым. Берни турында уйламадым, дөньядагы бернәрсә дә уема керерлек түгел иде. Күңелемдә бары бер генә теләк: тракторны йөртергә өйрәнү, аның механизмнарын белү теләге генә иде. Кайчаннан бирле шуңа омтылып, хыялланып йөрим бит инде! Менә хәзер куәтле машина, минем кулга буйсынып, тимер табаннарын шалтыратып үрмәли-үрмәли китеп барды. Кирәкле хәрәкәтләрне төгәл эшләү турында гына уйлап, үзем дә әйтерсең бер механизмга әйләндем.

Җир башында тракторны ярыйсы гына бордым шикелле. Дөрес, прицепщик булмагач, борылышта шактый чи урыннар калды калуын. Ләкин анысы әллә ни зур бәла түгел: Анархайда җир җитәрлек әле! Аның каравы мин трактор йөртергә өйрәнәм бит!

Шул рәвешчә без берничә буй әйләндек. Йөрәгем инде хәзер ул хәтле каты сикерми, үземне батыррак тоя башладым.

– Куркып калма, Академик! Мин беравыкка гына барып киләм. Ул-бу булса, моторны сүндерерсең!.. – дип кычкырды Әбәкер колагыма.

Трактор барган шәпкә җиргә сикереп төште һәм, өс-башын каккалап, төзәтенә-төзәтенә сакманчы кыз янына китте. Кыз хәзер безгә якын гына иде. Әбәкернең ниятенә бары тик хәзер генә төшендем. Кабинага ул мине тикмәгә генә утыртмаган икән.

Әбәкер, бернидә дә гаме булмаган кебек, кыз белән иркенләп сөйләшеп тора. Нигә иркенләмәсен!.. Эше эшләнә, трактор якын гына, ул-бу булса, хәзер йөгереп килеп җитә.

Әбәкернең бу хәйләсе ошамады миңа. Әмма шул ук вакытта шатлыгым да бик зур иде – машина хәтле машинаны үзем йөртәм бит! Кызга кабинадан кул болгыйсым, берәр матур сүз әйтәсем килеп күңелем кытыкланып тора. Их, монда Әбәкер булмаса! Кызга нәрсәләр сөйләнә икән ул анда, кыз ни дип җавап кайтара икән? Кызга аның янында саграк булырга, артык ачылып китмәскә кирәк иде бит...

Кыз сарыкларын кире куып алып киткәнче, мин сәгать ярымлап трактордан төшмәдем. Әбәкернең чыраеннан эше уңганлыгын сиздерерлек бернинди билге күрмәдем. Әйе, аның чыраенда гадәттәге тупаслыгыннан башка нәрсә сизелми иде.

Әбәкер:

– Бар, Академик, үз урыныңа! – дип, җилкәмә шапылдатып сукты да авызын кыйшайтып көлгән булды.

Мин бер сүз дәшмичә, трактордан сикереп төштем.

Кызыбыз икенче көнне дә килде. Әбәкер, тагы мине кабинага утыртып, үзе кыз янына китте. Кыз монда килеп йөрмәсә яхшырак кына булыр иде. Мин тракторны ташлап китә алмыйм, шул ук вакытта бу хәлгә битараф та кала алмый идем.

«Кисәтеп куярга иде бит аны. Әбәкер белән очрашырга ярамый аңа. Ләкин кешеләрне үзара сөйләшүдән тыеп буламы соң? Кем белән эш иткәнен кеше үзе белергә тиеш...» – дип уйландым мин, кабинадан алар ягына борчулы караш ташлап.

Бу юлы кыз бик тиз китеп барды. Бу хәлгә бик сөендем мин. Кыз, артына да әйләнеп карамыйча йөгерә-йөгерә, сарыкларын дала буйлап куып китеп бара иде. «Кичер, сөеклем, — дип күңелемнән гафу үтендем мин аннан. – Тиз китүең бик әйбәт булды. Без синең белән кабат очрашырбыз әле. Икенче тапкыр тракторга утырмам, синең яныңа йөгерермен. Ә хәзергә китә бир, туктама, чибәр кыз... Мин бит әле исемеңне дә белмим...»

Әмма мин, кабат очрашырбыз әле дип, юкка гына өметләнгәнмен икән. Шуннан соң кызыбыз бүтән күренмәде. Без аны өч көн буе икәүләп көттек. Билгеле, моны бер-беребезгә белгертмәдек. Әбәкер гадәттәгедән усалрак, тупасрак булды. Миңа тагын ачыктан-ачык дошманлык белән карый башлады. Ләкин хәзер инде мин дә үземнең нәфрәтемне яшермәдем. Аның ничектер кызны рәнҗеткән булырга тиешлеген аңладым, кызны нинди дер яман, әшәке нәрсәдән саклап кала алмаган сыман, үземне аның алдында гаепле хис иттем.

(Дәвамы киләсе санда.)

(Дәвамы. Башы 38 нче санда).

Йолдызсыз калган татарлар

Башкортстанның Ярмәкәй районы Суккул авылында 1918 елда туган капитан **Нагаев Мөэмин Кәрим улының** бик тә сәер һәм гыйбрәтле язмышы турында, бәлки, авылдаш-якташлары ишетеп тә белмәдер. Уен түгел, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә, санга саналмаган, лаек даннан коры калдырылган бөек каһарман ул!

М.Нагаев Туймазы комиссариаты тарафыннан 1939 елның сентябрендә Кызыл армия сафларына чакырыла. 1941 елның декабрендә Уфада 112 нче Башкорт кавалерия дивизиясен туплау башлангач та, 76 миллиметрлы орудие командиры итеп билгеләнә. Украинаның Чернигов өлкәсендә Десна елгасын кичү һәм Березна каласын штурмлау вакытында Нагаев батареясы 60 нчы гвардия кавалерия полкының каршылыксыз алга баруына ярдәм итә. Аның батареясы дошманның 3 танкын, 2 автомашинасын, 2 туп, 6 пулемет ноктасын, 170 кә якын солдат һәм офицерын юк итә. Днепр елгасын кичкәндә чагында һәм украиннарның Вяле, Нивки, Гале хуторларын азат иткәндә әлеге батарея тагын гитлерчыларның 1 тубын, 4 пулемётын, 2 миномёт һәм 200 гә якын солдатын юкка чыгара. Днепрны кичкәч, Любеч районында батарея туры наводка белән атып, гитлерчыларның 1 туп, 6 пулемёт, 4 дзот һәм 40 тан артык солдатны юк итә. Шушы батырлыклары өчен Мөэмин Нагаев 1943 елның октябрендә беренче мәртәбә Герой исеменә тәкъдим ителә, ләкин аңа, штабтагы ыштан туздыручылар тырышлыгы белән, «Кызыл байрак» ордены өчен генә Аллаһы әппәр итеп куярга туры килә.

Аннары 1945 елның февраль аенда кавалерия дивизиясе инде Германиянең Бралентин (хәзер Арнсвальд) шәһәрен азат итү өчен яуга керә. Нагаев батареясы 15 танк һәм үзйөрешле «Фердлинандлар» белән ныгытылган немец батальонының 5 һөҗүмен кире кайтара, 200 гә якын гитлерчыны юк итә. Үзенең сафтан чыккан орудиясен яңага алыштырып, Нагаев дошманның 3 танкын юкка чыгара. Батареядагы барча туплар сафтан чыгып беткәч, Нагаев солдатлары әле 6 сәгать буе туктаусыз яу алып бара. Яу ахырында чолганышта калсалар да, Нагаевныкылар үзебезнең сугышчылар янына исән-имин көе әйләнеп кайта. Әлеге яудагы батырлыклары өчен Мөэмин Нагаевны инде икенче мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп карыйлар. Ләкин кабинет түрәләре янә татар каһарманын Ленин ордены белән генә бүләкләп куя.

Нагаевның февраль аенда ирешкән җиңү кадере вермахт документларын актарганда тагын да гаҗәпләндерә. Бактың исә, герман армиясенең ФАУ-2 реактив снарядлары белән коралланган төп армия резервындагы 962 нче артеллерия полкы нәкъ менә шушы Бралентин районында урнашкан булган икән бит! Әгәр Нагаев тупчылары җимереп өлгермәсә, ул ФАУ снарядлары совет гаскәрләре өстенә очасы булган!..

Мөэмин Нагаев туган ягына Җиңү яулап, күкрәген Ленин, Кызыл байрак, Кызыл Йолдыз, Ватан сугышы, Александр Невский орденнары белән бизәп кайта.


п. гл. №3043
НГРАДНОЙ ЛИСТ
1. Фамилия имя отчество Нагаев Мугин Керимович
2. Звание Гвардии Капитан Должность, часть [illegible]
3. Представляется к присвоению звания „Герой Советского Союза"
4. Год рождения 1918 г. Национальность башкирин партийность [illegible]
5. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите С.С.С.Р. в отечественной войне / где, когда. [illegible]
6. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне [illegible]
7. С какого времени в красной армии с 9.1939
Каким Р.В.К. призван Туймазинским РВК БАССР
8. Чем ранее награжден /за какие отличия [illegible]
9. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

В бою 16. 2. 45. в районе Бралдентин стоя на противотанковом опорном пункте отразил пять атак немецкого батальона поддержанного пятьнадцатью танками и одним фердинандом и уничтожил до двухсот солдат и офицеров противника. Когда расчет трех его орудия был выведен из строя тов. Нагаев стоковясь у 3го орудия лично сожег три танка и один фердинанд, несмотря на то, что все орудия были выведены из строя, занимаемого рубежа не оставил, собрав десять человек красноармейцев продолжал бой в течении шести часов в окружении с ручной гранатой в руке с криком „Ура, Черниговцы не отступают" бросился в контр/атаку и отбил шестую атаку немецкой роты, истребив из стрелкового оружия св. 70 солдат и офицеров, пробился из окружения и присоединился с третьим эскадроном 58 Гв. к.п.
[illegible] звания "ГЕРОЙ СОВЕТСКОГО СОЮЗА."
[illegible]
гвардии подполковник / Х абаров /
Достоин присвоения звания „Герой Советского Союза"
Командующий Артиллерией 16 кд
Гвардии Полковник / [illegible] /

Гыйззәтуллин Кәшфулла Гыйззәтулла улы, ул да 1903 елда Башкортстанның Туймазы районында туган һәм 1941 елның декабрендә 112 нче Башкорт (соңыннан 16 нчы Чернигов гвардия) дивизиясе составында фронтка озатылган. 58 нче гвардия кавалерия полкында миномёт расчеты командиры, сержант булып хезмәт итә. 1942 елның 24 апрелендә тәүге яуга керә, 6 декабрьда яралана. «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә. Днепр елгасын кичкәндә дошманның пулемёт нокталарын юк итә.

Украинаның Чернигов өлкәсендәге Галки авылын саклаган чакта 1943 елның 29 сентябрендә дошман ике мәртәбә совет плацдармын штурмлап карый. Дошман туктаусыз рәвештә туптан дәһшәт чәчеп торуга карамастан, Гыйззәтуллин аларның 2 станоклы пулемётын, 2 минометын һәм сугыш припаслары тутырылган 2 арбасын юкка чыгара. Шушы яудагы каһарманлыгы өчен Кәшфулла Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин аны «Сугышчан Кызыл байрак» ордены белән генә йомып куялар. Кәшфулланың Герой исеменә тәкъдим ителүен авылдашлары, мөгаен, белмидер дә.


Вх №14142
23.10.4[illegible]
Все графы заполнять полностью
НАГРАДНОЙ ЛИСТ
1. Фамилия, имя и отчество Гизатуллин Нагифулла Гизатуллинович
2. Звание Гвардии Сержант 3. Должность, часть командир миномётного расчета 58 гвардейского кавалерийского полка 16 гвардейской Черниговской кавалерийской дивизии 7 гвардейского кавалерийского корпуса
Представляется к „Званию Героя Советского Союза"
4. Год рождения 1903 5. Национальность башкир 6. Партийность чл. ВКП(б)
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и отечественной войне (где, когда) в отечественной войне с 24.04.42 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне ранен 6.12.42 г.
9. С какого времени в Красной Армии с декабря мес. 1941 10. Каким РВК призван Туймазинским РВК Баш. АССР
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Орденом „Красная звезда"
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг
[illegible]
Командир 58 гв. кав. полка
гв. подполковник / Кусаков /
Командир (начальник)
9. Октября 1943 г.

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.

«Миллиард татар» челтәреннән. **Вахит ИМАМОВ** тәрҗемәсе.

Уй-тойгы, хисләрне, шатлык-сөенеч, көенечләрне аңлатуның төрле юлалымнары бар. Безнең әби-бабаларыбыз да гасырлар буе кайгы-шатлыкларын, әкияти хыялларын, яулап алынган җиңү-уңышларын, уй-хисләрен үзләренең бию хәрәкәтләре белән дә тасвирлаган. Биюләр кешелек дөньясы барлыкка килгән заманнардан бүгенгәчә килеп җиткән. Ерак гасырларда халык үзенең иҗтимагый көнкүрешен, хезмәтен, төрле гореф-гадәтләрен, йолаларын биюгә салган. Яңа биюләр борынгы бию традицияләре нигезендә барлыкка килгән дә инде.

БИИ-БИИ МЕНӘР

Язмабызның герое – тугыз ел буе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артисты, профессиональ эшчәнлеген хореография сәнгатен саклау һәм популярлаштыруга багышлаган Владислав Уткин. Владислав – балет артисты, балетмейстер гына түгел, хореография сәнгатен фәнни һәм практик өйрәнүче дә.

В.Уткин 1991 елның 3 октябрендә Түбән Кама районының Олы Аты авылында дөньяга аваз сала. Алар гаиләдә һәрвакыт татарча сөйләшә. 2014 елда Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлагач, аны Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә чакыралар.

«Мәктәптә укыган вакытта үзешчән коллективта биедем, җитәкчебез Ирек Зиннәтулла улы Наскаев – профессиональ балетмейстер. Ул да миңа укырга керергә булышты. Институтта укыганда хореография бүлегенең деканы Владимир Горшков, кафедра мөдире Таһир Латыйфуллин булды. Укый-укый Таһир Максум улы җитәкләгән «Сәйдәш» бию коллективында биедем. Укытучым Сергей Дементьевич Сентябов «чечётка» элементларын өйрәтте, соңыннан үзенең аяк киемен дә бүләк итте», – дип сөйләде егет, үткәннәргә кайтып.



«Кешелек җәмгыяте барлыкка килгәч җыр, бию, сүз туган. Тора-бара халкыбызның сюжетлы биюләре иҗат ителеп, туйларда, уеннарда, җыеннарда башкарылган. Элеккеге чорларда татарларга биергә ярамаган, качып, мунчаларда, соңыннан аулак өйләрдә биегәннәр. Вак-вак хәрәкәтләр булган. Без инде биючеләр, шул вак хәрәкәтләрне киңәйтеп биибез. Вакытлар узу белән сәхнәгә тәүге биюләр куела, биючеләр дә данга күмелә башлый», – дип ул бераз бию сәнгатебезнең тарихы белән дә таныштырып үтте.

«Чакыру алса да, баштарак Владиславның ансамбльгә киләсе килмәде, чөнки укыган чорда ук ул «Сәйдәш» бию коллективына йөри иде. Ансамбльдәге тотрыклы режим баштарак куркыткандыр, – дип сөйләде егет турында Татарстанның халык артисты, балетмейстер Ләйсән Хәмитова. – Мин аны юкка гына чакырмадым, ул белгеч-биюче буларак әзер иде. Булачак хатыны Айгөл белән икесен дә коллективка алдык. Айгөл – чын татар кызы. Владислав җиңел аралаша, эшкә җаваплы карый, табигатьтән килгән артистлык сәләте, шаянлык бар үзендә, күңеле хисләргә бай, бию хәрәкәтләренә педантларча әһәмият бирүе, намуслылыгы, әдәплелеге күңелемә хуш килде. Валерий Кузнецов репертуарыннан Фәйзи Гаскәров куйган «Җизнәкәй» биюен ул үзенчә башкарып, кирәкле образны табуга ирешә. Владислав бии башласа, ару-талуны белми. Аннары яңа номер куюны сорагач, озакка сузмыйча, С.Садыйкованың «Казан кичләре»н балетмейстер буларак яңача, заманча итеп сәхнәләштерде. Киләчәктә талантлы балетмейстер, актер, педагог та булыр, чөнки шәп биючеләрдән генә яхшы педагоглар чыга. Коллективта аны гадел булуы өчен хөрмәт итәләр, татарча камил сөйләшүе дә аңа карата хөрмәт уята. Минемчә, ул ансамбльдә матур идеяләр таратучы булыр. Р.Гарипова куйган «Кызлар җыены» композициясендә ул гармунчы кызны шундый ышандырып уйнап бии ки, аның егет кеше икәнен соңыннан баш киемен салгач кына күрәсең. Барлык биюләрдә дә ул – солист. Кая, нинди биюгә билгеләсәң дә, бер сүзсез риза була һәм югары дәрәҗәдә башкарып чыга.

«Мәдәният һәм сәнгать институтында кафедра мөдире булган чакта ук Владиславның тырышлыгын, эзләнүен күреп сокланган идем, – дип сөйләде ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов. – В.Уткин төрле проект, конкурсларда катнаша. Кеше буларак та яхшы күңелле,



ҮРЛӘРГӘ...



ипле, хөрмәткә лаек. Хатыны Айгөл белән алар ансамбльдә дә бергә. Владиславның белем дәрәҗәсе югары – аның белән төрле темаларга сөйләшеп була. Хореография тарихын да яхшы белә. Егеттә артистлык осталыгы көчле – Кавказ халыклары, башкорт биюләрен һ.б. яхшы ала, техник алымнарны төгәл башкарып сокландыра. Һәр образы үзенчәлекле. Комик биюче буларак та егет үз юнәлешен тапты. «Кияү» биюенә, һәр башкарган саен, яңа төсмерләр кертә. Сәхнәгә ул йолдыз кебек балкып чыга, тамашачыны энергитекасы, магниты белән үзенә җәлеп итә һәм үзеннән җибәрми тота белә.

«Владислав ансамбльгә әзер булып килде, – диде егет турында күп еллар ансамбльнең репититоры булган Татарстанның атказанган артисты Рәйсә Хәсәнова. – Тамашачы белән яхшы эшли, күзләре янып торган күмер кебек. Тамашачы аны күз уңыннан җибәрми, аның белән бергә бии сыман. Хатыны Айгөл белән бик пар килгәннәр, ике бала үстерәләр. Ул биюче генә булып калмас, киләчәктә аннан оста бию куючы да чыгар әле. Биюләрнең милли колоритын саклап, хәрәкәтләрнең вак кына нюансларын да төгәл итеп башкара белү сәләте аеруча әһәмиятле. Владислав бүген коллективның иң яхшы артистларының берсенә әверелде. Үз көченә ышану, һәрдаим белемен арттыруга омтылу, яңалык эзләү Владиславны бик күп яшьләрдән бер баш югарырак күтәрә».

«Татарның бию сәнгате мәдәниятебез формалашкан вакытта үсеш алды. Хореографияне башка сәнгать төрләреннән аерып карап булмый, әлбәттә. Шуңа күрә дә ул этрафлы, һәрьяклап өйрәнүне таләп итә. Көй-музыкадан башка бию була алмый, шуңа күрә без биюнең музыкасын да ныклап өйрәнергә тиешбез», – ди Владислав үзе.

В.Уткин – халыкара, Бөтенроссия конкурслары һәм фестивальләрендә җиңүче һәм лауреат. Мәсәлән, 2019 елда Грозный шәһәрендә узган М.Эсамбаев исемендәге халыкара фестивальда «Аерым бию» номинациясендә беренче дәрәҗә лауреат, 2021 елда Ярославльдә үткәрелгән балет һәм хореография артистларының Бөтенроссия конкурсында «Халыкчан сәхнә биюе» төрендә өченче дәрәҗәле лауреат була һ.б.

Фәнни эшләр өлкәсендә Владислав Геннадьевич V Бөтенроссия фәнни-практик конференциядә «Балет һәм хореография үсешенең актуаль мәсьәләләре» катнаша (Мәскәү); II Бөтендөнья фәнни-практик конференциядә «Теория һәм практика актуаль мәсьәләләрен фәнни күзлектән карау» дипломы белән бүләкләнә. Аның басылып чыккан хезмәтләре дә байтак. «Бию процессын язу мәсьәләләре», «Бию рәсемнәренең электрон язмасы» кебек авторлык проектларын алар Айгөл белән бергәләп эшли.

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концертлар залында шагыйрь Хәсән Туфан иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәдә В.Уткин биюнең төрле элементларын кулланып биеде һәм җырчы, композитор С. Садыйкованың «Казан кичләре» җырына бию куйды.

Хореограф буларак Казан мэриясы ярдәмендә оештырылган «Хәрәкәттә бәрәкәт» проектында катнашты, «Ярмәк вагы» буенча осталык дәресе үткәрде, шәһәр паркларында һәм скверларда биеде, шулай ук Казан шәһәренең мәктәпләрендә татар биюен балаларга өйрәтте. Владислав Геннадьевич «Калеб», «Шаян ТВ», «Манзара» телетапшыруларының, «Туганайлар» газетасының һәм «Тәртип» радиосының даими кунагы.

«Балетмейстер сыйфатында биюләр, спектакльләр куясым килә. Әмма моның өчен тәҗрибә зур булырга тиеш. Классиканы да яхшы белү сорала. Бию сәнгатендә миллилекне югалтмыйча, аны заманча камилләштерү мәсьәләсе җитди хезмәт булып тора», дип хыяллары белән уртаклашты әңгәмәдәшем. Шундый зур планнар белән яши биючебез.

«Җырның моңы булган кебек, биюнең дә – үз моңы, үз аһәңе. Шул моң-хисне җаны-тәне белән тоеп йөрәгеңә салу кирәк биючегә», – дип кабатларга ярата иде ансамблебезнең иң беренче биючеләреннән булган легендар биючебез Мансур Гатиатуллин. Бу сүзләр безнең язмабыз герое Владислав Уткинга да туры килә.

Филүсә АРСЛАН.

ТАТАР ҖАЙДАКЛАРЫ

● **Мишәр полкларындагы обер-офицер һәм казак.** А.В.Висковатов эше.



● **«Башкорт–мишәр» гаскәрендәге кием формалары. 1.Рядовой җайдак. 2. Обер-офицер. 3. Мишәр урядникы, 1829-1838.** А.В.Висковатов эшләре.

(Дәвамы. Башы 38 нче санда).

Күңеле сукыраймаган кешеләр ул 3000 яугирнең ким дигәндә яртысы татар яки мишәр булуын җиңел аерганнар. Командада башлыкларының да күпчелеге – татар. Ә башкорт мөтәгалимнәре барыбер «Польша походында башкорт гаскәре катнашкан», дип күкрәк суга бирә. Янә бер кабатлыйк: азатлык өчен көрәшүче ләһ дусларны изү-кыру өчен оештырылган кан коюда катнашу – һич горурлык түгел. Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Патша хакимияте таләп иткәч, башларын түбән иеп, татары да, башкорты да барган.

Беренче партия Уфа каласыннан 1771 елның 16 декабрендә чыгып киткән булса, соңгы команда 1772 елның 4 гыйнварында кузгалган. Җәй башында генерал Урусов канаты астында Вильно һәм Краков калалары янында фетнәче полякларның зур гаскәрен тар-мар итүдә катнашканнар. «Җиңүгә» ирешкәч, Хәрби коллегиянең 25 августтагы фәрманы буенча, 2000 җайдак Уфага кайтырга юл ала. 4 нче, 8 нче һәм 9 нчы командага тупланган 933 җайдакны (старшиналары: Әлшәйдән Кәип Җыямбәтов, бүгенге Олы Ака төбәгеннән Исәкәй Садиров, Казан юлындагы татар волостьларын җитәкләгән Зөбәер Йосыпов) Польшада «тәртип саклау өчен» калдыралар, әмма алары да 1773 елның көзендә ашыгыч рәвештә Казанга кайтарыла. Бактың исә Җаек буенда Петр Федорович атлы «патша» баш күтәргән икән, өч команданы да аңа каршы юнәләчәк җәзачы генерал-майор Ф.Ю.Фрейман корпусына кушып куялар. Әмма Оренбург янындагы беренче бәрелештә үк «башкорт» командаларының өчесе дә Пугачев ягына качып чыга. «Патша галиҗәнабләре» Пугачев Бирдә бистәсендә Петербург мисалында Хәрби коллегия дә оештырып җибәргән. Бер ел элек кенә поляк крестьяннарын изеп йөргән Кинҗә Арсланов белән Ямансарый Яппаров - аның әгъзалары, ә Кинҗә «башкортларның башкомандующие» булып та өлгергән. Польша походында унынчы партия башлыгы булып йөргән Качкын Самаров та монда, ул хәзер – полковник, Уфа төбәгендәге фетнәче башлыкларның берсе. Пугачев дүртенче партия башлыгы Кәип Җиятбәтовны да рәнҗетми. Үз теләге белән кушылган өчен аңа полковник дәрәҗәсе бирә, өстәвенә аны Бакалы белән Нагайбәк крепостен камалышта тотучы фетнәчеләр башлыгы итеп тә озата. 1774 елның февраль һәм март айларында карательләр тарафыннан тар-мар ителгәч, Кәип-полковник үз отряды белән Казаннан Оренбургка таба юнәлгән генерал М.Голицын корпусына каршы да сугышка керә, Уфа белән Оренбург арасындагы яуларда да катнаша.

Ләкин 1774 елның көз башында Пугачев гаскәренең тулысынча тар-мар ителүе турында хәбәр килеп ирешә. Гөнаһларны «юарга» ашыкмыйча булмый, Кәип-старшина да башка «түрәләр» белән бергә карательләр каршына гафу үтенеп килә. Польша походындагы тырышлыгын исәпкә алганнардыр, Кәипне җәзага тартмыйлар, хәтта кабат туган волостенда йорт-аймак старшинасы итеп тә калдыралар. Ни галәмәт, Кәип бабай әле 1796 елда да исән була, җанисәп документларына да теркәлә. Уллары да үзе шикелле үк елгыр һәм үҗәт булган, ахры. Хәлил белән Әюп исемле ике улы 1812 елгы Ватан сугышында катнаша. Хәлиле яуда һәлак була, ә Әюбе 2 нче «башкорт» полкы составында батырлык күрсәтеп, Изге Анна ордены белән бүләкләнә. Берничә елдан соң, артыннан йөреп, Әюб Кәипов подпоручик һәм дворян дәрәҗәләрен алуга ирешә. Аның артыннан ук Кәипнең өч улы – Гомәр, Госман һәм Локман да дворян булып таныла. Кәип туып-үскән Сипәш авылы озак еллар буе Кәип булып та йөри, ахыр чиктә Әлшәй районындагы Иске Сипәш булып кала. Кәип командасында күрше Чуракай авылыннан Аккүбәк Түләкәев, Кыпчак-Әскәр авылыннан Арслан Өметбаев белән Әмир Мортазин атлы татар яугирләре сугышып йөрүен дә искә алыйк.

Польша походында 6 нчы команда башлыгы булып йөргән Юлай Азналин да исән-сау кала. Ул үзе генә түгел, улы Салават та Пугачев гаскәренә барып кушыла. Юлайга бирелгән җирләрне өч тиенгә сатып алып, анда завод төзеп куйган «калын кесәлеләргә» үч итеп, 1774 елда әлеге старшина Сим һәм Йөрүзән заводын ут төртеп яндыра. Шуның өчен аны һәм улы Салаватны шул ук Сим заводы җирендә 25 әр камчы белән тотып яралар һәм маңгайларына кызган тимер белән «мөһер» салып, Балтыйк буендагы Ровервик сөргенәнә озаталар. 1797 елда әүвәл Юлай, ә өч елдан соң Салават вафат була. Гаҗәбе шул: Салаватны барча җиһан белә, ә яугир Кәипне ул туган Әлшәй районында да искә алучы юк... Тукай районының Оргыды авылында старшина булып торган, Польша походына яугирләр озаткан, ә Пугачев фетнәсе башлангач туган төбәгеннән олы отряд җыеп, полковник дәрәҗәсенә ирешкән Туйхуҗа Мәмәтовны да бүген беркем белми... Өстәл өсте мул бит: урыс аракысы түр башында, тозлаган кыяр да бар, ә тарих ник кирәк?..

Польша походында катнашкан сугышчылар сафын барлауга килсәк, безгә **Бүләр** волосте авылларыннан җыелган җайдакларның бер өлеше мәгълүм. Старшина Муса Мөслимов кул астында Баязит Аблаев – квартирмейстер, ә Мөрсәлим Галимбәтов, Юлдаш Яхшымбәтов, Кучкилде Исергәпов, Йортыкәй Яхшымбәтов (Яхшый авылыннан), Мәгъсүт Сөешев (Сикиядан), Мөслим Ишкилдин, Габдерәшит Юнаев, Габделвәһап Курманаев, Бохармәт Макаров, Тәмай Ишкилдин, Шәрип Морзакаев, Әбдүш Үмәткулов, Мөрсәлим Бәкеров, Габдрәхим Юлаев, Габделман Габдуллин, Зәйсән Солтанбәтов, Дәүләт Мәмәтев, Ишмөхәммәт Солтанбәков, Әхмәр Шабаев, Баязит Мөлеков, Ишбулды Иштирәков (Елан авылыннан) рядовой яугир булып йөри. Бүләр волостеның «башкорт катламы»ндагы татарлар старшинасы Имәнгол Кутлин кул астында Әмин Алдаров, Мөстәкыйм Мөстәкаев, Ярмөхәммәт Ишмәтев (Мөшегә авылыннан), Җәгъфәр Габдуллин (Мәсәгутыттән – Мөслим районында), Ракай Колышев (Сасыборын авылыннан, хәзер Мөслим районында Елгабаш), Имәкәй Юзеев (Мөшегәдән), Гомәр һәм Юлдаш Котлымәтовлар (Сәет авылыннан, Мөслимдә), Аккул Туктамышев (Әтрәкледән), Мостафа Мусин, Ишкул Миңнебаев (Сасыборыннан), Имәнгол Мөкъсинов, Илмәт Аллагулов (Уразмәттән), Салих Ишкинин, Миңлебай Юзеев, Әлкәй Алдаров (Уразмәттән), Биктимер Качкынов, Ишмәкәй Дүскәев, Уразай Карашаев, Сәет Мусин, Габит Хәитов, Зөбәер Юзеев (Әтрәкледән), Юмакай Юлмәтев (Мөшегәдән) һәм Хәлил Хансөяров ерак Польшадагы яуга бара. Әлбәттә, яугирләрнең һәммәсе дә яуга үз теләге белән генә бармый. «Башкорт катламы»на язылган вотчинник булганга күрә, үз статусларын югалтмас һәм биләмәләреннән колак какмас өчен, алар хәрби бурыч үтәргә – ил чикләрен сакларга һәм җангя ятышсыз Польша походларына йөрергә мәҗбүр булган...

Минзәлә җайдаклары 1812 елгы Ватан сугышында

1812 елның 24 июнендә Наполеон Бонапарт кул астындагы француз гаскәре Россиягә бәреп кергәннән һәм рус армиясе Неман елгасыннан алып Смоленск каласына чаклы чигенергә мәҗбүр булганнан соң, 8 август көнне, Россия императоры Александр I башкорт һәм мишәр җайдакларыннан хасил казак полклары оештырырга фәрман бирә. Россиянең көнбатыш чикләренә ул елларда составына Уфа провинциясенең Минзәлә өязе дә кергән Оренбург губернасыннан һәркайсы 500 җайдактан торган 20 полк озатыла. Шул полкларны тәшкил иткән 10 мең «башкорт» яугире белән регуляр армиянең кадровый офицерлары җитәкчелек итә. «Башкортныкы» булып саналган 3 нче, 5 нче, 6 нчы, 19 нчы һәм 20 нче полклар Минзәлә төбәгендә урнашкан авыллардан туплана.

11 нче хәрби кантон составындагы 6 нчы атлы полкны тулысынча Минзәлә өязендәге «башкорт» авылларының яугирләре тәшкил итә. Полк башлыгы – Казан гарнизон полкы майоры Н.Ф.Шайдаров. 21 сентябрьдә полк походка чыга һәм Алабуга, Арча, Казан, Зөя, Чабаксар калалары аша 16 октябрьдә Түбән Новгородка барып җитә. 1812 елның 30 октябрендә ул Балахнаны үтә һәм 24 декабрьдә Устюжня каласына керә. Падишаһ фәрманы буенча, полк бер ел буе Санкт-Петербург белән Вологда арасын саклап тора. Аннары полк җайдаклары Витебск каласында атлы полиция бурычларын үти. 1814 елның 1 апрелендә аны Борисов каласына каравыл хезмәтен алып бару өчен күчерәләр.

Кыргыз волосте авылларын үз эченә алган 10 нчы, Байсар волостендагы 11 нче һәм Азнакай-Туймазы төбәкләреннән җыелган 12 нче хәрби кантон «башкортлары»ннан оештырылган 5 нче атлы полк Бөгелмә өязенең Карабаян авылында формалаштырыла. Ул походка 25 июль көнне кузгала һәм Чистай, Казан, Зөя, Чабаксарны үтеп, 29 августта Түбән Новгородка җитә. Командиры – Югары Уральскидагы гарнизон капитаны И.Г.Ти-

ЕВРОПАДА

хановский. 15 октябрьдә полк кенәз П.М.Волконский җитәкчелегендәге отрядка кушыла. Витгенштейн һәм Винценгероде командалыгындагы корпуслар белән берлектә алар Торопец, Белый, Сычевка калаларын Смоленск ягыннан янаучы дошман гаскәре һөҗүменнән саклый. 5 нче «башкорт» полкындагы өч йөз сугышчыны – Велиж, ә калган ике йөзен Сураж каласына урнаштыралар. Шуннан торып разъездлар (атлы төркемнәр) Витебск һәм Рудня калаларыннан килгән юлларны саклап тора.

1812 елның 1 ноябрендә полк генерал-майор М.М.Свечин отрядына кертелә, ә бу отряд үзе Витгенштейн корпусының авангардын тәшкил итә. 14-16 ноябрьдә полк җайдаклары генерал Властов отряды составында Березина елгасы янындагы яуларда катнаша. 1812 елның 27 ноябрендә полкның фактдагы башлыгы, гаскәри старшина Ибраһим Бикчурин 3 нче дәрәҗәдәге Изге Анна ордены белән бүләкләнә. Березина янындагы яулардан соң 5 нче полк әсирлеккә төшкән французларны озату өчен Витебск каласына җибәрелә, аннары Борисов каласында тәртип саклау белән шөгыльләнә. Соңрак полк Данциг каласын камалышка алуда катнаша. Аннары 1814 елның апрелenә кадәр Минск губернасында җирле полициягә ярдәм күрсәтә, француз әсирләрен һәм яңа гына армиягә чакырылган рекрут партияләрен озатып йөри.

(Шушы урында тукталып, өстәмә кертергә мәҗбүрбез. Висла елгасының Балтыйк диңгезенә койган тамагында урнашкан Данциг крепостен генерал Витгенштейн корпусы 1813 елның гыйнвар аенда ук штурмлый башлый. Корпус составында Беренче «башкорт» полкы җайдаклары да була, алар яуларда да катнаша. Әмма крепостьны яулауга ирешмиләр. Апрель аенда, рус корпусына ярдәмгә, Бишенче «башкорт» һәм Икенче типтәр полклары да килеп кушыла, май аенда крепость тулысынча камалышка алына. Ләкин крепостьны 1813 елның декабрендә генә, янә өстәмә рус гаскәре һәм 7 нче «башкорт» полкы килеп җиткәннән соң гына яулауга ирешәләр. Икенче типтәр полкы составында минем туган авылым Байсардан да 95 ир-ат исәптә торган).

Полкның бер өлеше әле 1812 елның ноябрь аенда ук гаскәри старшина И.Бикчурин җитәкчелегендә үзәк армия карамагына, инфантерия генералы Барклай де Толлины саклау өчен озатылган була. Шушы эскадроннар Германиядәге Лейпциг каласы янындагы данлыклы яуда катнаша. 4-6 октябрь көннәрендә булып узган бәрелешләрдә күрсәткән каһарманлыгы өчен И.Бикчурин – подпоручик, ә Тукай районының Оргыды авылыннан әүвәл йөзбашы, аннары гаскәри старшина булып йөргән Идрис Сөешев (Сөеш улы Якупов) 14 нче класстагы түрә дәрәҗәсе белән бүләкләнә. Иркәнәш авылы (бүгенге Минзәлә районында) старшинасы И.Бикчурин һәм аның уллары Габделкаһир белән Габделхалик соңыннан дворян, яки морза исеменә лаек була һәм аның шәҗәрәсе Оренбург губернасының дворяннар китабына кертелә. Полк сугышчыны Париж каласын яулап тәмамлый.

Хәзер без Наполеонга каршы 1805-1807 еллардагы кампания, 1812 елгы Ватан сугышы һәм 1813-1814 елларда чит илләрдәге походта катнашкан сугышчылар исемлеген китерәбез. Офицер, зауряд-түрә (хәрби поход барышында нindider вазифага билгеләнгән яугир), урядник һәм сәркатибләрнең исемлеге 11 нче «башкорт» кантонының 1836 елда төзелгән формулярыннан, ә рядовой «башкорт» фамилияләре 1845 елда төзелгән исемлектән алынды. Исем-фамилияләр, сугышчыларның дәрәҗәсе һәм туган авыллары – барысы да шул заман документлары буенча китерелә. Ветеранның һәммәсе дә диярлек 1812 елгы Ватан сугышы истәлегенә һәм 1814 елның 19 мартында Парижны яулап алу хөрмәтенә булдырылган көмеш медальләр белән бүләкләнгән.



● **«Башкортлар» Парижда, 1814.** Билгесез художник, 1814.

● **Әсир ителгән француз сугышчыларын «башкорт» һәм калмыклар саклый.** Р.Кнётель эше.1813.

1845 елда 11 нче «башкорт» кантоны 25 хәрби йортка бүленә:

1 нче йорт – Бүләр волостеннан Мәчти (1974 елда юкка чыкты), Байсар, Сәфәр, Олы Имән, Яхшый авыллары (барысы да Актаныш районында);

2 нче йорт – Байлар волостеннан Күҗәкә, Чиру, Әтәс, Апач (барысы да Актанышта);

3 нче йорт – Байлар волостеннан Юскәй (хәзер Югары) Тәкермән, Оргыды, Калмаш, Әхмәт (Актаныш районының Такталачык авылы янәшәсендә), Кугаш, Сәет, Абдул (барысы да Тукай районында), Тау Асты Байлар (Минзәләдә);

4 нче йорт – Байлар волостеннан Чебенле (Туйхуҗа), Колыш, Калмия, Малтабар, Боерган, Күзкәй – (барысы да Тукай районында), Гөлек (Минзәләдә);

5 нче йорт – Байлар волостеннан Дәвек, Урыс (дөресе Ырыс), Тулбай, Хуҗамәт, Усай (барысы да Минзәләдә), Байлар, Туер (Тукайда);

6 нчы йорт – Байлар волостеннан Чат, Чынык, Бикчәнтәй, Усы, Адай, Түбән Уръяды, Карач, Измелково (дөресе – Җизмыек, ул Шәбез елгасы буенда яшәгән, юкка чыккан), Каен Түбә (Татар Әҗбие) - барысы да Актанышта;

7 нче йорт – Байлар волостеннан Нөркәй, Яңа Әхмәтабыз (Яңа Әхмәт), Азалак, Каташ-Каран, Сарман – (барысы да Сарманда), Казаклар, Теләнче Тамак, Куады (соңгы өчесе Тукай районында), Иске Әхмәтабыз (Иске Әхмәт) – Зәй районында;

8 нче йорт – Байлар волостеннан Әлмәтмулла (Иске Әлмәт), Мортышбаш, Мортыштамак, Дөмәй Тарлау, Кәүҗияк (барысы да Сарманда), Баламык (Баланлы-?), Карамалы, Рангазар, (өчесе дә Мөслимдә), Драгун Бикмәт (юкка чыккан) – Тукай районында, Сарайлы Бикмәт (Сарман районында);

9 нчы йорт – Гәрәй волостеннан Такталачык, Түмерҗә (Таймөрзә), Түбән Такталачык, Теләкәй, Бурсык (барысы да Актанышта);

10 нчы йорт – Гәрәй волостеннан Әҗәкүл, Куян, Шәрип, Уразай, Ирмәш (барысы да Актанышта);

11 нче йорт – Гәрәй волостеннан Чөгәнә, Югары Актанышбаш, Яңа Актанышбаш, Илчебай, Югары Мерәс, Тыңламас (барысы да Актанышта);

12 нче йорт – Йәнәй волостеннан Яңа Богады, Иске Богады, Кадермәт, Солтангол, Ахун, Меңнәр, Елан (барысы да Актанышта);

13 нче йорт – Йәнәй волостеннан Чалманарат, Шәбез, Калмаш, Суыксу, Карт (барысы да Актанышта);

14 нче йорт – Гәрәй волостеннан Иске Гәрәй, Яңа Гәрәй, Ямалы, Буазкүл (соңрак Өшәр белән кушылган), Кормаш, Балтач, Җияш (барысы да Актанышта), Яңа Сәфәр – Мөслимдә;

15 нче йорт – Йәнәй волостеннан Өшәр (Семиостров), Яңа Өшәр, Сәүз (1800 елларда Яңа Өшәрдән бүленеп чыккан), Әҗби (барысы да Актанышта);

16 нчы йорт – Бүләр волостеннан Сәет, Сикия, Әлмәт, Әмәкәй, Теләнче (хәзер Октябрь), Мәсгуть, Уразмәт, Бишкүмәч (барысы да Мөслимдә), Табанлыкүл, Чуракай, Әгъбәс (өчесе дә Актанышта);

17 нче йорт – Бүләр волостеннан Зөбәер, Түке, Качкын, Колын (барысы да Актанышта), Исәнсеф (Мөслимдә), Бикбау, Калморза (икесе дә Минзәләдә);

18 нче йорт – Бүләр волостеннан Әтрәкле, Мөшегә, Чүплек (Кызыл Төбәк), Иркәнәш (дүртесе дә Минзәлә районында), Айман (Иске Айман), Әнәк (икесе дә Актанышта), Бүләр (Татар Бүләре) - Мөслимдә;

19 нчы йорт – Сарайлы-Мин волостеннан Сарсаз Тәкермән, Имән (Иске Имән), Шарларәмә, Кормаш – дүртесе дә Сарманда, Сәмәкәй (Тукайда);

20 нче йорт – Сарайлы-Мин волостеннан Түбән Табын, Югары Табын, Тугаш, Тәмьян (дүртесе дә Мөслимдә), Үсәли Саклау, Тегермәнлек, Саклаубаш, Сөлек, Чураш (бишесе дә Сарманда);

21 нче йорт – Ирәкте волостеннан Метрәй, Мәлләтамак, Салавыз, Яңа Вәрәшбаш, Симәк, Сәякәй, Бәкәбез, Күбәк, Карамалы, Бүләк, Баланлы, Сасы-борын (юкка чыкты, башка урынга күченгәч алган исеме - Елгабаш) – барысы да Мөслимдә; Имәнле (юкка чыкты), Нарат Асты – Минзәләдә;

22 нче йорт – Кыргыз волостеннан Аеш, Кадыкай (Кәзкәй), Яңа Әлем, Иске Әлем, Аккүз (барысы да Актанышта);

23 нче йорт – Вятка губернасының Алабуга өязенә караучы Байлар волостеннан Бәзәкә һәм Турай (Менделеев районында);

24 нче йорт – Вятка губернасының Алабуга өязендәге Байлар волостеннан Салагыш, Аккүз, Мазарасты, Көчек, Баржы, Янморза, Кураз, Бетсемәс (барысы да Әгерҗедә), Тавземал (Тауҗамал – Удмуртиянең Кыяс районында калган, Әгерҗе районы чигенә терәлеп тора, дөрес исеме Тау Ямалы булу мөмкин);

25 нче йорт – Вятка губернасының Сарапул өязенә караучы Йәнәй волостеннан Исәнбай, Үтәгән, Эсләк, Касай, Әгерҗе (барысы да Әгерҗедә).

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

«Сезнең дустыгыз,

(Ахыры. Башы 38 нче санда).

1938 елның 13 июнендә Зорге СССРдан качкан Ерак Көнчыгыш төбәге буенча НКВД идарәсе башлыгы, генерал Г.Лушков документларын укый, 250 битнең 90ын фотога төшереп, Мәскәүгә җибәрә. Генерал исә армиядә М.Тухачеcкий белән бәйле чистарту эшләре барганда японнарга Себердәге совет гаскәрләре санын әйтә, яшерен кодларны тапшыра, Сталинның Себердәге төп оппонентлары фамилияләрен саный һ.б. Ул үз гаиләсен дә Европага озаткан була инде. Японнар бу хактагы мәгълүматларны полковник Шолльга да тапшыра. Лушковтан немец хәрби контрразведкасы да сорау ала. Аның әйткәннәре буенча язылган бихисап материалларны Зорге укый.

Бу чорда дәүләтләр арасындагы сәясәт кискенләшә, вакыйгалар июль-августта Хәсән күле янындагы бәрелешләргә кадәр барып җитә.

26 яшендә совет разведчигы белән гомер итә башлаган Ханаконың көннәре исә шушы тәртиптә: 1937 елда ул инде «Рейнгольд» рестораны эшләми, Зорге аңа аена 200 иена түли, ул Зоргеның башка акчасына бер профессорга барып, җырларга, бер пианист ханым янына барып, уйнарга өйрәнеп йөри. Ханым – ярлы гаиләдә үскән зат. Ханако да Зоргеның нинди эшчәнлек алып баруын төшенми. Төшенсә, ул аңа арзанлы тукымадан тегелгән саргыл-кызыл галстук бүләк итмәс тә иде... Ханым: «Зорге һәрчак мәкаләләр язуда иде», – дип искә алачак. Аннары ул бит аның йортына да һәр көн килми. 1938 елда, Ханако сөйләвенчә, япон полициясе хезмәткәре аннан Зорге хакында сораша һәм кайбер кәгазьләрен урлап, аңа тапшырырга тәкъдим итә. Тик ханым моңа риза булмый. Һәм бу хакта Рихардка да әйтә. Зорге аннан: «Сез чыннан да минем кәгазьләрне урларга җыенасызмы?» – дип кенә сорый. Ханако: «Юк, беркайчан да», – дип җавап бирә.

Рихард өендә овчарка тотарга тели, әмма моңа хезмәтче япон ханымы каршы төшә. Шуннан соң ул кулга ияләшкән ике ябалак алып кына юана. Кайчак Япония тарихы хакында калын китап язуын дәвам итә, еш кына аны кәгазь битләренә баса. Мәскәүгә яшерен хәбәрләрдән кала мондый эчтәлекле язма да юллый: «Зинһар, онытмагыз, миңа инде 45 яшь тулды, шуның 11 елдан артык вакытымны мин сезгә эшлим. Аңа кадәр 5 ел башка оешмага хезмәт итеп, гомеремне сәяхәтләрдә үткәрдем. Минем тәҗрибәм белән нинди дә булса Үзәктә утырып эшләр вакыт җитә. Мин сугыштан соң нишләрмен?.. Ахыр чиктә, мин беркая барып кайтмыйча 7 ел яшим һәм, башка «инсафлы чит ил кешеләре» кебек, һәр 3-4 елдан соң ял да алганым юк... Әмма шуңа карамастан сезнең тугры дустыгыз булып калам. Рамзай». Газета редакторлары да, китабын нәшер итергә теләүче нашир да, аның белән алдагы елларда да хезмәттәшлек итергә җыенучы немец илчелеге дә аннан килачәктәге планнары хакында еш сораша... Мәскәүдә 1940 елдагы хәбәрләренә дә ышанучы аз. Моңсу була аңа. Өстәвенә, 1941 елның 15 февралендә Германиядә чит дәүләтләрдәге атташе аша совет иленә сугыш башлау көнен ялганлап әйтергә кирәклеге хакында карар чыга, бу карар сәбәпле ул да ялгыш дата күрсәтелгән радиограммалар юллый...

1941 елны, Ханако язуынча, аның эчке халәте бик борчулы рәвешкә килә. Зорге йә нык кына эчә, йә иртән генә кайта, йә нидер яза... «Бервакыт ул кабинетында кулларын маңгаена куеп, тын гына ята иде. Мин янына килдем. Зорге тын гына елый иде. Исем китте. Мин шушындый да көчле ир-ат булган Зоргены елый аладыр дип күзаллый да алмый идем», – дип искә алачак япон ханымы. Аннары ул аңа үзен бик моңсу хис итүе хакында әйтә. Моның сәбәбен: «Минем дусларым юк», – дип аңлата. Ханако: «Нигә? Сезнең Отт-сан бар. Вайзе-сан. Клаузен-сан. Сезнең дусларыгыз бар!» – дисә дә, Зорге тагын да моңсуланып: «Чын дусларым юк», – дип җавап бирә.

1940 елда разведчик: «Хәзерге вакытта немецлар үз көнчыгыш чикләрендә, Румынияне дә кертеп, СССР сәясәтенә йогынты ясау максатыннан 80 дивизия тота. Германиядән Япониягә килгән хәрбиләр әйтүенчә, немецлар СССР территориясен Харьков-Мәскәү-Ленинград линиясе буенча басып алачак» дигән радиограмма җибәрә. Кайбер чыганакларда, Зорге 1939 елның май-июнендә Германиянең Польшаны басып алырга әзерләнүе, һөҗүм август ахырында-сентябрь башында башланачагы хакында, 1940 елның февраль-апрелендә исә фашистларның Франциягә һәм Англиягә каршы һөҗүм итәргә, ә аннары Советлар Союзына ташланырга ниятләве турында хәбәр бирә. 1941 елның 5 мартында элемтәчегә Германиянең чит илләр министры Риббентропның О.Оттка совет иленә май аенда сугыш белән керәчәкләре хакындагы телеграммасының фотокүчермәсен тоттыра, диелгән. 1941 елның 21 маенда ул мондый хәбәр юллый: «Гитлер вәкилләре шуны раслый: сугыш май ахырында башланачак. Германия СССРга каршы 150 дивизиядән торучы 9 армия туплаган». 1941 елның 20 маенда: «Советлар Союзына һөҗүм 20 июньдә башланачак; төп һөҗүм юнәлеше – Мәскәү»; 1941 елның 31 маенда: «22 июньдә Германия сугыш игълан итеп тормыйча Советлар Союзына ташланачак»; 1941 елның 15 июнендә: «Һөҗүм киң фронт белән 22 июнь таңында булачак»; 1941 елның 3 июлендә инде: «Япония, гитлер Германиясе басымы булса да, әлегә СССРга каршы сугышка кермәячәк». 1941 елның 6 сентябрендә исә: «Әгәр дә Кызыл Армия үз хәрби көчен саклап кала алса, Япония һөҗүме гомумән булмаячак. Берничә мобилизация билгеләнгән, әмма аларның максаты – Квантун армиясен Кытайдагы хәрби хәрәкәт өчен тулыландыру. Болар барысы да Япониянең быел Ерак Көнчыгышка үтеп кермәвен аңлата» дигән хәбәрләрен җибәрсә дә, аңа ышанучы аз була. Соңрак ул элемтәченең күзләренә туры карап: «Ни өчен миңа ышанмадыгыз?!» – дип тә сорый. Әмма бу сорау Мәскәүдә аңа карата ачу гына тудыра.

Ләкин Сталин бу юлы аңа ышанырга мәҗбүр, ул хәрби кадрлардан торучы 26 себер дивизиясен көнчыгыштан көнбатышка таба күчерергә боерык бирә. Мәскәүне, дөньяны саклап калу өчен никадәр өстәмә көч Зорге хәбәрләре сәбәпле һәм бары тик шулай гына барлыкка килә...

Зорге иң соңгы хәбәрен 1941 елның 4 октябрендә юллый. Ул контрразведканың аның эзеннән үк баруын аңлый. 1941 елның октябрендә япон полициясенең чит ил бүлеге Рамзай төркемендәгеләрне кулга ала башлый. Беренче итеп 10 октябрьдә рәссамны кулга алалар, аннары башкаларын. 14 октябрьдә Одзаки «Азия» ресторанына килми. Ике көннән Мияги да очрашуга килми. Зорге моны көтелгән хәл буларак кабул итә. 17 октябрьдә ул Клаузен һәм Вукелич белән очраша. Кичен радист-шифрлаучы, Клаузен, Зорге янына барып, Мәскәүгә резидентларны кайтару зарур дигән телеграмманы эшкәртерә. Әмма инде бик соң була... 18 октябрь иртәсендә Зоргены кулга алып, Сугамо төрмәсенә ябалар. Аның өстәл өстендә шул радиограмманың карамаласы табыла. Өйдә 3 фотоаппарат, 1 фотокамера, 3 фотолинза, аларның берсе телескопик линза була, агентлар белән бәйләнеш язылган, отчетлар кушылган 16 блокнот, акчалар, йөзләрчә том китап, яңа Япония хакында язылган 300 битлек язма, кроватта ачык килеш калган XVI гасыр япон шигырьләре китабы, 7 битлек отчет, схема һәм Мәскәүгә юлларга әзерләнгән 2 битлек инглизчә текст һ.б. Клаузенда да шушы телеграмманың яртылаш шифрланган варианты табыла. Гомумән, Япониядәге фирмасы чәчәк аткан саен Клаузенның разведка эшчәнлеге сүлпәнәя генә барган икән шул. Совет акчасына ачылган фирма табышының бер өлешен разведка өчен тотарга кирәк, дигән боерык та аңа ошамый. Яшерен телеграмма кәгазьләре дә өстәл өстендә ята бирә.

● Ханако Исии Рихард Зорге сынын ясый.

Германия илчелеге «Зорге ялгыш кулга алынды!» дип рәсми кәгазьләр яза, андагы беркем дә аның разведчик булуына ышанырга теләми. Кулга алулар 1942 елның җәенә кадәр дәвам итә. Төрмәдә утырганда да Зорге үз иптәшләренә зур сумма акчалар күчерә алган дигән мәгълүмат бар. Ә О.Отт Зоргены күрергә дип төрмәгә килгәндә аңа юрган алып килә. Аның гомере озын булып чыга: 1942 елның 31 декабрендә ул инде илче вазыйфаларыннан алына, Япониядә пон grata дип игълан ителә һәм бу дәүләттән китергә мәҗбүр була. Гаиләсе белән Пекинга күченә. Хәрби хезмәткә кайтырга теләп язган бар гозерләре дә кире кагыла. Сугыштан соң ФГРга кайтып, 1977 елда гына 87 яшендә Баварияда үлә...

Сорау алу башлангач, Рихард дәшми. Аннары гына кәгазь һәм каләм сорый, «Мин 1925 елдан бирле Коминтернда» дип язып, кәгазьне йомарлап, бүлмәнең аргы почмагына ыргыта. Бүлмә буйлап арлы-бирле йөри дә, кинәт кенә елап җибәрә. «Җиңелдем. Мин гомеремдә беренче тапкыр җиңелдем», – дип кычкыра. Тикшерүчеләрнең сорауларына разведчик җавапларны язмача рәвештә язачакмын дип җавап бирә һәм «Мин бары тик Коминтерн файдасына шпионлык иттем», – дип бара. Бер карасаң, бу аның иптәшләрен зуррак явызлыктан коткару, чөнки совет разведкасына эшләдем, дию аларның барсын да «Кэмпэйтай» хәрби полиция карамагына күчертер иде, ә анда – явызлыклары чиктән ашкан хәрбиләр...

Мәскәүдә аның кулга алынуын берничә айдан соң гына беләләр, алар өчен Зорге... «ике як агенты» булып та санала. Гомумән, аны анда җәлләүче булдымы икән?!

Кемдер Зоргеның «яну»ын коммунист Мияги белән хезмәттәшлек итүдә күрә, японнар ул чакта коммунистлар артыннан нык күзәткән иң. Кулга алулар да шуннан башланып киткән. Ә кемдер, бәлкем, совет илчелегендәгеләр белән очрашулар күзгә чалынгандыр дип фикерли. Ләкин бу тарихның очына төгәл чыгучы юк.

Кулга алынган 24 агенттан сорау алулар дәвам итә. 1943 елны, инде сорау алулар да тәмамлангач, Ханаконы да 6 көнгә төрмәгә тыгып куялар. Ул азат ителә. Чөнки Зорге Ханако минем разведчик булуымны белмәде, зинһар, аны тынычлыкта калдырыгыз, аны кулга алсагыз, мин сезгә берни хакында да сөйләмәячәкмен, дип белдерә.

Япон суды Мантэцу идарәсенең Токио бүлегендәге рәсми булмаган киңәшчесе 43 яшьлек Одзаки Хоцумига һәм 49 яшьлек супершпион Рихард Зоргега карата 1943 елның 29 сентябрендә карар чыгара: үлем җәзасы. Алар бер-берсен беренче тапкыр судта гына күрә. Карарны тыныч күңел белән тыңлыйлар. Алар, Коминтерн агентлары буларак, «Япониядәге дәүләт төзелешен үзгәртергә, анда пролетариат диктатурасы урнаштырырга һәм коммунистик җәмгыять төзергә теләгән» икән.

Гавас Бранко Вукелич һәм Макс Клаузен исә гомерләре ахырына кадәр төрмәдә утырачаклары хакындагы карарны ишетә. Башкалар да үз карарларын тыңлый. (Арадан Вукелич 1945 елда Хоккайдо утравындагы төрмәдә ачтан үләчәк. Аның җәсәден япон миллләтле җәмгате яндырып күмсә дә, соңрак көле салынган савыт бомбага тотканда яначак. Туберкулез белән чирләүче Мияги Ётоку 1943 елда суд карарына кадәр вафат булачак, аның җәсәде көлен әнисенә юллаячаклар. Рәссамның Мексика китүче ир туганы рәссамның көлен дә үзе белән алып китәчәк).

Рамзай...»

● Казанда Рихард Зорге бюсты.

Р.Зорге судта немец телендә җавап бирә: «Сугышлар – капиталистик җәмгыятьләр бәрелеше. Капитализмны юкка чыгарыга кирәк», – ди. Адвокатлар аппелляция язса да, Одзаки өчен ул уңай якка каралмый. Ә Зорге буенча аппеляция Япониянең Югары судына бер тәүлеккә соңарып бирелгән булып чыга.

Аларны 1944 елның 7 ноябрендә Сугамо төрмәсендә асып үтерәләр. Зорге да эшафотка тыныч кына менә. Төрмә табибе аның йөрәге үлгәч тә 8 минут буе типте, дип язып куя. Ул пиджактан, галстуксыз һәм күзлектән була.

2004 елда ачыкланган протокол буенча, Одзаки Хоцуми үлеме алдыннан дога белән Буддага мөрәҗәгать иткән. Төрмә башлыгы Зоргедан җәсәде һәм шәхси әйберләре буенча төзелгән васыятьнамәгә ни дә булса өстәргә телиме дип сораган. Зорге: «Минем васыятьнамәм үзем ничек язсам, шулай калачак» – дип җавап биргән. «Сез тагын нәрсә дә булса да әйтергә телисезме?» дигән сорауга каршы: «Юк, башка берни дә...» – дигән. Аннары Зорге төрмә хезмәткәрләренә таба борылган һәм: «Мин сезгә сезнең игелеклегез өчен рәхмәт әйтәм», – дигән. Аны күмәрлек кеше булмаганга күрә җәсәден дә төрмә хезмәткәрләре төрмәдән ерак булмаган Дзосигай җәмәгать зыяратына күмгәннәр.

1948 елда Ханако Зоргеның адвокатын эзләп таба һәм аның сөйләве буенча Рихардның судта: «Бар җитәкчелек, эшчәнлек өчен мин генә җавап бирдем, японнар миңа бары булышлык кына итте, адвокат дөрес аңлатмый, бөтен гаеп – минем өстә», – дип инандыруы хакында белә. Адвокат: «Зорге төрмәдә бик күп укыды, Европа телләрендә язылган Япония тарихын өйрәнде. Төрмәдә уздырган 3 ел эчендә ул бары тик тарихи китаплар гына укыды. Төрмә китапханәсендә ул укырга теләгән китаплар булмагач, миңа үз хисабындагы акчага кибетләрдән башка китапларны сатып алдыртты», – ди. Чыннан да аның китапларга бик шатлануын, йөзләрчә том укып чыгуын, иртән халат киеп, төнгә кадәр язу машинкасында язмалар басуын башкалар да раслый. Бу язмалар «Төрмә язмалары» дип аталачак. Моннан кала аңа тәрҗемә итеп торучы ир-ат та: «Суд барышында ул сугыш вакыйгалары хакында белеште һәм Сталинград бәрелешендәге совет уңышын ишеткәч, нык шатланды», – дип искә алачак әле.

Япониянең Юстиция министрлыгы рөхсәте буенча чит ил гражданнарын җәзалау рөхсәт ителми. Шуңа күрә Зоргены да җәзаламыйлар. Әмма бу үз Ватаннарына каршы эшчәнлек алып барган японнарга кагылмый. Аларны каты җәзалаганнар булыр, ахрысы. Әмма, кем белә, әйтик, аларны баштагы «Токко» махсус полициясе түгел, ә «Кэмпэйтай» хәрби полициясе тоткарласа, бәлкем, чит ил кешеләренә карата да каты җәзалар кулланылган булыр иде...

Ханакога зыярат каравылчысы кенәгәдән Зорге күмелгән дигән язманы укып бирә. Ул америка хәрбиләренең бирегә килеп, Косугэ төрмәсеннән дә кемнедер чакыртып, Зорге күмелгән җирнең сурәтен ясап, китеп барулары хакында да сөйләгән, ханым шул төрмәгә китә. Анда аңа әлеге разведчик буенча документларны күрсәтәләр. Япон ханымы Зорге җәсәден Тама зыяратында сатып алган җиргә күчереп күмәргә ният кыла. Өстәвенә, урын җитмәү сәбәпле, андагы җәсәдләрне тагы казып алып, яндырып баралар икән. Ашыкмаса, Зоргеның җәсәден дә казып, яндырып юкка чыгарырга мөмкиннәр. 1949 елның 19 ноябрендә ханым Дзосигай зыяратыннан Р.Зоргеның җәсәден казытып алдыра. Аны аның баш сөяге, аяк сөягендәге сугышта алган җәрәхәттән сынып төзәлгән урыны буенча, каеш прәшкәсе, череп баручы ботинкалары, гомумән буй озынлыгы буенча ук таный. Күзлеген, каеш прәшкәсен, теш протезларын сумкасына сала. Җәсәд калдыклары салынган табутны велосипедка беркетеп, крематорийга алып киләләр һәм яндыралар. Ханым яраткан кешесенең көле салынган савытны алып кайтып, савытны кочаклап йокыга тала. Аннары аның каберен булдыруга керешә. Әүвәл нәшриятка барып, Зорге хакындагы китабы өчен гонорар сорый. Аннары аның фотосын бер сынчыга биреп, бюстын ясатырга була. Ясалып, бронзада коелган сын аңа ошамый. Ханым андагы кимчелекләрне күрә. Берникадәр вакыт үткәч ул җәсәден күчергәндә алган Зоргеның алтын теш коронкаларын эреттереп... үзенә балдак ясата. Һәм аны киеп йөри башлый.

Аннары Зоргеның башка бюсты кирәк булуын аңлап, аны үзле балчыктан үзе ясый. Ясап бетергәч, бер остаханәгә барып, акча түләп, койдырта. 1950 елның 8 ноябрендә өйдә бер ел диярлек сакланган разведчик җәсәденең көле салынган савытны Тома зыяратына илтеп, кабер урындагы бетон җәйланмага куя, бетон капкач белән каплатып, цемент белән ныгыта. Бу зыяраттагы гомуми кабердә руслар, татарлар, төрекләр дә күмелгән. Алар – 1 нче, ә Зорге җәсәде көле – 17 нче участокта. Сугыш чорында Ватанын саткан бердәнбер япон дип саналучы Одзаки Хоцуми җәсәде дә бирердә күмелгән була.

Ханако әдәби түгәрәктә язу сәләтен шомарта. Зорге хакында барлыгы 3 китап нәшер итә. Кайчандыр җитди чирләп, туберкулез сәбәпле операция дә кичергән ханым нибары 2000 елда, 89 яшендә вафат була.

1964 елның җәендә Н.Хрущев дачада французларның «Кем сез, доктор Зорге?» детективын карый. Һәм «Зорге дигән разведчик чыннан да булганмы соң?» – дип сораша. Уңай җавап алгач та, аның хакында халыкка белгертерергә кирәк, ди. Тиз арада Япониядәге каберенә дә барып кайталар, Ханаконы да табалар. «Правда»да язма да басыла. 1964 елның 5 ноябрендә Р.Зоргега Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ә бу вакытта инде чит илләрдә аның хакында дистәләрчә китап нәшер ителгән була. Моңа кадәр кайчандыр аның белән эшләгән һәм атып үтерелгән ике башлыгы – Я.Берзин һәм Л.Борович та инде 1956 елда акланган була.

1966 елда Зорге кабере илебез хөкүмәте булышлыгы белән үзгәртелә. Ханако үлгәч, аның шул алтын балдакны кигән килеш яндырылган җәсәде көлен дә бирегә урнаштыралар, исемен кара ташка язалар. 2020 елдан башлап Рихард Зорге кабере ил карамагында, Россия җаваплылыгында.

1998 елда «Асахи симбун» Р.Зоргены «ХХ гасырның йөз кешесе» исемлегенә кертте. Әмма ул барыбер да ХХ гасырның яшерен сугышы тарихындагы иң өйрәнелүче һәм иң серле шпионы булып кала бирә.

Р.Зоргедан соң Япониядәге яшерен эшчәнлекне башка совет разведчигы, полковник, татар – Шамил Хәмзин генә дәвам итә ала. Күп телләр белүче Шамил Хәмзин һәм Бибииран Әлимова 1954 елда Кытайдан Япониягә килә һәм шушы дәүләттә... 13 ел дәвамында уңышлы эшли. Ләкин бу инде гомумән башка тарих.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА әзерләде.

Айга карамый

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

7 октябрь (шимбә). ***Рабигул әүвәл аеның 22 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 22.28 сәгатьтә калка, 16.22 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.09 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Иммунитетны ныгыту (1)

Ай буена көн саен 5-6 әстерхан чикләвеге ашау иммунитетны ныгыта. Яисә 2 аш кашыгы чыршы ылысын кәстрүлдәге 1 стакан кайнар суга салалар, капкачын ябып, 20 минут кайнаталар, 30 минут төнәткәч, сөзәләр, ике-өчкә бүлеп, көн буена эчеп бетерәләр. Организмны мүк җиләге, балан, кара карлыган, чия, җир җиләгеннән кайнаткан компот та ныгыта, аны көн саен яртышар литр эчәргә кирәк. Яисә 5 әр аш кашыгы кырлыган (иван-чай), мелисса, бөтнек үләннәре, кәстәнә чәчәген 1 литр кайнар суда 2 сәгать төнәтәләр дә, көненә берничә тапкыр 1 әр стакан эчәләр.

8 октябрь (якшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 23 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 23.47 сәгатьтә калка, 16.43 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.04 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Иммунитетны ныгыту (2)

Организмның авыруларга каршы торучанлыгын арттыру өчен, ярты килограмм изелгән мүк җиләге, 1 стакан чистартылган әстерхан чикләвеге, шакмаклап туралган 2-3 яшел алманы кәстрүлдәге ярты стакан суга салып, ярты килограмм шикәр өстиләр, сүрән утта кайнатып чыгаралар. Банкаларга тутырып, суыткычта саклыйлар, иртән һәм кичен 1 әр аш кашыгы кабалар. Яисә ярты литр суга 250 грамм вак туралган суган, 200 грамм шикәр салып, сүрән утта сәгать ярым кайнаталар, суынгач, 2 аш кашыгы бал өстиләр, сөзеп, пыяла савытта суыткычта саклыйлар. Көненә 3-5 тапкыр 1 әр аш кашыгы кабалар.

9 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 24 нче көне. 25нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Арыслан йолдызлыгында, 1.06 сәгатьтә калка, 16.57 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 11.00 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Иммунитетны ныгыту (3)

Эпидемияләр чорында чир йоктырудан саклану өчен, яртышар стакан торма һәм кишер согын кушып, шуңа 1 әр аш кашыгы бал һәм лимон (яки мүк җиләге) согы салып болгаталар, иртән һәм кичен 1 әр аш кашыгы кабалар. Яисә вак кына туралган ярты лимон һәм 7-8 бүлем сарымсакны пыяла банкага салып, өстенә кайнатып суытылган

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

ган ярты литр су коялар, караңгы урында 4 тәүлек тонәткәч, суыткычта саклыйлар, иртән ашарга 20 минут кала 1 әр аш кашыгы эчәләр. Болай дәвалануны өзмичә, октябрьдән март азагына кадәр дәвам итү яхшы.

10 октябрь (сишәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 2.24 сәгатьтә калка, 17.06 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.55 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Сихәтле чәй

Менә мондый чәй дә иммунитетны ныгыта: иртән 1 әр аш кашыгы гөлҗимеш җиләге һәм вакланган андыз тамырын 1литр кайнар суга салып, сүрән утта 10-15 минут пешерәләр, 20 минут төнәткәч, 1 әр аш кашыгы сары мәтрүшкә һәм мәтрүшкә үләннәре, 2 бал кашыгы яшел яки кара чәй өстиләр дә, 1 сәгать төнәтәләр. Аннары, кайнар су белән сыеклап, көн буена эчәләр.

11 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 17.11 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.51 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

12 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 3.40 сәгатьтә калка, 17.16 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.46 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

13 октябрь (җомга). ***Рабигүл әүвәл аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 4.56 сәгатьтә калка, 17.20 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 10.41 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Ананаслы салат

3 йомырка, 5 консервланган ананас бөҗрасы,100 грамм сыр, 2 бүлем сарымсак, майонез кирәк. Сырны, йомырканың агын аерым, сарысын аерым уалар, ананас бөҗраларын вак кына турыйлар, майонезга сарымсак издереп кушалар. Зур сай тәлинкәгә иң аска уылган йомырка агын, аннары ананасны җәяләр, әз генә майонез сылыйлар, аннары уылган сырны җәеп, тагын сарымсаклы майонез сылыйлар да, өстенә уылган йомырка сарысы сибәләр.

Аш догалары

Аш-су өчен кылына торган догалар тәкъдим итәбез.

Аш-мәҗлесне, һичшиксез, **«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим»** дип башларга һәм ошбу доганы укырга кирәк:

«Әллааһүммә бәәрик ләнәә фииһи вә этъгыймнәә хәйран минһү. Әллааһүммә әгътыйнәә ризкан хәләәлән вә әнтә хайрур-раазикыйин. Әллааһүммә нәввир кулүүбәнәә вәрхәмнәә вәрьда ганнәә. Вә әгътыйнәә тәмәәмә нигъмәтикә вә дәвәәмә нигъмәтикә вә тәмәәмә тәүфиикыйкә».

(Әй Аллаһым! Ашларыбызга бәрәкәт бир, болардан да хәерлерәк ашларны ашарга насыйп кыл. Безгә хәләл ризык бир, чөнки Син ризык бирүчеләрнең иң хәерлесе. Аллаһым! Күңелләребезне яктырт, безгә мәрхәмәт ит һәм бездән разый бул. Безгә нигъмәтеңнең дәвамын һәм тәмамын әйлә, йә Рабби!)

Әгәр бисмилләне әйтү онытылып, ашаганда искә төшсә, ошбу дога укыла:

«Әллааһүммә бәәрик ләнәә фил-әүввәли вәл-әәхыйрь».

(Әй Аллаһым! Безнең өчен башын да, ахырын да бәрәкәтле кыл!)

Ашап бетергәннән соң биргән нигъмәтләре өчен Аллаһыга шөкрана һәм хәмде-сәнә әйтергә кирәк. Ашау-эчү догалары Аллаһыга шөкер, рәхмәт һәм ризалыкны белдерергә тиеш.

«Әл-хәмдү лилләәһилләзии этъгамәнәә вә сәкаанәә вә җәгаләнәә минәл мүслимиин. Вәл-хәмдү лилләәһи раббил-гааләмиин».

(Аллаһыга мактау булсын. Безне ашаткан, эчерткән һәм мөселман булуыбызны насыйп әйләгән Аллаһыга мактау булсын. Мактау булсын Галәмнәрнең Раббысы – Аллаһыга).

Аш-су өчен кылына торган башка бер дога:

«Әл-хәмдү лилләәһилләзии халәкаль-инсәәнә вә этъгамәһүү вә сәкааһү вә җәһһәзәһүү бил-иимәән. Вә нәхмәдүһүү лимән мәййәзәл-хәләәлә минәс-сәййи-әәти вәл-хәраам. Вә кассәмәр-ризка галәә халькыйһии би әхсәнил-үслүүби вә әркан-низаам. Вә нүсалли вә нүсәллиму галәә мән үрьсилә рахмәтән лил-гааләмиин».

(Инсанны яратып, ашатып-эчерткән һәм күңеленә иман нигъмәтләрен урнаштырган Аллаһыга мактау булсын. Мактау булсын хәләл белән хәрамны бер-берсеннән аерган Аллаһыга. Яратканнарына ризыкларны иң гүзәл рәвештә өләшеп, инсаннарга иң яхшы низам-тәртипне бирүче – Улдыр. Галәмнәргә рәхмәт буларак күндерелгән Мөхәммәдкә салават-сәлам булсын).

Икенче бер аш догасы:

«Әл-хәмдү лилләәһилләзии этъгамәнәә вә сәкаанәә вә җәгаләнәәә минәл мүслимииин. Вәл-хәмдү лилләәһи вә бәракәәтүһүү галәә саахибит-тагами вәл-әкилиин. Әллааһүммәҗгаль нигъмәтәнәә дәә-имән вә диинәнәә каа-имән вә әүләдәнәә гаалимән саалихән вә ләә түсәллитъ галәйнәә заалимән. Әллааһүммә зид нигъмәтән кәсииратән би хүрмәти сирри сүүратил-фәәтихә».

(Безне туендырган, эчерткән һәм безне мөселман итеп кылган Аллаһыга мактау булсын. Аллаһыга мактау, бу ашның хуҗасына һәм ашаганнарга Аллаһының бәрәкәтләре булсын. Аллаһым! Безнең нигъмәтләребезне дәвамлы, динебезне таянычлы, балаларыбызны галим вә салих кыл. Безнең өстебезгә бернинди дә залим җибәрмә. «Фатиха» сүрәсенең сере хөрмәтенә безгә биргән нигъмәтләреңне тагын да арттыр, Аллаһым!)

Бу догаларның берсен дә белмәгән кеше, «Мин дога белмим» дип, өстәл артыннан дога кылмыйча тормасын. Бу кешеләр:

«Аллаһым! Биргән нигъмәтләреңә, исәнлек-саулыгыбызга мең шөкер итеп Сине мактыйбыз. Безне һидаять юлыннан аерма. Даими хәләл ризыклар ихсан ит», – дип тә дога кылырга мөмкин.

Өйдән чыкканда укыла торган дога

Мөселман кешесенең калебе һәрвакыт Аллаһка бәйле булырга тиеш. Шуңа күрә дә, өебездән чыгып киткәндә, бар эшебезне Аллаһка тапшырып, аны зикер итеп чыгып китәргә тырышырга кирәк. Әлеге зикерне әйтеп чыксак, хәерле булыр:

«Бисмилләһ, тәүәккәлтү галәАллаһ, үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ» – «Аллаһ исеме белән. Мин Аллаһка тәвәккәл иттем һәм Аллаһтан башка көч тә, куәт тә юк» (Әбү Дауд риваяте).

Ә менә өйгә кайтып кергәч, ишектән кергәндә, менә бу зикерне әйтергә онытма:

«Бисмилләһи үәләҗнә үә бисмилләһи хараҗнә үә галә Аллаһи раббинә тәүәккәлнә» – «Аллаһ исеме белән кердек вә Аллаһ исеме белән чыктык һәм Раббыбыз Аллаһка тәвәккәлләдек» (Әбү Дауд риваяте).

Дибәҗә Каюмованы искә алу

Татар Ямалыда туып-үскән Дибәҗә Каюмова да – иҗат мирасы гаять бай, күпкырлы әһелләренең берсе. Проза һәм поэзиядә каләм чарлап, халыкчан әсәрләр иҗат иткән, якты хатирәләр калдырган шәхес. Ул Алабуга шәһәрендә озак еллар студентларга белем биргән остаз-укытучы да әле.

Татар Ямалы авылы мәдәният йорты, китапханә хезмәткәрләре, Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте укучылары һәм укытучылары, «Чулман» әдәби-музыкаль берләшмәсе тарафыннан Дибәҗә Каюмованың туган авылында аның истәлегенә багышланган иҗади кичә үткәрелде.

Зур чараны авылдашлары күңел биреп, яңача сулыш өреп оештырганнар.

– Шагыйрә һәм үзешчән композитор Дибәҗә Каюм кызын искә алу кичәсе үткәрү идеясе тугач, аның балалары, туганнары, көллият коллективы белән элемтәгә чыктык. Һәркем хуплап алды, ярдәм иттеләр. Дибәҗә апаның эшчәнлеге, гаиләсе һәм иҗаты турында мәгълүматларны бөтен авылыбыз белән бергәләп эзләдек. Нәсел шәҗәрәсе төзелде. Мәктәп коллективы, укучылар да бу эшкә кушылды, – дип сөйли Татар Ямалы мәдәният йорты директоры Айсылу Нургалиева.

Кичәне Алабуга шәһәренең сәхнә йолдызлары кичәнең үзгә бер яме булды. Җыр-биюгә өйрәтүче, мәдәният-сәнгатьнең нечкәлекләренә төшендерүче укытучылар белән укучылар – барысы бер коллектив. Осталыклары сокландыра. Авыл сәхнәсенә генә түгел, барлык актанышлылар өчен дә яңа сулыш алып килгәннәр. Араларында Актаныш егете – биергә өйрәтүче остаз Илнар Рафил улы да бар иде. Алабуга көллиятендә бию бүлеген тәмамлаган, хәзер укытучы булып эшли. Куелган күп кенә биюләрнең авторы.

Алып баручылар Илсаф Хәлиуллин белән Татарстанның атказанган артисты Диләрә Мироваева – тәрбияви, иҗади, истәлекләргә бай чараның һәр мизгелен сәйләп итеп тезде.

Агыйдел суында тирбәнеп, болын-кырларда сихәт табып, гомер буе туган якка мәдхия җырлаган шагыйрәбез Дибәҗә Каюмованың шигырьләре сагыну хисе белән сугарылган. Искитмәле табигате, күркәм кешеләре булган Татар Ямалы авылы аның балачак эзләрен әле дә югалтмыйча саклый. Гомер юлы да шушындагы болыннар кебек матур, Агыйдел елгасы кебек киң, чиста.

Яхшы кешенең дуслары да күп була. Шуның мисалы буларак, зал тулып тамашачы килгән. Актаныш, Яр Чаллы, Алабугадан мәртәбәле кунаклар да кайткан. Кичәне Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятенең «Кама таңнары» бию ансамбле башлап җибәрде һәм яңадан-яңа чыгышлары белән хозурлыкка күмде. «Йолдызлык» бәйгесенең гранпри бүләген яулаган коллектив ул.

Татар Ямалы авыл җирлеге башлыгы Дамир Вәлиев кунакларны: «Танылган язучыларны, сәнгать хезмәткәрләрен, көллият вәкилләрен үзебезнең җирлектә каршы алуга без бик шат. Бу чара балаларга үрнәк, олы мирас булып калсын иде, – дип сәламләде.

– 2016-2017 елдан бирле «Кече Ватан» проекты гамәлдә. Туган җирдә үсеп чыккан данлыклы кешеләребезне данлау, шәҗәрәләр төзү, тарихыбызны барлауга багышлана ул. Быел узәкләштерелгән китапханә коллективы яңа тәкъдим кертте. Һәрбер җирлектә китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләре үзләренең язучыларын, шагыйрьләрен хөрмәтләп, кичәләр оештыра. Бүген без һәр җирлектә чын патриотлар тәрбияләргә тиеш. Данлыклы кешеләрне хөрмәтләп, киләсе буыннарга җиткерү өчен эшләнә бу, – дип, район башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Дилбәр Әнвәрова әлеге очрашуның төп асылын аңлатты.

Дибәҗә Каюмова шагыйрә генә түгел, ә педагог та. Йөзләгән укучыларга белем биргән, һөнәргә өйрәткән. Быел – Педагог һәм остаз елы. Лаеклылар хөрмәтләнә.

– Үзем дә Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятендә укыдым. 34 ел китапханәдә эшлим. Алабуга кунакларын күреп сөендем, туганнарым шикелле якын тоелды. Төпле белем бирделәр. Без, китапханәчеләр, быел туган якка багышланган яңа проект игълан иттек. «Туган ягым шәхесләре» дип атала. Һәрбер авылда аларны яшь буынга күрсәтү, тарихи мәгълүматлар туплап бару – төп максат. Иске Богады, Әтәс, Кужәкә, Уразай һ.б. авылларда мондый чаралар үткәрелде. Бүген – Татар Ямалысында очрашабыз, – диде Актаныш үзәк китапханәсе җитәкчесе Гөлназ Әхмәдишина.

Китапханәчеләр көллият коллективына Актаныш турында китаплар бүләк итте. «Агыйдел дулкыннары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Лилия Шәйгәрданова 1957 елда барлыкка килгән берләшмәнең беренче җитәкчесе Суфиан Поварисовны телгә алды.

Кичәдә Дибәҗә Каюмованың шигырьләре дә яңгырады. Иҗатында мәхәббәт, авыл темасы, лирика өстенлек итә. Якташыбызның шигырьләре шома, матур язылган. Берничә тапкыр укып чыгуга хәтергә уелып кала.

Хәтер кичәсендә Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, язучы-якташларыбыз Әлфия Ситдыйкова, Айгөл Әхмәтгалиева, Лира Ибраһим катнашты.

Дибәҗә ханым Алабуга мәдәни-агарту училищесында 30 елдан артык эшләгән. Татар, рус, чит телләр әдәбиятыннан белем бирә. Читтән торып уку бүлеген җитәкли. Исеме көллият тарихына алтын хәрефләр белән язылган.

Уку йортының хәзерге директоры, филология фәннәре кандидаты Әлфирә Әкбәрова авыл халкына соклануын белдерде:

– Дибәҗә апа буыны эшләгән уку йорты хәзер дә абруен югалтмаска тиеш. Аларның традициясен дәвам итәбез, үзебезчә яңартабыз, яшәртәбез. Уку методикасын заманага яраклаштырып көйлибез. Без студентларыбыздан мәдәният хезмәткәре ясыйбыз. Чөнки көллияттә укыган кеше мәдәниятнең бер генә өлкәсендә дә югалып калмаска тиеш. Дибәҗә апаны бары тик яхшы яктан искә алабыз. Бөтен студентларны исеме белән хәтерләве сокландыра иде. Киләсе елда, 90 еллыгына багышлап, Дибәҗә Каюмова турында китап чыгарырга ниятлибез.

Дибәҗә Каюмованың хис-кичерешләрен авылдашы, районыбызның чын-чын артисткасы Альбина Хөсәенова (Мусина) төрле эпизодик күренешләрдә тасвирлады. Аның монологлары аша Дибәҗә Каюм кызының бөтен тормыш юлы күз алдыннан узды.

Дибәҗә апа белән Афзалетдин абыйның балалары Алабугада яши. Кызлары Алсу һәм уллары Алмаз медицина өлкәсендә эшли. Очрашуга кызы да кайткан. Алсу Латыйпова әнисе турында якты истәлекләрен безнең белән дә уртаклашты.

– Әни турында якты хисләр белән сөйлисез. Ана телен онытмау, югары дәрәҗәдә саклау үзебездән тора. Әлеге кичә әнинең рухына дога булып ирешсен.

Кичә Дибәҗә апаның «Аналарның кулын үбик» дип аталган нәсерен уку белән тәмамланды.

Филиза СӘЛАХОВА.
Актаныш.

Туган як илһамы

Безнең Актаныш районындагы Кужәкә авылында халык тырышып эшли дә, матур итеп ял итә дә белә. Нәүрүз, Карга боткасы, Сабантуйларны халык көтеп ала. Авыл көннәрен үткәргәндә тарихыбыз барлана, үткәннәрне чагылдырган күргәзмәләр эшләп куела. Яшь буынга гореф-гадәтләребезне тапшыру максатында кич утыру, аулак өй, кичке уен күренешләре дә күрсәтелә. Соңгы елларда урам бәйрәмнәре үткәрү традициягә кереп бара. Шулай ук якташ язучыларыбыз иҗатына багышланган китаплы, әдәби-музыкаль кичәләрне дә халык көтеп ала. Бу чараларда язучыларыбыз үзләре дә катнаша.

Язучының үзе катнашында үткәрелгән мондый чаралар китап укучыларда көчлерәк тәэсир калдыра, китап белән кызыксынуны арттыра. Алар иҗатында туган якка мәхәббәт, авылыбыз кешеләренә мәдхия җырлана. Безнең авылдан да танылган әдәбият-сәнгать әһелләрен биргән. Язучы Әлфия Ситдыйкова, артист Асия Харисова, профессор-шагыйрь Филүс Хисаметдинов, Әлмәт шәһәрендә яшәп иҗат итүче Гөлгенә Мәрдәмшина, Яр Чаллының сәнгать дөньясында кайнаучыларыбыз Регина Шаехова, Илдус Газизов, Раушания Салахова-Газизова, Түбән Кама шәһәрендә яшәүче Тимергали Мусин, Хуҗәмәт авылында иҗат итүче Наилә Валиева-Хәким һ.б. Ә илһамны аларга, әлбәттә, туган ягыбыз бирә.

Күптән түгел Наилә Вәлиева-Хәкимова иҗатына багышлап әдәби-музыкаль кичә үткәрдек. Язылган әсәрләре басылып чыгу – һәр каләм иясе өчен зур шатлык. Наилә ханымның да «Мәйдан» журналының 2023 елның июнь ае санында «Миңсылу» дип исемләнгән бәяне дөнья күрде. Кичәдә шушы әсәрдщн тыш, язучының иҗат эшчәнлеге белән таныштырдык. 2019 елда дөнья күргән «Кош язмышы» китабының шигырьләрен дә тыңладык. Мондый чараларга читтә яшәүче авылдашларыбыз да кайта. Бәйрәмнәр авыл халкын берләштерә, үткәннәребезне хәтердә яңарта.

Ләйсән АКМАЛОВА.
Актаныш районы,
Кужәкә авылы.

Чүп өчен – кырык тартма...

Швейцариянең кайсы төбәгенә генә барма, бөтен җир ялт иткән. Бу – чүпне тәфсилләп бүлү һәм дөрес урынга түгү нәтиҗәсе. Чүпне сортларга бүлү системасы биредә иң камил дәрәҗәгә җиткерелгән. Илдә яшәүче һәркем – баймы ул, ярлымы – чүпне сортларга аерып ташларга тиеш, алайса штраф түләячәк. Биредә бөтен кешегә чисталыкта яшәү ошый, чөнки менталитетлары шундый. Шешә тапшыру буенча Швейцария дөньяда беренче урында – тараның 90 проценттан артыгы пыяла эшкәртү заводларына кире әйләнеп кайта. Файдаланылган пыяланы кабул итү һәм кабат эшкәртү буенча программа 1972 елда гамәлгә кертелгән һәм хәзергә кадәр уңышлы тормышка ашырыла. Әле төрле төстәге шешәләрнең һәркайсын аерым тапшырырга кирәк. Кәгазь һәм катыргы да аерым җыела, илдәге басма продукциянең өчтән бере икенчел чимал җыю пунктларына кире кайта. Илдә сатылган батарейкаларның 60 проценты чүпкә ташланмый, ә кире тапшырыла. PET-шешәләр – аерым, иске электр җиһазлары һәм көнкүреш техникасы – аерым, төзелештәге калдыклар – аерым, лампалар – аерым, консерв банкалары (аларны башта һәркем үзе магнит прессы ярдәмендә калай итеп җәяргә тиеш) – аерым, хайван үләксәләре – аерым (моның өчен түләргә кирәк, тик аларны күмеп кую тыела), үсемлек мае калдыклары – аерым, машина мае калдыклары – аерым (үз автомобилеңдә майны алыштыру катгый тыела – 50 франк түләп, моны техстанциядә эшләтәләр), ризык калдыклары аерым тапшырыла. Әйе, ялкаулар чүпне сортларга бүлмәсә дә була, әмма аның һәр килограммыннан салым түләргә кирәк, һәр чүп капчыгына салым түләгәнлекне раслый торган марка ябыштырыла. 5 килограмм чүп ташлау 2-3 франк тора. Шунлыктан күпчелек бөтен кирәкмәгән нәрсәне икенчел чимал кабул итү пунктларына илтә – бусы бушлай. Маркасыз ташланган чүп хуҗаларын исә махсус полиция тиз арада исәпләп чыгара һәм зур штраф сала. Хәтта файдаланылган һәр чәй төргәгенең этикеткасын – катыргы, чәй түбен – компост, пакетның үзен – кәгазь, беркеткечен – металл, ә җебен марка ябыштырылган чүп капчыгына салырга кирәк. Һәм бу – шаяру түгел, чынбарлык.

(“Tages-Anzeiger”).

Йөрәк картаймасын!

Акыл зәгыйфьлегенең кайчан башланасын төгәл билгеләве бик кыен. Чөнки бу акылдан шашу да, психикадагы тайпылышлар да, чир дә түгел. Ул кинәт башланмый, ә еллар буена әкренләп “көч туплый”. Табибләр шулай да тиз арада баш миен кайгырту зарурлыгына күрсәтә торган кайбер билгеләрне ачыклаган. Беренчесе – тәнкыйтьне кабул итмәү, гадәттән тыш үпкәләүчәнлек. Икенчесе – яңа нәрсәләрне өйрәнергә теләмәү: мәсәлән, яңа телефон алганчы, кеше үзе индеияләшкән искесен төзәттерүне кулайрак саный. Өченче билге – игътибарны туплау кыенлашу: җитди әдәбиятны аңлавы катлаулана, укылганнар бик тиз онытыла. Китап уйландырмый торган, фильм исә кәефне күтәрә торган булырга тиеш – нигә әле баш ватып азапланырга, яшәү болай да шәп бит! Дүртенче билгесе – гадәттән тыш эгоцентризм: кеше үзенең әйләнә-тирәсендәге һәркем аның турында гына кайгыртырга, аның тирәсендә биеп йөрергә тиеш, дип саный. Бишенче билгесе – ностальгия өянәкләре, үткәннәрне бик еш сагыну. Менә шул бөртекләрдән картайгач акыл зәгыйфьлеге башлану ихтималы җыела да инде. Шунлыктан һәрвакыт яңалыкка омтылырга, яңа белем алырга, дөньяның гүзәллеге белән хозурланудан туктамаска кирәк.

(“Лента.ру”).

Иң ярлы президент

2015 елның гыйнварында Уругвайда гади эшче Геральд Акоста өенә кайтыр өчен юлда машина туктатмакчы булып басып тора. Утызлап машина узып китә, аннары ниһаять бер иске “Фольксваген” туктый. Акоста утыра һәм гаҗәпләнүдән телсез кала. Рульдә Уругвай Президенты Хосе Мухика үзе бара икән, янәшәсендә – хатыны белән эте. Ул илдә 2010 елдан 2015 елга кадәр хакимлек итә һәм бик тыйнак яшәве белән тарихка кереп кала. Мухика һәм аның сенатор хатыны чәчәкләр үстерә торган иске фермада яши һәм барлык хуҗалык эшләре белән дә үзләре шөгыльләнә. 12 мең долларлык эш хакының 90 процентын президент хәйриячелеккә күчереп бара. Машинасына инде 30 елдан артык, гарәп шәехе аны 1 миллион долларга сатып алмакчы була, әмма Мухика ризалашмый – үзенең өч аяклы этен утыртып йөрер өчен бик җайлы икән автомобиле. Ул хакимлек иткән чорда Уругвайда марихуана сату рөхсәт ителә, бу – дөньяда шундый беренче ил. Президентлык срогы беткәч, Мухика сенаторга әйләнә, әмма 2018 елда үз вәкаләтләрен вакытыннан алдарак башка кешегә тапшыра һәм дәүләт пенсиясеннән баш тарта.

(“The Local”).

Бельгиядәге мини-Европа

Брюссельнең төньягындагы “Мини-Европа” – Бельгия башкаласындагы иң истәлекле урыннардан берсе. Анда ел саен 350 мең кунак була. Өч футбол кыры кадәр мәйданда Европаның 80 шәһәрендәге йөзләрчә данлыклы бинаның төгәл күчермәләре урнаштырылган. Алар барысы да бик җентекләп, тик 25 тапкыр кечерәйтеп эшләнгән. Мәсәлән, 324 метрлы Эйфель манарасы – 13 метрлы. Паркта Париждагы Триумф аркасы һәм Изге Ана соборы, Бранденбург капкасы һәм Берлин дивары, Афина Акрополе һәм Пиза манарасы, Венециядәге Дожлар сарае һәм Лондондагы Парламент (Биг-Бен белән бергә) бинасы, Һолландиядәге җил тегермәннәре һәм Төньяк диңгездәге нефть платформасы макеты бар. Везувий вулканы һәм Жак-Ив Кусто корабле кебек көтелмәгән экспонатлар да шактый. Брюссельдәге Гран-Плас макетын ясау 350 мең еврога төшкән. Паркны бөтен Европа бергә төзегән: мини-Парижны – Франция, немец ядкәрләрен Германия, антик биналарны Италия акчасына салганнар. Эстония Таллинндагы “Юан Маргарита” манарасын, Латвия – Ригадагы Бәйсезлек һәйкәле күчермәсен, Литва – Вильнюс университеты кампусы миниатюрасын төзеп биргән.

(“Die Presse”).





Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

9 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Акыл батл» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Татарстан без коррупции». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
23.00 «САДОВНИЦА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Празат Исәнбәт турында телеочерк. 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Калеб». 6+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Секретные материалы. Ключи от долголетия». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЛЮБОВЬ НАПРОКАТ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СЕРДЦЕ АНГЕЛА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Удиви меня». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «МАРЬИНА РОЩА». 16+
23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «БИЗОН. ДЕЛО МАНЕКЕНЩИЦЫ». 16+
23.55 Подкаст.лаб «Пусть не говорят, пусть читают». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Осор Будаев.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ТОЛЬКО В МЮЗИК-ХОЛЛЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Мастера искусств. Народный артист СССР Павел Массальский».
12.10 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 Большие и маленькие.
14.55, 23.35 «Три минуты тишины».
15.00 Линия жизни. Анна Якунина.
15.55 «Агора».
17.20 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Победители.
18.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Дмитрий Антонов. «Советские иконы - уникальные религиозные артефакты эпохи гонений».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Собибор. Непокоренные».
21.45 «Сати. Нескучная классика...»
22.30 «12 СТУЛЬЕВ».
23.50 «Магистр игры». «Что отразилось в «Лебедином озере». Чайковский, Пруст, Рудольф Нуреев».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Сишәмбе

10 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 15.00, 19.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.30, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
12.30 Хоккей. «Адмирал» - «Ак Барс». 6+
15.15 «Семь дней+». 16+
15.45 «Учимся вместе».
16.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Заман көзгесе». 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Tatarstan toeay. Открытый миру». 16+
23.00 «САДОВНИЦА». 12+
0.55 «Не от мира сего...» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАРЬИНА РОЩА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СЕРДЦЕ АНГЕЛА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Удиви меня». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «БИЗОН. ДЕЛО МАНЕКЕНЩИЦЫ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почерк эпохи». «Ильф и Петров. Великие комбинаторы».
8.00 «Забытое ремесло».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35, 22.30 «12 СТУЛЬЕВ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Олег Даль. Рассказывает Юрий Поляк.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Не только цирк».
11.55 «Краснодар. Особняк Василия Рубежанского».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 Оттепель. В добрый час. Татьяна Доронина. Рассказывает Анастасия Дьячук.
13.20 «Игра в бисер» «Александр Блок. «Скифы».
14.05 «Жозефина де Богарне. Любовь Наполеона».
14.55, 23.35 «Три минуты тишины».
15.00 «Истории в фарфоре».
15.30 Больше, чем любовь.
16.15 «Сати. Нескучная классика...»
17.15 «Эрмитаж».
17.45 Оттепель. В добрый час. Олег Ефремов. Рассказывает Дмитрий Лысенков.
18.00 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Победители.
19.10 Оттепель. В добрый час. Евгения Уралова. Рассказывает Евгения Ивашова.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Марьяна Скуратовская. «Мода Серебряного века».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.45 «Белая студия».
23.50 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Чәршәмбе

11 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Соотечественники». 16+
23.00 «САДОВНИЦА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннар турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАРЬИНА РОЩА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «СЕРДЦЕ АНГЕЛА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Удиви меня». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «БИЗОН. ДЕЛО МАНЕКЕНЩИЦЫ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почерк эпохи». «Владимир Татлин. Летатлин...»
8.00 «Забытое ремесло».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35, 22.30 «12 СТУЛЬЕВ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Татьяна Лаврова. Рассказывает Дарья Урсуляк.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Гибель Марины Цветаевой».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Оттепель. В добрый час. Владимир Ивашов. Рассказывает Павел Чинарёв.
13.20 Искусственный отбор.
14.05 «Лоренцо Медичи. Некоронованный король Флоренции».
14.55, 23.45 «Три минуты тишины».
15.00 «Истории в фарфоре».
15.30 Больше, чем любовь.
16.10 «Белая студия».
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 Оттепель. В добрый час. Геннадий Шпаликов. Рассказывает Даниил Шперлинг.
18.00 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Победители.
19.10 Оттепель. В добрый час. Алексей Баталов. Рассказывает Максим Севриновский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Федор Софронов. «Распространение джаза в СССР».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.45 Власть факта. «Советский авиапром. История взлета».
23.50 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Пәнҗешәмбе

12 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+
11.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
12.00 Хоккей. «Амур» - «Ак Барс». 6+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Шома бас», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
16.00 «Татарлар». 12+
17.30, 19.00 «Точка опоры». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Соотечественники». 16+
23.00 «САДОВНИЦА». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Гаилә учагы». 16+
10.00 «Туган авылым». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Tatarstan toeay. Дөньяга ачык». 12+
21.25 «Йөрәктән-йөрәккә». И.Биктаһиров турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАРЬИНА РОЩА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.45 «СЕРДЦЕ АНГЕЛА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Удиви меня». 12+
16.30 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «БИЗОН. ДЕЛО МАНЕКЕНЩИЦЫ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+

11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИХОРАДКА». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почерк эпохи». «Юрий Олеша. Ни слова фальши».
8.00 «Жизнь и судьба».
8.20, 22.30 «12 СТУЛЬЕВ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Татьяна Самойлова. Рассказывает Полина Рафеева.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Ансамбль Александрова».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 Оттепель. В добрый час. Никита Михалков. Рассказывает Юрий Цокуров.
13.20 Абсолютный слух.
14.05 «Мария-Антуанетта, последняя королева Франции».
14.55, 23.45 «Три минуты тишины».
15.00 «Истории в фарфоре».
15.30 Больше, чем любовь.
16.10 «2 Верник 2».
17.15 Моя любовь - Россия! «Филимоновская игрушка».
17.45 Оттепель. В добрый час. Евгений Урбанский. Рассказывает Василий Симонов.
18.00 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Победители.
19.10 Оттепель. В добрый час. Владимир Земляникин. Рассказывает Севастьян Смышников.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Шамиль Идиатуллин. «До февраля».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Человек-амфибия». Любовь с первого взгляда».
21.45 «Энигма. Надежда Павлова».
23.50 «Запечатленное время».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.10, 0.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Җомга

13 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Татарча диктант».
14.45 «Секрет дней+». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «НЕВЕСТА МОЕГО ДРУГА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.30, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.30, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.00, 19.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Татар җыры-йөз ел элек». 16+
13.00 «Татарча диктант». 6+
15.25 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 16+
21.25 «Кто мы татары? Тюркский каганат и древние татары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МАРЬИНА РОЩА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.00 «ТАНЦОР ДИСКО». 16+
15.30 «Удиви меня». 12+
16.30 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Уже не дети». 12+
23.50 К 60-летию со дня рождения Валентина Юдашкина. «Матадор». «Haute couture». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Истории Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Почерк эпохи». «Всеволод Багрицкий. Осколки...»
8.00 «Жизнь и судьба».
8.20 «12 СТУЛЬЕВ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Андрей Миронов. Рассказывает Михаил Тройник.
10.20 «АНТОН ИВАНОВИЧ СЕРДИТСЯ».
12.00 Открытая книга. Шамиль Идиатуллин. «До февраля».
12.45 «Забытое ремесло».
13.00 Оттепель. В добрый час. Станислав Любшин. Рассказывает Максим Керин.
13.20 Власть факта. «Советский авиапром. История взлета».
14.05 «Вильгельм Завоеватель. Герцог Нормандии на английском троне».
14.55, 21.50 «Три минуты тишины».
15.00 «Истории в фарфоре».
15.30 Больше, чем любовь.
16.15 «Энигма. Надежда Павлова».
17.15 Письма из провинции.
17.45 Оттепель. В добрый час. Олег Табаков. Рассказывает Владислав Миллер.
18.00 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Победители.
18.30 «Царская ложа».
19.10 Оттепель. В добрый час. Инна Гулая. Рассказывает Мариэтта Цигаль-Полищук.
19.45 «Траектория «Успеха».
20.25 «УСПЕХ».
21.55 Линия жизни.
22.55 «ЗОВИ МЕНЯ ДРОЗД».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.10 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+

Шимбә

14 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Синең Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кайнар хит». 16+
10.00 Хоккей. «Амур» - «Ак Барс». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Татарча диктант».
14.30 «Гаилә учагы». 16+
15.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
15.30 «Туган авылым». 12+
15.45 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар. 16+
17.00 «Күңелләрдә тальян моңнары». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «СТАЖЁР». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». И.Бикташиров турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Синең Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кайнар хит». 16+
10.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Татарча диктант». 6+
17.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 16+
22.35 Спектакль «Җилкәнсезләр». 16+

«ЭФИР»

5.00, 14.35 «Заповедники РФ». 12+
6.00 «Легенды кино». 16+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Салют-7. История одного подвига». 6+
8.50 «ПАПА В ЗАКОНЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ТЫ БУДЕШЬ МОЕЙ». 12+
15.00 «Ночной дожор». 12+
15.55 «ФРАНЦУЗСКАЯ КУЛИНАРИЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖАНДАРМ ЖЕНИТСЯ». 16+
22.30 «СВЕТ И ТЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 К 90-летию со дня рождения Марка Захарова. «Я оптимист, но не настолько...» 12+
14.00 «ФОРМУЛА ЛЮБВИ».
15.45 «Горячий лед». Фигурное катание.
17.00 К 60-летию со дня рождения Валентина Юдашкина. «Маэстро русской моды». 12+
18.20 «Михаил Задорнов. вся жизнь». 16+
19.15 «Эксклюзив». 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.20 «ВЕЛИКИЙ». 18+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Парад юмора». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МОЕЙ ЛЮБИМОЙ». 16+
0.35 «МОЯ ЧУЖАЯ ЖИЗНЬ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.40 «ПУТЕШЕСТВИЕ МИССИС ШЕЛТОН».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «УСПЕХ».
11.50 «Эрмитаж».
12.20 Земля людей. «Чуваши. В белых одеждах».
12.50 Черные дыры. Белые пятна.
13.35 «Лазурная обитель».
14.20, 23.00 «Три минуты тишины».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.20 К 95-летию Ансамбля песни и пляски Российской армии имени А.В. Александрова. Концерт в КЗЧ.
16.05 Большие и маленькие.
18.10 «Энциклопедия загадок».
18.40 «Доминанты».
19.45 «ТАНЦОР ДИСКО».
22.00 «Агора».
23.05 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

15 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00, 0.45 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева. 16+
8.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Дуслык иленДә». 12+
11.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.00 «Татарча диктант».
14.30 «Уңыш - Урожай-2023». 16+
15.30 «Погружение на 100». 12+
15.40 «Татар халык җырлары».
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «НУ, ЗДРАВСТВУЙ, ОКСАНА СОКОЛОВА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Кто мы татары? Тюркский каганат и древние татары». 12+
8.00 «Үткәннәрдән киләчәккә сезнең белән җырлап барам». Хәния Фәрхи. 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Илтәзәр Мөхәммәтгалиев турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Татарча диктант». 6+
15.00 «Гаилә учагы». 16+
15.35 «Туган авылым». 12+
15.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.00 «Уңыш 2021». 16+
21.50 Спектакль «Хәйләсез - дөнья файдасыз». 16+

«ЭФИР»

5.00, 8.30, 14.35 «Заповедники РФ». 12+
6.00 «Легенды телевидения». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.55 «ФРАНЦУЗСКАЯ КУЛИНАРИЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЗЕЛЕНАЯ КАРЕТА». 16+
15.00 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.50 «ПАПА В ЗАКОНЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖАНДАРМ НА ПРОГУЛКЕ». 16+
22.45 «БОЛЕЛЬЩИЦЫ СО СТАЖЕМ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Первые лица». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.05 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
13.50 Спектакль «Юнона» и «Авось». 16+
15.25 «Горячий лед». Фигурное катание.
17.00 «Ни шагу назад». 16+
19.00 «Перепой звезду». 12+
21.00 «Время».
23.00 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»

6.10 «ПУТЬ К СЕРДЦУ МУЖЧИНЫ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены». 6+
12.50 «ДЕВЯТЫЙ ВАЛ». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.00 «ЭТО БЫЛО ПРОШЛЫМ ЛЕТОМ».
9.40 Диалоги о животных.
10.20 «Окрыленные».
11.00 «МАТРОС СОШЕЛ НА БЕРЕГ».
12.15 Неизвестные маршруты России.
12.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Нина Соколова.
13.25 «Игра в бисер» «Владимир Солоухин. «Третья охота».
14.05 «Коллекция».
14.35 «ВСЁ НА ПРОДАЖУ».
16.10, 21.50 «Три минуты тишины».
16.15 «Первые в мире».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 «Загадка Шаляпина».
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «НАСТЯ».
22.00 Дж. Верди. «Дон Карлос». Дирижер Герберт фон Караян.

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! Суперсезон». 6+
23.25 «Звезды сошлись». 16+

Чүпрәле районы эчке эшләр бүлегенә «Яңа Элмәледән ир-кеше мәете китерелде», дигән шомлы хәбәр 7 майга каршы төндә килә. 46 яшендәге Сергей Мискинның чәнчеп үтерелүе шик уятмый, табиблар мәрхүм күкрәгенең сул ягында үтәли җәрәхәт булуын билгеләде. Моны шунда булган Алексей Аюгин да раслый, оперативникларга моның үз эше икәнен дә җиткерә. Буада үткәрелгән экспертиза С.Мискинның яра аркасында төп кан тамырлары, сул үпкә киселү нәтиҗәсендә җан биргән күрсәтә.

Исереккә диңгез тубыктан

Фаҗига туганнан туган агай-энеләрнең 6 майда бергәләп эчеп йөрүләре нәтиҗәсендә килеп чыга. Ул көнне 1980 елгы А.Аюгин өйдә була. Карт буйдак җирле хуҗалыкта төрле эшләр башкаручы булып эшләгән, Яңа Элмәледә ялгызы көн күргән. Авылдашлары да начар сөйләми аның турында. Шулай да 20 яшьлек чагында хулиганлык кылып 4 еллык шартлы хөкем алган ул, ләкин шуннан соң законсыз гамәлләре булмаган. Өч яшькә өлкәнрәк абыйсы Сергей Мискин Мәскәүгә йөреп эшләгән, дүрт балалы гаиләне матди яктан тәэмин итеп торган.

Сергей иртән кибеткә киткән җиреннән ике сәгать чамасы югалып тора, чөнки бер шешә аракы алып, энесе янында кәефләнеп кайта. Шуннан соң авыл ирләре икесе дә хуҗалыкларында мунча яга, Алексей юынып чыгарга да өлгерә. Төштән соң анда тагын 40 градуслыны кыстырып Сергей пәйда була. Әлеге шешәне бушаткач, акча биреп, кибеткә А.Аюгинны җибәрә. Алексей тиз барып кайта, әмма кунак йокыга талган була. Ачылмаган шешә ул уянганчы тора. Әсыйланып утыра башлагач, үзара ызгыш чыга.

А.Аюгин аның сәбәбен хәтерләми. Әмма кызып китеп икебез дә торып баскач, Сергейны куркыту өчен өстәлдәге пычакны алып, очын аның күкрәгенә таба юнәлттем, ә ул кинәт ыргылып пычакка үзе кадалды, дигән фикерне алга сөрә. Имеш, пычакны тартып чыгаргач, Мискин караватка барып ята: «Ничего страшного», – дип куя. Аюгин Сергей күкрәгендәге ярадан күбекләнеп кан чыга башлавын күргәч, авыл фельдшерының өенә йөгерә. Анысы, аңлап бетермичә, Аюгин йортына түгел, Мискиннарга кереп, хуҗабикәне аптырашта калдыра. Тиздән фельдшер хатын-кызлар Аюгинның буш өенә килә, андагы кан тапларын, Мискинның киемнәрен күрә.

А.Аюгин фельдшер өеннән чыккач та, төн уртасында клуб янында кайнашкан яшьләр янына йөгерә, 21 яшьлек егет Мискинны сырхауханәгә илтергә ризалаша. 7-8 чакрым араны узганчы Сергей берничә тапкыр аңын җуя, кабул итү бүлмәсенә керткәч үк, шәфкать туташы аның сулыш алмавын күрә, бу хакта А.Аюгинга да әйтә. Шул арада аңа ирен югалткан, дүрт бала белән тол калган Надежда шалтырата...

Тикшерү комитетының Буа районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Д. Әскаров җинаять эшен аңлы рәвештә үтерү турындагы маддә буенча кузгата. А.Аюгин җинаять урынында С.Мискинның ни рәвешле пычакка кадалуын күрсәтеп бирә. Ләкин мәеттәге яраны тикшергән эксперт аның күрсәтмәләрен хак түгел, дип белдерә. Яралы абыйсына ярдәм чакырып чабулаган, аны сырхауханәгә илтеп куйган Алексейда үтерү нияте булу икеләндерә үзе. Шуңа күрә аңа аз гына җиңелрәк җәза каралган башка маддә буенча хөкем чыгарылу мөмкинлеге дә бар кебек. Монысын инде судья хәл итәчәк.

* * *

Әлмәттә яшәүче өч егет 2023 елны 29 декабрьдә үк каршылый башлый. Р.Мөхәммәтов белән М.Мельников көндез үк уртак дуслары гаражында сыйлана. Аннары Артур Шакиров дигән тагын бер иптәшләрен чакыралар һәм мәҗлесне 36 яшендәге ханым фатирында дәвам иттерергә булалар.

Юлианна (кайбер исемнәр үзгәртелә) ике баласын яңа елны каршыларга Чирмешән районындагы авылда яшәүче әнисе янына озаткан була. Егетләр ишек шакыганчы подъездда да шактый гына аракы чөмерә. Ул чакта ялгыз хатын фатирында өлкәнрәк яшьтәге кунак була инде, әмма танышларын түрдән уздыра ул. Йокысыннан уянып чыккан 53 яшьлек Леонид Башкатов та кушылгач, өстәл янында биш кеше җыела. Бераздан алар өчәү генә кала, чөнки ике сәрхүш, шул исәптән, Леонид агай йокларга ята. А.Шакиров белән М.Мельников кибеттән бер литр аракы алып кайта, өч кеше тагын эчүен дәвам иттерә.

Хәмер дигәнең, иң әүвәл, 1989 елгы А.Шакировның тәртибен үзгәртә. Хуҗабикәнең әйтүенчә, Артур аны җенси мөнәсәбәткә керергә өнди. Шул сәбәпле өйдә ызгыш куба, тавышка уянып Л.Башкатов килеп чыга. Исерек ирләр бәрелешү куркынычы туа. Агай хатын-кызны якларга керешкәч, кухняда кычкырышу гына түгел, үзара бәргәләшә дә башлыйлар. Кухнядагы М. Мельников, тегеләр тынычланган арада, өенә кайтмакчы булып коридорга чыга. Шул мәлдә коридорда Леонид агай, аның артыннан пычак тоткан Артур пәйда була һәм ул качып баручы абзыйның аркасына чәнчи. Ошбу галәмәтне күреп алган Мельников ярсыган егеткә ябыша, ләкин аның «кочагыннан» ычкынган Артур, күрше бүлмәгә кереп, хәлсез Леонидның тетмәсен тетеп ташлый. Моны Юлианна күреп тора.

Мельников һәм йоклап яткан тагын бер егет фатирдан чыгып шыла. Алар «112» коткару хезмәтенә шалтыратып торганда фатирдан ярсу егет тә атылып чыга, дусларына: «Пацаны, меня не сдавайте!» – дип кычкырып баскычтан түбәнгә йөгерә. Әлбәттә, өч шаһит алдында кылынган вәхшәт ачылмый кала торганнар рәтеннән булмый. Ике егет полиция килгәнче урамда тора, аларны күрсәтмә бирергә эчке эшләр бүлегенә алып китәләр.

Л.Башкатовка ярдәмнең хаҗәте калмаган була инде. Чөнки котырынкы бәндә аңа барлыгы 18 тапкыр кадый. Өендә чишенмичә йоклап яткан Шакировны полиция уята. Улының өс киемнәрендәге кан эзләрен күргән 1954 елгы ана, хәвеф-хәтәр булганын аңлап, кара хәсрәткә бата.

Өлкән яшьтәге ханым улы турында начар сөйләми. Мәктәптә әйбәт укыды, көллият тәмамлады, шәһәрдәге «Луч» телекомпаниясендә оператор булып йөрде, Зәй районындагы санаторийда эшләде, ләкин соңгы елларда очраклы шабашкаларга йөрде, ди. Шулай ук улының наркотиклар белән бәйле җинаяте, барып чыкмаган талау очрагы өчен хөкемгә тартылуын да яшерми ул. Моңа алкоголь, берничә төр наркотик матдәләргә бәйле зат буларак наркология диспансерында исәптә торуын да өстик.

Бу очракта адәм баласының аңлы рәвештә үтерелүе аермачык күренә. Җинаять эшендә зарар күрүче итеп мәрхүмнең 29 яшьлек улы чыгыш ясый. Ильяның әйтүенчә, эти-әнисе аңа 10 яшь чакта аерылышкан. Леонид аннан соң Людмила исемле хатын белән торган, аннан да баласы булган, ләкин ошбу гаилә дә таркалган. Илья этисенең нефтьчеләр җәмгыятендә эшләвен әйтә. Леонидның үлеме Җәлил бистәсендә яшәүче 1947 елгы әнисе Хәтимә әби өчен дә чиксез хәсрәт була.

А.Шакиров яңа елны изоляторда каршылый. Әлмәт шәһәр суды 31 декабрьдә аны сак астына ябарга дигән карар чыгара. Беренче күрсәтмәсендә үк барысын да әйтеп бирә ул, хуҗабикәгә «бәйләнә» башлануын да яшерми. Тикшерү комитетының тикшерүчесе С.Сөнгатуллин аңа аңлы рәвештә үтерү-дә гаепләү белдерә. Гаепләү ягы фикере судта да раслау таба һәм А.Шакиров-ны 10 елга кырыс режимлы колониягә озатырга дигән хөкем чыгарыла.

* * *

Ютазы районы үзәге Урыссу бистәсендә пычаклы һөҗүмгә дучар булган 22 яшьлек егетне үлемнән шешәдәше һәм табиблар коткара. Җинаять эше үтерергә омтылыш ясау очрагы буенча кузгатыла.

1979 елгы Марсель Мәрданов Чаллыда туган, Азнакайда пропискада торган, соңгы вакытта Урыссуда яшәгән. Ул наркотик матдәләр кулланучы буларак исәптә торган, ике мәртәбә хөкем ителгән зат. Ләкин эш урынында яхшы бәяләнә, Урыссуда бер хезмәттәше фатирында ялгыз яшәгән, чөнки хатыны һәм бер баласы белән күптән аерылышкан.

Мәгълүм ки, ялгызак эчкечеләр торагында кунаклар бетеп тормый. Мондый «притон»нарда еш кына яшьләр дә җыела. Быел 20 январьда кич белән урамда буталып йөргәч, балигъ булмаган сөйгән кызын иярттеп, анда 22 яшендәге Динар Солтанов килеп керә. Ул чакта Мәрданов һәм тагын бер салмыш егет йокы симертә, өч яшь кеше өстәл артында сыйланып вә гәпләшеп утыра. Шул рәвешле бер түбә астында җиде кеше, шул исәптән, 17 яшьлек Вероника (исеме үзгәртелә) җыела. Бераздан йоклаучылар да уянып хәмерле мәҗлескә кушыла.

Алдан сыра гына йоткалап утырган Динар тиздән аракыга күчә, берара ике мәртәбә өлкәнрәк Марсель белән әйбәт кенә аралаша, ләкин эч торгач, мөнәсәбәтләре кискенләшә. Бәхәс төрмә хәлләре турында сөйләшкәндә чыга. Утырып кайткан Мәрданов яшь малайны санга сукмый. Әйткәләшүләр сугышу-көрәшүгә күчә, иденгә егылып әүмәкләшәләр, бер мәлне чалкан яткан егет өстендә утырган М.Мәрданов пычак чыгарып аның күкрәгенә кадый. Ул үзе дә, салмыш шаһитлар да аның кулына пычакның ничек килеп элгүен аңлата алмый. Ярый әле, Рәмис исемле егет, котырынган Мәрдановның кулларын артка каерып читкә өстери. Хуҗа аның аягын яраларга да өлгерә.

Д.Султанов тавыш күтәрелә башлагач ук урамга чыгып качкан кыз янына чыга. Вероника аның пычак чәнчүләрен хәбәр иткәч тә җиргә егылуын әйтә. Әмма аңын җуймый ул, ашыгыч ярдәм табибларына карыша, сырхауханәгә барасы килми, шулай да ярасын бәйләп, уколлар кадап алып китәләр.

Хирургия бүлеге мөдире А.Грабилов авыруны тикшергәч РКБ белгечләре белән дә киңәшә. Иртә белән аның күкрәк эченә җыела башлаган сыеклыкны суыртырга туры килә. Шөкер, Д.Солтановның сәламәтлеге рәтләнә. Чөнки ике кабырга арасыннан узган пычак төп кан тамырларын кисмәгән, йөрәк, үпкәгә тимәгән була. Шулай да табиблар Д.Солтанов саулыгына китерелгән зыян авыр дәрәҗәдә дип белдерә.

Д.Солтанов сырхауханәнең кабул итү бүлегендә чакта, анда төп коткаручы Рәмисне дә китерәләр, ботындагы яраны эшкәртеп озаталар. Бусы инде кеше сәламәтлегенә җиңел зыян китерү дигән җинаять дип табыла.

Тикшерү комитетының Азнакай районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Рөстәм Яруллин Д. Солтанов күкрәгенең сул ягына чәнчегән М.Мәрданов явызлыгын аңлы рәвештә үтерергә омтылу дип таба. Ә Мәрданов үтерергә теләмәдем дип, ошбу гаепне кире кага. Моның файдасы тими, Ютазы район суды 1979 елда туган М.Мәрдановны ике җинаять кылуда гаепле дип таба һәм 5 елга кырыс режимлы колониягә озатырга фәрман бирә.

Наил ВАХИТОВ.

Гротесклы сәнгать

Казанның «Дом ART» музей-галереясындагы күргәзмәне караучыларның кәефе мизгел эчендә күтәрелә, чөнки бу «АняМаня» иҗат дуэты курчаклары берләштерелгән урында, әйтерсең лә, Кояш нурлары даими рәвештә сирпелеп тора. Бәлкем, әлеге үзенчәлек алар ясаган авторлык шедеврларының чәчләре нигездә бакыр, җирән төстә булулары белән дә бәйледер...

Россиядә генә түгел, башка чит дәүләтләрдә дә мәгълүм игезәкләр дуэты – Анна Афанасьева һәм Мария Колегова үз эшләрен арт-объектлар дип атарга күнеккән, чөнки алар гадәти генә курчакларны түгел, ә мавыктыргыч композицияле, игелекле сюжетлы, кыска тарихлы хезмәтләрне ясый. Аларның курчакларын бер күрүдә танырлык, өстәвенә, алар ниндидер бер шатлыклы хөрлек, атмосфера тудырырга сәләтле. Моннан тыш курчаклар өчен сайлап алынган образлар да, әйтерсең, безнең янәшәдәге кешеләргә, танышларга карап кына ясалган. Аларның күбесе гаилә куанычлары белән дә бәйле, мәсәлән «Мин әтинең песнәге» композициясендәге кечкенә кызчык әтисенең кулларында сөенә, ә аның энесе, апасыннан көнләшеп булыр, атасының чалбар балагын йолкый...

«АняМаня» дуэты 2008 елда оешкан. Осталар 2007 елдан алып актив иҗатта. Күп приз иясе, мәсәлән, алар үз композицияләренең берсе белән 2016 елда мәртәбәле III «Пандора Платинум» Халыкара бәйгесенең «Традицион материаллар кулланып бердәнбер данәдә ясалган курчак» номинациясендә дә җиңеп чыкканнар. Бу факт та югары профессионализм хакында сөйли. «АняМаня» курчаклары дөнья каталогларына кертелгән, дуэт бик күп күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, Мәскәүнең мәшһүр «Вахтановъ» курчак галереясы мәдәни чараларында, «Манеж»да узучы «Курчак сәнгате» халыкара күргәзмәләрендә дә катнаша, алар NIADA – кул хезмәте белән иҗат ителүче үзенчәлекле курчак сәнгатен алга этәрүче рәссам-курчак осталарының бөтендөнья оешмасына да кабул ителгән, ә ул оешмага керү үтә читен, анда бар дөньядан нибары 20 оста гына теркәлгән. Осталар Россия рәссамнарының иҗат берлегенә, Россия рәссамнарының профессионал берлегенә һәм Татарстанның Рәссамнар берлегенә дә кабул ителгән.

Юмор, сатира кушып, гротеск стилендә иҗат итү өчен курчакларның йөзләрендә уңай хис-кичерешләр чагылган булырга тиеш, иҗатчылар моңа оста ирешә. Алар сынлы һәм гамәли сәнгатькә кечкенәдән бирле тартылган. Һәм эшләрендә еш кына үз балачак истәлекләрен дә барлыйлар.

Мондый курчаклар катнаш техникада, каркас ясап, пластик, папье-маше, паперклей, текстиль, челтәр, үзле балчык кулланып эшләнә. Хәзер бар материалларны да заказ белән кайтартып, кибеттә сайлап була, әмма Аня белән Мария «иҗат башында мөһим материалларны беркайдан да таба алмый идек, алар кибетләрдә дә сатылмагач, безгә авыр иде», дип искә ала. Хәзер инде дуэт курчаклары Россия, Европа, АКШ, Бөекбританиядә һ.б. дәүләтләрдә саклана.

Игезәкләр 1982 елда Казанда туган. 3 нче мәктәп-лицейны, шәһәрнең 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбен тәмамлап, Казан театр училищесына укырга кергәннәр. Иҗатчылар – курчаклар буенча рәссам-технолог, бутафор, курчак спектакльләре декораторы белгечләре. Унбер ел дәвамында үз тәҗрибәләрен башкаларга да җиткереп, осталык дәресләрен дә үткәрәләр, алар инде Мәскәү, Питер, Казан, Алматы, Астана, Истанбул, Владивостокта да узган.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Мөнирә СӘГЫЙДУЛЛИНА

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

**ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124**

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 06.10.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2540 данә

Заказ 2638

16+